

# Равиль Файзуллин

Избранные произведения

В шести томах

Том 3

*Стихи*
*Поэмы*

КАЗАНЬ • ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • 2005



# Равил Фәйзуллин

Сайланма әсәрләр

Алты томда

3 том

*Шигырьләр*
*Поэмалар*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2005

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ф91

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Фәйзуллин Р.Г.**

Ф91 Сайланма әсәрләр: 6 т. / Равил Фәйзуллин. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.

ISBN 5-298-04201-5

3 т.: Шигырьләр, поэмалар. — 2005. — 527 б.

ISBN 5-298-04211-2

ISBN 5-298-04211-2 (3 т.)
ISBN 5-298-04201-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Фәйзуллин Р.Г., 2005





## ЕЛАН ТАВЫННАН КАРАДЫМ...

*(Төш)*

Елан тавыннан карадым –
дуңгыз көтүен күрдем.
Казансуда таш һәйкәлнең
агып китүен күрдем.

Елан тавыннан карадым –
Ослан тауларын күрдем.
Идел төпләренә багып,
сагыш ярларын күрдем.

Елан тавыннан карадым –
биш балта сабын күрдем.
Акпатшаның айбалтада
күзенең агын күрдем.

*1984, март*
*Казан*

## ТУГАН ЙОРТТА

Бу түшәм такталарында
безнең урманның төсе.
Әтиләр егет булганда
таргандыр алар үсеп.

Бу мичнең кирпечләрендә
Шарлы* балчыгы төсе.
Беркөн комга әйләнерләр,
шушы нигезгә күчеп.

Бу тупсаның сырларында
тәпи баскан чак төсе.
Җекләргә сеңгән мүкләрдә
ерак җәйләрнең исе.

Бу матчаның ыргагында
тирбәнгән бишек төсе.
...Бала чагын сагынып ята
караватта карт кеше.

*1984, апрель*
*Пицунда*

* Ш а р л ы — елга-инешле үзәнлек исеме.

## БЕР ЧАРДУГАН ЯНЫНДА

Яшь. Сау. Көләч... Булды синең
тулышып килгән ай чагың!
Кая ару, кая талу! —
уйнап йөргән тай чагың!

Кая ул чак еллар санау!
Үткәнен язның, көзнең...
«Дөнья, диден, тик башлана!
Мәңгелек ул — без үзе!

Теләсәм — карт имәннәрне
суырып алып атам!
Теләсәм — аккан суларны
буып, сузылып ятам!

Теләсәм — йолдызлар чүплим!
Кирәксә — тау күчерәм!»
Мин ул чак көнләштем синнән,
һәм сокландым эчемнән.

Вакыт үтә-үтә беркөн
Ай да сызылып бетте.
Яшь имәнне яшен сукты.
Хушлашыр вакыт җитте.

...Йолдызлар да үз күгендә.
Таулар да урынында.
...Өстенә язу язылган
яңа бер түмгәк тора.

*1984, 14 апрель*
*Пицунда*

## УЧАК ЯНЫНДА

Көлдә пешкән
бәрәңгене
әрчегәндә
карала кул.

Хафаланма,
юдың исә
чистара ул!

Бәлкем, юлда
бәрәңгенең
җегәре дә
озак бармас...

Ә учактан
төшкән якты
гомерлеккә
җанда калыр —
еллар алмас!

*1984, 4 май*
*Юлсубино*

## ТУГАН ӨЙДӘ КҮРГӘН ТӨШ

Шундый матур төш!
Бөтен җир гел —
чәчәк тә гөл!

Чишмә дә инеш!
Һәм шунда...
мин, имеш!

...Айны урак итеп гөл кистем.
Чүмеч йолдыз белән су эчтем!

*1984, 5 май*
*Юлсубино*

## ТУГАНСЫҢ ИКӘН...

Тугансың икән, дөньяның
сиңа өлеше була.
Фәкать сиңа гына тигән
башкарыр эше була.

Шуны яшьли аңлаган җан,
гомер буе, икеләнмичә,
максатына баралган җан —
бәхетле кеше була.

*1984, 3 июнь*
*Казан*

## ЯЛГАН

I

Һәр әйтелгән ялган сүздән
мөгез чыкса маңгайга!
Кыяк үләннән күбрәк
мөгез булыр дөньяда!

Әле дә чыкмый. Юкса бездән
сабыйлар качар иде...
Олылар бер-берсен күреп,
акылдан шашар иде!

II

Һәр ялганнан җан көчләнә.
Күз нуры тоныклана.
Ялганчының, бер көн килеп,
баскан туфрагы яна!

Ә туфракка нәрсә ялган —
Табигать ул яңара!
Һәр ялганнан иң әүвәле
Ил аңы томалана...

*1984, 23 август*
*Казан*

* * *

Җирдә байлык артмый, кимеми дә —
күченеп кенә йөри оешып...

Табигатьнең
алып җанын,
арттырмакчы
Адәм малны...
Алтын-көмеш
елтырыннан
сыеклана
рухи каны...

Җисемемне Җиргә күмсәгез дә,
Рухымны сез Күккә күмегез!

Табигатьнең
алып җанын,
арттырмакчы
Адәм данны!
Җирдә тормыш
булыр шанлы —
Табигатьтән
алсак аңны...

Безнең яшьлекләр күк түгелләр шул, —
Язлар кабатлана ел саен!

*1984, 23 сентябрь*
*Куктубә*

## ИСКӘ ТӨШЕРДЕ ӘТӘЧ АВАЗЫ...

Таң алдыннан әтәч кычкыруы
яңгырады диңгез ярында!
Таныш аваз шундук йотылды
аунап килгән дулкын шавында.

Безнең аңда — әтәч биләмәсе;
киртә, бакча, абзар тирәсе...
Диңгез буендагы әтәчләргә
ияләнелмәгән, күрәсең.

Ә шулай да таныш шул аваз,
хәтер катларына таралып,
диңгезләргә хаким дәверләрне
искә төшергәч, киттем яңарып.

*1984, 24 сентябрь*
*Куктубә*

## ЯЛГЫЗЛЫК

Элек тә алар икәү иде
шушы йортта:
йөгерек хәтер,
күкеле сәгать.

Сәгать беркөн ватылып тукталды.
«Калдым берүзем...» дип йөргәндә,
табылды бит янә бер иптәш —
төнләләрен аваз биреп куя
мич артында сайрар чикерткә.

*1984, 6 октябрь*
*Күктүбә*

## КЫЗЫГУ

Апрельдә туган якка кайткач,
Тау кашында мәш килә балалар!
Биектә — зәп-зәңгәр өр-яңа язгы күк!
Тирә-юньдә — яңа гына борын төрткән яшел
чирәм.

Җилләр белән әүмәкләшеп,
тәгәриләр,
куышалар,
көрәшәләр яшь малайлар!
Чабак кебек ялтырап ала табаннары!
Бер ишләре кәгазь очкыч җибәрәләр күк
катына.
Чаялары учак аша сикерәләр бер-бер артлы.
Кышны җиңү куанычы — йөзләрендә!

...Карап торам читтән кызыгып.
Кушылыр идем мин дә уенга —
сикерә алмыйм еллар читәнен!
Бер юаныч — шөгылем бар:
куен дәфтәренә сүзләр язам —
«Зәңгәр түтен.
Яшел чирәм.
Төссез яшь...»

*1984, 13 октябрь*
*Куктубә*

## ...УЛ — СИН!

Утларда янам, утларда!..
Яндыручысы ул — син!
Янып бетмәс өчен, Ходай
җанга сабырлык бирсен!

Рәхәттән шашам, рәхәттән!..
Шаштыручысы ул — Син!
Очып китмәс өчен, Ходай
әзрәк авырлык бирсен!

*1984, 3 октябрь*
*Казан*

## ТУГАН ХАЛКЫМ

Бу дөньяда һәркем лаек ихтирамга,
раслый алса яшәвенең олылыгын.
Туган халкым! Илең-телең саклый алган
югалмыйча кала алуың — горурлыгым!

Матурлыкка, гаделлеккә, тынычлыкка
хезмәт итсәң — намусың пакь, иҗатың чын.
Туган халкым! Сынауларда сабыр булып,
җиңүләрдә ныгаюың — таянычым!

Йолдызларга менгән кеше, ялгышып та,
таптап китмәс шушы җирнең бер чәчәген.
Туган халкым! Тарихларның давылында
игелекле балаларың — киләчәгең!

*1984, 6 ноябрь*
*Казан*

## ҖЫРЛА СИН!

Җырла син! Җырыңны тыңлап,
белермен үткәнеңне.
Җырла син! Күзләрең миңа
әйтер ни көткәнеңне.

Җырла син! Халык җырында —
илеңнең үткән көне.
Киткәннәрнең васыять итеп
калдырган өмет-өне.

*1984, 9 ноябрь*
*Казан*

## ҖИГӘ АЛСАҢ...

Кыргый атның горур башын
элмәкләгән табунчыдай,
кулга ала да берәү Вакытны,
сөйри,
сөйри үз юлына!

Әй тартыша Вакыт!
Әй тартыша!..
(Күнеккән ул
хакимнәрнең хакиме булып!)

...Әгәр җиңеп,
ихтыярына җигә алса
Олуг Вакыт Галиҗәнабын —
шул зат кала
Бөек булып,
Вакытының
исемен алып
мәңгелеккә!

*1984, 21 ноябрь*
*Казан*

## ИСЕҢДӘМЕ?

*Р-га*

Урман авызыннан чыктык та без
(каршыбызда — кечке шәһәр),
гөнаһлы адымнар белән
(урлап алган бәхет хәвефле),
онытылып, хәлсез сарышып
(гомер юлы шәфәкъка якын),
Кояш баешына ашыктык
(тәрәзәдән көтә балалар)...

...Көтмәгәндә калку юл өстендә
керпе очрап безне туктатты
(ник дип чыккан кичке яланга?).

Тора керпе калкулыкта,
тере йомгак булып офыкта
(төнге якны җансыз димә син!).
Без торабыз
тораташтай, икәү бер булып
(олыгайгач сабый чак тарта)...
Тора керпе алсу фонда
(безне аңлый, әллә битәрли?).
Безнең соры кояш түгелме ул
(күктәгесе кереп югалган)?
Шул суәттә микән әллә
безгә иңгән энәле язмыш
(үткән белән һаман тартыша җан)?
Бераз торгач, тәгәрәде керпе
түбән таба тузанлы юлдан
(таң сызылыр тарафка таба).

...Кинәт миңа борылып карадың да
(сиңа ул кич ничә яшь иде?),
озын керфек очларыңнан
(элеккечә кайнар, үткерләр!)
тамды җиргә
ал-
    су
        чык-
            лар...

*1979—1984*
*Казан — Куктубә*

## ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ БЕЛӘН ЧИБӘР КҮЛ

Җирдә чибәр бер Күл булган.
Ә Күктә — якты Йолдыз.
Ишләре күбәү, ди дә, тик... —
үзләре никтер ялгыз.

Бер гаҗәп төнне Йолдызның
бер нуры Күлгә кунган.
Күл дә, иркә нурны тоеп,
бер дулкынланып куйган.

Берсе — Күктә, берсе — Җирдә.
Ерак булса да ара,
ниндидер могҗиза белән
очрашканнар кай ара.

Очрашу дигәне дә шул —
аңлашып карап алу.
Миллионнар арасыннан
бер-береңтаба алу.

Күк катында якты Йолдыз
зарыгып көткән кичне.
Атылырга әзер икән,
күрсә Күл яткан төшне.

Бу хәл Төнгә ошамаган,—
көнләшү— яман икән! —
караңгылык белән Күлнең
өстеннән яба икән.

Шуңа өстәп япкан аны
йә томан, йә болытлар.
Кышларын карлы бураннар,
җәйләрен төнбоеклар...

Күл үзе дә, көзге кебек,
Җирендә яткан көе,
көткән зарыгып Йолдызын,
Күкләргә баккан көе.

Сирәк аяз көннәрдә алар
бер-берсен тоя икән.
Кавышырга өлгермичә
таң атып куя икән!

Берсе янган, берсе көйгән...
Шулай гасырлар үткән.
Һәрнәрсәнең чиге була —
Күлнең түземе беткән.
Кибеп, парларга әйләнеп,
Күкләргә менеп киткән!

...Шул төн кипкән Күл урынына
Йолдыз атылган күктән...

*1985, 7 гыйнвар*
*Казан*

## КЫШКЫ АВЫЛДАН БЕР СУРӘТ

*(Малай чак хатирәсе)*

Кипкән яшел үлән — ризык.
Алтын салам — түшәк.
Абзар эчендә парланып
маллар тора күшәп.

Куначадагы әтәчнең
төшләрендә челлә!
Җитәме соң туңган бөртек
җәйге татлы җимгә!

Күк чиләктә шаулый аклык —
әни сыер сава.
Авыл өсләп талгын гына
күбәләк кар ява...

*1985, 10 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Вакыт өчен нәрсә Адәм гаме!
Һәр үзгәреш аңа — дөреслек!
Гаҗәпмени — Атлантида хәлен
аңлый алмый икән Эверест...

Кайчак сыйпап сөйгән гөлләрең дә
белми-тоймый синең шатлыкны.
...Кем ишетсен, Галәмгә дип төбәп,
җиң эченә әйткән хаклыкны.

*1985, 12 гыйнвар*
*Казан*

## ЫШАНЫЧ

*(Җыр)*

Илләр күп ул, җирләр күп ул, телләр күп ул...
Ә гомерләр — һәркемнең дә берәү генә!
Җырым әйтсен: халык өчен җан аямый
яшәүчеләр ирешсеннәр теләгенә!

Гөл чәчәкле, алсу таңлы бу дөньяга
туа кеше бәхет өчен, шатлык өчен.
Ил язмышы кыл өстендә торса әгәр,
фидаиләр башын сала хаклык өчен.

Җир йөзендә күпме ана бала бага,
өметләнеп тыныч көнгә, якты көнгә!
Һәммә кеше шат яшәсен, бәхет җырын
җырлый-җырлый туган җирдә, туган телдә!

*1985, 21 гыйнвар*
*Казан*

## ТОРДЫМ БАСЫП КАМА ЯРЫНДА

*Пристаньнар ярга ятып кала,*
*елый-елый китә пароход.*

Кадыйр Сибгатуллин

Бик ямансу булды быел кайткач
Балык Бистәсенең ярында.
Яланаяк басып тордым гүя
боз каплаган учак урынында...

Күңелнең бер якты аланына
төште кебек кырау-күләгә.
Пристанебызны алганнар бит,
без калалар «яулап» йөргәндә!

Яшьлек яры ятимләнеп калган,
бушап калган тирә-әйләнә.
Дебаркадер урынында хәзер
күбекләнеп дулкын тирбәлә...

Мәкәрҗә күк шаулы булган җир тын.
Казлар гына йөри чемченеп...
Бистәбезнең бу тарихи җирен
искә алдым авыр көрсенеп.

Кавышу-аерылулар үзәге иде!
Кая халык? Атлар? Әрҗәләр?
Кая балык, дегет, сыра исе?
Кая кыяр саткан марҗалар?..

Шушы төшкә ничә буыннардан
кемнәр генә аяк басмаган!
Нинди генә язмыш үтмәгәндер
пароходка салган басмадан!

...Пароходлар хәзер читләп үтә,
сәлам бирми безнең ярларга.
Ярдан атылып, керәшәләр генә
каршы чыгып оча аларга...

Һай замана! Әле кайчанмы соң
басып торып шушы ярларда,
шигырьләребезне укый идек,
Туган якны теләп данларга.
Җилләр генә безне тыңласа да,
бәхетлеләр идек дөньяда!

Хыялландык, яндык шушы ярда!
Кама безне аңлыйдыр иде.
Пароходның гудок бирүләре
безнең өчен үзе җыр иде!

Пристань ул — булган җанлы тарих,
бер бизәге безнең якларның.
Инде ул да кайтмаска дип киткән,
кайтмаган күк яшьлек чакларың.

Киткән чакта телгә килгәндер ул:
«Сау булыгыз! Сәфәр — затонга!»
Бу тормышта һәркемгә дә язган
соңгы тапкыр нидер озатырга...

...Басып торам элекке урында.
Офыкларда сагыш пәрдәсе.
Күзем йомсам күрәм: яшьлектәге
пароходларымның шәүләсен!

Яшьлекне җил офыкларга куган.
Керсә, бары — төштә ул еллар.
Кайсы затоннарда муртаялар
«Засулич»лар, «Вера Фигнер»лар?*

Дөнья — фани. Ярлар гына түгел,
үзебез дә шактый үзгәрдек!
Нуры азрак хәзер күзләрнең,
чынлыгы ким әйткән сүзләрнең...

* Пароход исемнәре.

Тик шулай да кылганыбыз — ихлас!
Азмы-күпме бар ул — эшебез.
Халык күңеленә җырлар уеп,
яшәргә дип килгән кеше без!

Хакыйкатькә тирән кергән саен,
кеше күп чак кала шул ялгыз...
Кама өстендәге күкрәүләр
әйтә кебек: «Югалтышмагыз!
Югалтышмагыз!
Югалтышмагыз!..»

Бик ямансу булды бу юл кайткач
яр буенда басып торулар!
Күңел өзгәләнеп теләгән иде
шул сәгатьтә бергә булырга...

...Бу хисләрне берәүгә дә әйтми
йөртә алыр идем эчемдә.
Шулай да бер ачылыйм дидем
әҗәлләрне кичкән кешегә.

*1985, 22 гыйнвар*
*Казан*

* * *

«Хуш!» дип әйтмим, «Сау бул!» дим.
«Түмгәк түгел, тау бул!» дим.
«Дуслар өчен саф җил булсаң,
дошман өчен дау бул!» дим.

«Син ят түгел, яр бул!» дим.
«Канатыма пар бул!» дим.
«Канатыма пар булмасаң,
учка кунар кар бул!» дим.

*1985, 22 гыйнвар*
*Казан*

## ӨМЕТ

*(Җыр)*

Яшьлекләр инде үтсә дә,
моңаер чаклар җитсә дә,
күңел
һич тынгылык теләми һаман да.

Әйтерсең лә
бәхет көткән
бер борылыш бар алда!

Хисләнеп алган чак була.
Хыяллар шундый ак була!
Шулчак
син чыгарсың шикелле каршыма.

Андый мәлдә
бу дөньяда
фәкать шатлык бар сыман!

Кешене өмет яшәтә.
Кешене сөю яшәртә.
Җиңә
зур мәхәббәт ил өчен көрәштә.

Сөю рухын
җуймаганда,
без көчлеләр һәр яшьтә!

*1985, 24 гыйнвар*
*Казан*

## КИЧЕР КАЙТА АЛМАВЫМНЫ!..

*(Җыр)*

Кичер, әнкәй, кичер
кайта алмавымны!
Чит ил туфрагында
ятып калганымны...

Язмышымны белми
озак көткәнсеңдер.
«Кайтмый калмас ул!» — дип
өмет иткәнсеңдер.

Илгә кайтасылар
килми идеме соң!
Гомер киселүен
тели идемме соң!..

Сугыш фаҗигасен
онытмасын еллар!
Язмышлары миндәй
алар — миллионнар!

Барсын илгә бирдем,
ни бар көчем булды,
һәлак булуым да
халкым өчен булды.

Кичер, әнкәй, кичер
кайта алмавымны!
Чит ил туфрагында
ятып калганымны...

*1985, 26 гыйнвар*
*Казан*

## СИҢА

Йоклаганда елмаясың —
күрәсең, бәхетлесең!
Нигә бәхетле булмаска? —
куйнында сөйгән кешең!

Сау тәнеңдә — яшәү дәрте,
күңелең—аклык кына!
Үзең теләп сайлап алган
хезмәтең — шатлык кына!

Нигә бәхетле булмаска? —
алма күк балаң янда!..
Мондый түгәрәк бәхеткә
кызыгыр Аллалар да!

*1985, 30 гыйнвар*
*Казан*

* * *

*Рәхәттер ул догаларны*
*туган телдә укулары!*

Элегрәк әби-бабай сәҗдә киткән
китап ятлап
комлы яктан
безгә иңгән
имляларда.
Ә без хәзер өйрәнәбез дәүләт рухын —
законнарны
котып яктан
безгә килгән
имляларда.

Шатлык килсә,
кайгы килсә,
җырлыйбыз без,
елыйбыз без
туган телдә,
карый-карый
кыйблаларга.

*1985, 3 февраль*
*Казан*

## ЧИЛӘБЕ. ТӨН. ВОКЗАЛ. КҮПЕРДӘ

Төрле шәһәр вокзалларында,
платформа күперләрендә
ничә тапкыр басып торылган да
күпме төнге утлар күрелгән!

Ымсынулар катыш сагыш белән
озатылган күпме поездлар!
Алар киткән якта әллә ничек
серле яна иде йолдызлар...

...Менә тагын торам күпердә мин.
Алда-артта — юллар, составлар...
Чуен юллы корыч айгырларның
ник берсенә утырып чапмаска?

Тик кай якка? Их, берәрсе шунда
яшьлек тарафына булсачы!
Тупикларга керсә, урман ярып,
барыр идем кебек юл ачып.

Шәп исемнәр куеп чыгар идем
үзем ачкан станцаларга!
«Саулык» станцасы,
«Хыял»,
«Шатлык»,
«Бәхет»!
«Сагыш»... —
монсы бераз ямансыларга...

Борылмалар саен яшьлектәге
ялгышларны күмәр идем дә,
язулы таш куеп, яшьрәкләргә:
«Гыйбрәт алыгыз!» — дияр идем мин.

...Төрле шәһәр вокзалларында,
платформа баскычларында
дөньяның күпме җил-түтене
йөзләремә килеп сарылган!

Ят җирләрдә офыкларга багып,
күзнең нуры күпме түгелгән!
Шул җуйганнар өчен бер яңа ямь
җыя бара килдем күңелемә.
Шуны табыш итеп, юллар буйлап
ташып йөрим бугай илемә.

...Җир өстендә күпме яңа юллар
яшен эзләредәй ярыла!
Поездлары гына никтер күбрәк
ашыгалар шәфәкъ ягына...

...Яшьлек эзләреннән хәзер ешрак
кабат-кабат урыйм уйларда.
Ә тирәмдә яшь малайлар үсә,
хыялланып сәфәр чыгарга.
Ничә буын язмышлары ята
көмеш йөзле чуен юлларда!

*1985, 8 февраль*
*Казан*

## АВЫЛ ИДИЛЛИЯСЕ

Яшел үлән,
сары үлән,
аксыл үлән —
бер болын.

Кызыл сыер,
кара сыер,
ала сыер —
бер көтү.

Чүмечләп сөт,
чүлмәкләп сөт,
чиләкләп сөт —
бер дәрья.

Кара туфрак,
көлсу туфрак,
сары туфрак —
бер басу.

Язгы бодай,
көзге бодай,
карабодай —
бер өмет.

Солы ипи,
бодай ипи,
арыш ипи —
бер саулык.

Ямансу җыр,
күңелле җыр,
сөюле җыр —
бер гомер.

Иген игә,
көтү көтә,
бала бага —
бу төбәк.

Ватаныма
тик бер нәрсә —
т-ы-н-ы-ч-л-ы-к!
кына кирәк!

*1985, 6 март*
*Бакуриани (Грузия)*

## МУНЧА ЯГА АНАЛАР...

Мунча якты. Улы иртәгә
каралырга барасы...
Комиссия тикшерәчәк
солдатлыкка ярыйсын.

«Яраклы!» дип кайтарырлар,
шикләнми анысына.
Бүтән үзгә бер күз белән
карый ул баласына.

Малай, дисәң, инде — олы,
егет, дисәң — иртәрәк.
Шулай да җиткән вакыты
өйдән чыгып китәргә...

...Хәтердә, һаман хәтердә:
бер ямьле иртә иде.
Әтисе дә авылыннан
бер чыгып киткән иде.

Мунчалар кереп китте дә,
югалды газиз башы.
Чит туфракларда югалды,
юк хәтта кабер ташы...

Менә хәзер үз улын да
мунчалар кертәсе бар.
Капкадан чыгып китүгә,
өзелеп көтәсе бар...

Ә дөнья тыныч түгел.
Хәвеф бар һәр тарафта.
Җиһан ал-гөл тоеладыр
бары тик битарафка.

Ул үстерсәң — ут йотарга,
кыз үстерсәң — сакларга...
Кайтмасын иде балалар
цинклы табутларда!

Бала — бәгырь. Яшь гомере
өзелмәсме чәчәктә?
Һәр ана бага баласын
«Өмет!» дип киләчәккә.

...Ана бүген иртәдән үк
һаман мунча юлында.
Газиз улын пакь итеп ул
тапшырыр ил кулына.

Горурланган, хәвефләнгән
аналар күпме алар!
Күзләрендә бер генә уй:
«Тыныч булсын дөньялар!
Тыныч булсын дөньялар!»

*1985, 31 март*
*Мәскәү*

## СИЗДЕРМИ КАЛМАС!..

Чапты балта. Ауды агач...

Җир белән Күк берлегенең
өзелде бер кылы.

Хаҗәтсез яман эш кылды
Кеше кулы...

Табигать сиздерми калмас моны
кайчандыр,
кемнәрдер,
нәрсәдер
аркылы!

*1985, 6 апрель*
*Пицунда*

## АЛМА ҺӘМ КОРТ

Орлыкка елышкан кортка
алма — әйләнгән йортка!
Алма үзе йә төшкән корт
чыгарга тиеш юкка...

Юк шул. Алма эленеп калды.
Дөрес, бозылган эчтән...
Корт та исән. Инде әнә
бүтән алмага күчкән!

*1985, 8 апрель*
*Пицунда*

## ОФЫКТАГЫ ЮЛ ӨСТЕННӘН АГЫЛАЛАР БОЛЫТЛАР...

*Югаравыл юлы,*
*Түбәнавыл юлы!*
*Гарифуллам, ник кайтмыйсың?*
*Сагындырдың бу юлы...*

Дәүәни бик еш әйтә иде бу җырны

Олы юл үргә менә дә
югала офыкларда.
Карашларың туктап кала
күктәге болытларда.

Юл — кисеп кергән шикелле
болытлар арасына.
Болытлар ишелеп чыга
карашлар каршына.

Юл югалган шул ноктага
төбәлгән күзләр күпме!
Кемдер кайта, кемдер китә
кичеп шул нокта-чикне.

Офыктагы ул болытлар
керми нинди сурәткә!
Үзгәрсә дә сурәтләре,
уелып бара йөрәккә.

Болытлар бер ак булалар,
бер китәләр каралып.
Төсләрне алар — көткәннәрнең
күзләреннән аламы?

Болытлар! Белеп үтегез
юл өстенең ул турын!
Күпме җаннар шул тарафка
юнәлткәннәр күз нурын!

Каплап тора күрмәгез сез
кайтучы, китүчене!
Тамчы булып иренен̦ә
тамыгыз көтүченең!

...Олы юл, нигә дип шулай
үрләргә менден̦ икән?
Офыктагы болытлар күк,
көтү — мәңгелек икән!

Көтәләр... Ник көтмәсеннәр,
көтәргә өмет барда.
Әнә бит болайга таба
йөгерә болытлар да!

*1985, 9—10 апрель*
*Пицунда*

## ЧИТКӘ КИТҮЧЕЛӘРГӘ

*Аерылганны — аю ашар...*

Мәкаль

Аю башы җитәме соң
һәрбер аерылганга!
«Ерактагы кояш шәп!» дип,
читкә каерылганга!

Туган җирне ташлауларның
юлы ник бетми икән?
Китү чире ил канына
бер керсә — китми икән!

Тудыра, суын эчерә,
тел бирә, кеше итә...
Тагын нишләсен Туган җир?
Ә кемдер... ташлап китә.

Китә кайчак язмыш кушкач,
кайчак — үзе теләп тә.
Ялгышып та, язылып та,
китә бәхет эзләп тә.
(Уйласаң, һәр кылган эшкә
табып була сәбәп тә.)

Аерыла илдән-телдән,
җиреннән-нигезеннән...
Кайчак үзен дә югалта
Яшәеш Диңгезендә...

Һәр чакрым киткән саен,
үз җырыңнан язасың.
Соңрак... балаларың татый
ялгышларның җәзасын.

Кошлар да әйләнеп кайта, —
ташламый Туган җирен.
Кеше кадәр кеше булып,
ничек оныта илен?

...Аерылган да чәчелгән,
сибелгән дә таралган.
(Мисаллар бар: кай халыклар
туплаактар яңадан.)
Җил бер чәчкән орлыкларны
җыеп кара яңадан!

. . . . . . . . . . . . .

«Аерылганны — аю ашар,
бүленгәнне — бүре»дер.
Аю-бүре эзләп читтә
күпме җаннар йөридер!

*1985, 10 апрель*
*Пицунда*

## БЕЗНЕҢ АЛСУ

*Алсу гөлләр чәчәк атсын*
*йөргән юлларыгызда!*

Балалар вокаль ансамбле җитәкчесе
Алсу Гарифуллинага

Алсуы инде — ансы үзең!
Гөлләрең— балаларың...
Балалар авазы аша
данлыйсың халык җанын!

Берәүләр — тимер бөгәләр,
берәүләр — иген игә.
Безнең Алсу — авазлардан
күңелгә гөлләр чигә!

Үзең дә, бәлки, гөлләрдән
такыя үрәсеңдер?
Балаларны да үз итеп,
гөл итеп күрәсеңдер.

Шулайдыр. Бүтәнчә булса,
без сихерләнмәс идек.
Концертларыңда мең кабат
«Мең яшә!» димәс идек!

Балаларыңны тыңлагач,
сабый чакка кайтасың.
Халыкның киләчәгенә
өметне яңартасың.

Сәнгатьтә юллар җиңелме?
Авырлыклар да бардыр...
Ышанабыз, Синдә җиңәр
сабырлыклар да бардыр.

Сине аңлаучылар күбәү —
ямансулама, Алсу!
Алда — яңа сөенечләр,
яңа сынаулар, Алсу!

*1985, 14 апрель*
*Пицунда*

* * *

Яшәү ул — һәр күзәнәкнең
иркен, рәхәт сулавы.
Тәннең Кояш каршында
көч тоеп уйнаклавы.

Бәхет ул — һаман яшь калып,
максатка ирешә алу.
Рух бүлешер җандаш табып,
сөенә-сөешә алу.

*1985, 17 апрель*
*Пицунда*

## ТӨНГЕ КҮКТӘ КЫР КАЗЛАРЫ ӨНЕ

Фильм бетте. Чын сәнгатьчә әсәр.
Сурәтләнә язмыш хәлләре.
Залда ут янгач та, тәэссораты
күңелләрдән китми барды әле...

Экран тормышы әле урамда да
дәвам итте уйны бизәвен.
...Кинәт өстә — язгы төнге күктә
нинди авазлар бу? Чү әле!..

Ялгышмыйммы? Кошлар авазы ич!
Кайтып килгән казлар тавышы!
Исәрләнеп тыңлыйм. Кинодагы
вакыйгалар очты барысы.

Бала чакта гына була торган
бер халәткә кайттым яңадан.
БТРлар салган улау түгел,
бу — илаһи иңрәү һавадан.

Шәһәр күкләрендә беренче кат
ишетәм бугай өнен казларның?
Кабатланмас сихри бүләк бит бу
кабатланып килгән язларның.

...Һич бәхәс юк: олы сәнгать — юлдаш
гаделлеккә, ямьгә, аклыкка.
Тик ул азрак, кеше үзе тоеп,
Табигатьтән алган шатлыкка.

*1985, 22 май*
*Казан*

## КАРАМА!

Синең керфек — сиксән бөртек!
Һәммәсеннән гөл тама!
Күз алмаларым эри бит,
карама миңа таба!

Минем сөю — яшен тию!
Куен ачсам — кан яна!
Бәгырькәең көяр, кызый,
карама миңа таба!

*1985, 8 август*
*Казан*

## ТАНЫЙМ ДА, ТАНЫМЫЙМ ДА...

Без утырткан бакча бит бу!
Юкәсе, каены да...
Еллар үткәч кайткан идем —
таныйм да, танымыйм да...

Якташлар ихлас чакырды
өенә, табынына,
карыйм сынап яшен-картын —
таныйм да, танымыйм да...

...Кайсысының оныгы бар.
Кайсысы — аерылган...
Бергә укыган кызларны
таныйм да, танымыйм да...

Зиратыбызда йөрдем,
әрвахлар янында.
Әүвәлге ташбилгеләрне
таныйм да, танымыйм да...

Күпме нәрсә төс үзгәрткән
елларның агымында!
Саеккан инешнең юлын
таныйм да, танымыйм да...

...Миннән дә сорыйдыр бу Җир:
«Син әле каян монда?»
Гөлләре әйтә шикелле:
«Таныйм да, танымыйм да...»

*1985, 28 сентябрь*
*Казан*

* * *

Җанын талкып, артык йөдәтмә син
уйчан калган ялгыз кешене.
Җиңәр өчен күпләрне ул, бәлки,
ялгызлыгы белән көчледер?..

Ашыгып әйтмә: «Һай, гамьсез ул!» — дип
гел елмаеп йөргән кешегә.
Елмаюы битлек кенә булып,
ут сулыйдыр, бәлки, эченнән...

*1985, 7 октябрь*
*Санкт-Петербург*

## ЯПЬ-ЯШЬ КИЛЕШ СӘРХУШ БУЛГАН ТАНЫШ ТҮГЕЛ БЕРӘҮГӘ

Әйтеп торырга кирәкме? —
дөньяда, дип, күпме ямь!
Ә соң нишлим: күзеңдә
өметсез бушлык күрәм.

Күрәм: сиңа таңнар ни дә,
болытлар агышы ни...
Балалар көлүе ни дә,
чишмәләр тавышы ни!..

Күк, Җир, Су матурлыгына
битараф булгач инде, —
димәк, эш вәгазьдән узган,
җаның тәгаен чирле.

Димәк, үз хәлең хәл инде,
җителгән соңгы чиккә.
Матурлык та көчсез булгач,
талпынуларың — тиккә...

...Күргәч сине, үземнең дә
башым иелгән кебек.
Ниндидер ялгыш җибәреп,
яуда җиңелгән кебек.
Гаеплелек энәләре
мигә сибелгән кебек...

Бер уйласаң, син кем миңа?
Беренче күрәм алда.
...Без — җирдәш шул. Кеше булып
яшәргә килгән җаннар.

Шушы уй, утлы күмер күк,
тынгылык бирми аңга.

*1985, 7 октябрь*
*Санкт-Петербург*

## ХАТИРӘ

Тәти ташлар җыеп кайттык
Кара диңгез буеннан.
Аларга, бәлкем, кайчандыр
дельфиннар да сыенган?..

Хәзер ята нәни ташлар
аквариум төбендә.
Чагыла вак балыкларның
күләгәләре генә...

Алар, шиксез, сагынадыр
диңгезнең дулкыннарын.
Мин дә аларга карадым да
искә алдым Кырым ярын...

*1985, 23 октябрь*
*Куктубә*

* * *

Язуларга теркәлмәгән сүзләр күпме!
Чын хак сүзләр,
　　　　　ялган сүзләр,
　　　　　　　　йомшак сүзләр,
　　　　　　　　　　　　үткен сүзләр...
Очалар да кемнәрнеңдер ирененнән,
Җил аларны сибеп йөри дөнья буйлап —
кыйтгалардан кыйтгаларга...

Югалалар?
Юк, югалмый, бетми алар!
(Сүз кадәр сүз ничек бетсен!)
Чыга алар йә таш булып,
йә шыталар гөлләр булып...
Күрәләр дә бу хәлләрне
(Кешеләрне күрми димә!),
туа Җирдә яңа шытым —
йә Изгелек,
　　　　　йә Яманлык...

*1985, 31 октябрь*
*Куктубә*

## САМОЛЕТТА ОЧКАНДА

Аста — болытлар...
Уйнаклый яшен!
Шомланып куям:
бит аста — Җирдә —
сөйгәнем яши!..

Җирдән Күкләргә
карыйдыр ул да.
Бәлки, әйтәдер:
«Бит өстә — Күктә —
кадерлем юлда!..»

Хәвеф — кемгә аста,
хәвеф — кемгә өстә...
Яшенле күктә,
ут булып гүя,
уйлар кисешкән.

*1985, 8 ноябрь*
*Казан*

## СИҢА

Бу төшләрне генә язсаң да! —
Мәхәббәт поэмасы!

...Кайчак аңлашмыйбыз икән —
үтә ул — кайгырмачы!

Язмыш безне өнебездән —
Сөюдән аермасын!

*1985, 10 ноябрь*
*Казан*

## КИЧКЕ МОҢСУ БЕР КҮРЕНЕШ

Көмеш Ай нурында коенып,
тора оеп
сандык ягасында ак песи.

Бу бүлмәдә һәр ялгызлык үз төшендә.
Асылынып тора тонык люстра,
шкаф башына терәп куелган рамлы фото,
стенадагы герле сәгать,
ятагында — ялгыз тол хатын...

Көмеш Ай нурында ак песи
торараштай тора оеп.
Тәпиләре белән колак кашып,
кунак чакырыр исәбе дә юк...

*1985, 12 ноябрь*
*Казан*

## КАСКАДЕР

Утлар эченә кер. Сикереп төш
муен сындырырлык биектән.
Аварияләргә эләк. Сугыш.
Тәгәрәп йөр җанвар-киектәй.
Барган шәпкә поездлардан ташлан.
Күперләрдән барып очып төш.
Исән-имин кал тик! Хәвефләрдән
үлем ясамау бит — безнең эш!
Дөрес, кайчак без дә азат түгел
ялгышудан яки каушаудан...
Ә шулай да бу эш тынычрак
сәясәттә сальто ясаудан.
Кемгә — трюк. Уен... Безгә — хезмәт.
Алынгансың, эшең—чын булсын!
Сәнгать белән Хәтәр янәшәдә —
биекләрдән егыл егылсаң!
Киноларда ерак кадрда без.
Алгы планнарда — геройлар!
Без кылганда кичергәннәрне
Ходай белсен ничек уйныйлар?!
Сау тәнеңнең һәр бөртегенә
хуҗа булу бик җиңел түгел!
Экстремаль халәтләрдә кайчак
йомшап ала, нечкәреп күңел...
Кыл өстендә калган вакытларда
үлем шәүләләре күренә!..
Тарзан булып күпме генә йөрмә,
һәркемнең дә гомере бер генә!
Бу дөньяда язмыш сынавында
буладыр ул һәркем каскадер!
Яшәвенә, шөгыленә карап,
исемнәре генә башкадыр...

*1982—1985*
*Казан*

# КОШЛАРЫМНЫ КӨТӘМ

*(Җыр)*

Нигә шулай багам һаваларга,
канатларым юк ла иңемдә?
Туган якка кайткан кошлар юлы
үтә, ахры, минем күңелдән.

Нигә шулай тыңлыйм искән җилне,
әллә берәр хәбәр көтәмме?
Хәбәр түгел, көтәм кошларымның
талга басып сайрар иртәне.

Нигә шулай тансык кошлар өне,
кош сайраудан сагыш кимерме?
Кошлар булып, ахры, җаным җырлый,
искә алып үткән гомерне.

*1985*
*Казан*

## ЯРА БУЛЫП КАЛГАН ХАТИРӘ

Белмим, кемнәргә тигәндер
ул мәчет манарасы?
Өстенә атланып кисте
шуны адәм баласы!..

Сабый чак. Шулай да истә:
халык җыелган иде.
Манара аена аркан
бәйләп куелган иде.

Кисүче Түбән авылдан.
Акчага кисә, имеш.
Манара кисә, кисә дә
аннан соң эчә, имеш.

Әләм-әтрәк табылыр ул...
Ә халык ни караган?
Имгәкне иңгә кертерлек
ирләр юкмы арада?

Җимереп ташлау — оста өйгән
ракета-корылманы —
шулмы эш? — «искегә»
каршы көрәш «геройлары»?

Тыныч чакта җимерү-кисү
ул — кыргыйлык хәлләре.
Төшергәнче — күтәрә бел,
менгезә бел әүвәле!

Элекке авыл чыклы иде,
гөлле, чирәмле иде...
Шәм кебек манаралары
үзенчә ямьле иде!

*1985*
*Казан*

## ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА БЕР ШИГЫРЬ

И кардәшем! Бер хаҗәтсез кайчак
телне шундый бозып сөйлисең!
Ил колагын хурлап, халкыңның
рухын рәнҗетәмен димисең!

Мескенләнмә, бакый гомер килгән
тел байлыгын итмә кадерсез.
Бер уйласаң, илаһи бит, изге —
Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз!

Һич мәртәбә түгел туган телдә
җиң очына карап сөйләшү.
Көчле, горур сөйләш! Кирәк икән
хаким телләр торсын көнләшеп!

Иренмә син, туган, туган телнең
асыл байлыкларын ачарга.
Без ваемсыз булсак, чит-ят сүзләр
хәзинәңне әзер басарга!

Ана телне ватып-бозып сөйләп,
кешелегең генә төшә бит!
Корама тел, яман чир булып,
яңа буыннарга күчә бит!

Күп телләрне белү — яхшы шөгыль,
туган телең үги калмаса.
Җанын салып әйткән әткәң сүзен
синең аша балаң аңласа.

Мәгълүм: дөнья көтү, заман өчен
файдалырак телләр бары да...
Тик шунсы хак: фәкать туган телдә
иман иңә кеше җанына!

Киләчәкнең башы — бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнеңдә —
оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
матур итеп туган телеңдә!

*1985*
*Казан*

## ЯЛГЫША ДИП УЙЛА МИНЕ...

Керфекләрең яшь күренә,
күзләрең инде уңган...
Керфек-канат җилпенсә дә,
күңелең кошы туңган...

Үткән гомер элмәкләре —
муеңдагы сырларың.
Моңлырак чыга шул инде
шаян дигән җырларың...

Үзең сер бирмисең әле —
дәртле уйлар уеңда.
Әйдә, уйла, ялгыш диеп
минем фикер турында.

*1986, 21 гыйнвар*
*Уржум*

## КЕШЕ-ХУҖА НИ УЙЛЫЙ?

Диңгезнең үз балыклары...
Тайганың — боланнары,
кыя-тауның — бөркетләре,
чүлләрнең — еланнары,
даланың — йомраннары...

Һәркайсының үз яшәве:
суы, күге, үз яры...
Бәлки әле үзләре дә
белмиләрдер бер-беренең
бу дөньяда барын?..

Ә менә Кеше дигәнең
һәммәсен белеп тора!
Очканнарын күреп тора,
йөзгәннәрен күреп тора,
чапканнарын күреп тора...

Шуңа да үзен Җир-Күкнең
хакиме итеп тоя.
Табигатьнең күп эшенә
хуҗа булып кул куя!

Бер карасаң, Табигать гел
шул килеш — борынгыча.
Гөлләр үсә, җилләр исә,
диңгез шаулый, кош оча...
Бер карасаң, Табигать гел
тәмам үзгәреп беткән!..
Кояш үзе аптырыйдыр —
теге киткән, бу кипкән...

Күк-гөмбәз үзгәрмәсә дә,
Җирдә хәлләр башкарак:
Кеше дигән Хуҗа-затка
Тереклек тора карап... —
барсын күреп торучыга,
барсын белеп торучыга,
барсын сизеп торучыга...

Ә соң Кеше ничек карый
үзенең бурычына?
Чын Хуҗа бурычына,
чын хаким бурычына?
...Иң башта син бу сорауга
үзеңнән җавап сора!

*1986, 18 февраль*
*Чегет (Кабарда-Балкария)*

## ЯШЬЛЕГЕМНЕҢ КӨМЕШ БЕР КИЧЕ

Көмеш ай! Көмеш дөнья!
Көмеш шәмнәр рәт-рәт!
Күңелгә аклык иңдерер
кабатланмас сурәт!

Бу тылсымны сөйләү кыен —
аны күрү кирәк!
Табигатьнең андый чагы
буладыр бик сирәк!

Һәрбер тараф гел көмештән:
көмеш — үлән-тирәк...
Көмеш — төнге кош авазы,
көмеш — пешкән җиләк!

Бу манзара үзе генә дә
чиктән ашкан иде!
Матурлыктан исәрләнеп,
ярым шашкан идем...

Өстәвенә Син үзең дә
гел ап-актан идең.
Мине үртәп ак дөньяга
кереп качкан идең.

Яктырткыч бөҗәкләргә мин:
«Табышыгыз!» — дидем.
Илаһи бәхет көтүдән
мин сабырсыз идем.

Бермәл үзең килеп чыктың
каен арасыннан —
урманнарда яши торган
пәри кызы сыман.

Күпме йолдыз безне күзләп,
чекерәеп янды.
Ике күзең — ике ут-йолдыз —
зиһенемне алды.

Ничәү соң ай? Күктә — берәү,
күпмесе йөрәктә!
Тагын... якты ике ак ай —
синең күкрәкләр!..

Бу аклыктан күңел күзең
чагылу да булыр.
Бу вакытта бөеклек тә,
абыну да булыр...

Йолдызларын безгә ышанып,
ай оеп йоклады,
һәр күзәнәктә кабынды
сәгадәт утлары...

Булган алар гомеремнең
алтын минутлары!

...Көмеш ай! Көмеш дөнья!
Ак каеннар рәт-рәт!
Искә төшә дә ул чаклар,
шундый татлы — рәхәт!
Яшьлекнең шул киче өчен,
Язмыш, сиңа рәхмәт!

*1986, 14 февраль*
*Чегет (Кабарда-Балкария)*

## ҖӘЙГЕ ЯҢГЫРДАН СОҢ ИДЕЛДӘ

Басулар нишләгәндер, — күрмәдем, —
әй кинәнде Идел яңгырга!
Күк белән Су кавышып бер булды.
Яңгыр икән балалары!

Чистарып калгандай булды дулкыннар —
(кырыкмыш атларның яланган ялы күк).
Юынды ак тәрәзәле яшел дебаркадерлар,
коенды кызыл маяклар,
яктырып китте сал өсләре!..

Без, сәйяхләр, палубада тезелешеп
күзәтәбез акчарлаклар уйнаклавын:
су өстеннән күтәрелгән бу җылы пар
канатларны җиңеләйтәме, авырайтамы?
Гудок биреп, каршы килгән теплоходта
юкмы икән берәр таныш?

Уңда-сулда утырып калган утраулардан
аңкып килә печән исе, җиләк исе.
Ярлардагы учакларның төтеннәре куеланган
(чыбык-чабык артыграк дымлангандыр...).

Көймәләрдә, причалларда, басмаларда
җанландылар балыкчылар
(яңгырдан соң кичке чиртү җитте бугай).

...Яңгыр болытлары күкрәп үтте.
Без төшәбез Идел буйлап
шул болытлар киткән якка.

Баюына барган Кояш офыгыннан нуры белән
безне арттан этә кебек.
Биекләрдән караганнарга —
аккош кебек, бер пароход
йөзмә шатлык булып күренәбездер...

Яңгырдан соң күкләр аяз,
күңелләр саф,
сулыш иркен,
яхшы сүзләр килә әйтәсе!

Хәерле кич сиңа, Идел, хәерле кич!
Тыныч сәфәр, имин төннәр сезгә, Кешеләр!

*1981–1986*
*Идел — Чегет (Кабарда-Балкария)*

## ЯШӘҮ БИТ ҮЗЕ БЕР БӘЙРӘМ ЛӘ!

*Боекма! Елмай, көл!*
*Күңеленә*
*яусын гел шифалы ләйсәннәр!*
*Хыяллар күгендә*
*җилфердәт әләмнәр!*

*Дөньяда яшәүләр —*
*аңлаган кешегә*
*үзе бер бәйрәм лә!*

Тагын көннәр аяз! Кояш көлә!
Туган якка кайткан сыерчык!
Ничек моңа сөенмәскә кирәк —
быел язга тагын сау чыктык!

Әти-әни исән. Ярым янда.
Сөйгән эшем — җанга бер дәва.
Ихлас әйткән гадел сүзебездән
яңа яхшылыклар ярала.

Дөньялар имин. Хыяллар сау.
Җыр туарлык муллык табында.
Заманалар меңгә әйләнсә дә,
фидакарьләр һәрчак табыла!

*1986, 16 февраль*
*Чегет (Кабарда-Балкария)*

* * *

Тау өстеннән — йолдызлар да якын,
егылсаң да, кеше күзендә...
Таулар — гадел. Ни дип кычкырсаң да,
кайтавазы кайта үзеңә.

Кара төн дә караңгылаталмый
пиклардагы карлар аклыгын.
Биекләргә менеп кою кирәк
җанны сарган тормыш ваклыгын!

*1986, февраль*
*Чегет (Кабарда-Балкария)*

## ЭЛЬБРУСТА ИСЕМ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

Ошхамахуа дип аны
адыгей халкы әйтә.
Грузинча Ял-буз булыр.
Куска-мафь ул — чиркәстә.
Осетиннарда — Ура-хох,
балкарларда — Мәңге тау...
Һәркайсы — җирле халыкның
тауны зурлап атавы.
Мәгънәләре бер диярлек —
Олы тау, Мәңгелек тау,
Изге тау, Бәхет тавы...
Ничек кенә әйтмәсеннәр,
бар шул әйтерлекләре —
Туган җирләре символы,
изге биеклекләре!

Тауга якын бу илләрнең
язмышлары да текә!
Һәрбер ташка халыкларның
тарихлары береккән.

Кемнәр генә үрелмәгән
бу тауның ияренә!*
Ышанып биек тәхетнең
үзенә тияренә...

Аш-гамахо, Стыр-хох... —
һәрбер исем изге лә!
Ә менә ерак халыкның
исеме калган үзендә:

Эльбрус дип танылган ул.
Әль-борыс — фарсычасы.
...Белмим, ни дип атый аны
бөркет — кошлар патшасы?

*1986, 18 февраль*
*Чегет (Кабарда-Балкария)*

* Эльбрус тавының түбә өлеше ияр сыман ике өркәчле сырттан тора.

## САУМЫ, ТАУЛАР!

Саумы, таулар,
Тәпи басмасам да сезне күреп,
яшьтән үк сез йөрәктә инде!
Әллә ерак бабамнарның каны
кыяларга береккән инде?

Саумы, таулар!
Озын сәфәр үтеп,
сәлам әйтәм Биекстанга!
(Минем дә бит үземә «стан»ым бар,
гаҗәпләнмә шулай кушканга.)

Саумы, таулар!
Сезгә ятмы, үзмедер мин, белмим,
гашыйк булгач, шиктә юк гамем.
Күземә генә түгел, рухым өчен,
үземә генә түгел, халкым өчен
биеклекләр барлап килгәнмен.

Саумы, таулар!
— Сау-у-м-ы-ы!..
Кабатлыйсыз?
Ишеткәнсез икән ләбаса!
Тау һәм Кеше биегәя бары,
бер-берләрен әгәр аңласа.

*1986, 10 март*
*Казан*

## ТАУ — ШУЛ УК ҖИР...

Тау — шул ук җир. Тик аңарга
башны чөеп карар җир.
Тау — шул ук җир. Туарга да,
күмелергә дә ярар җир.

Тау — шул ук җир. Тик һәркемнең
табанына ятмас җир.
Тау — шул ук җир. Биеклекне
бер югалтсаң, тапмас җир.

*1986, 11 март*
*Казан*

## БЕР ЭРЕСӘҢ, ТАМАРСЫҢ...

Түбәнгә үк
төшмик әле
дигәндәй,
кар бөртекләре
калгалады
түбәдә.

Өс өс инде! —
Юккамыни
мактыйлар!
Иң беренче
астагыны
таптыйлар...

Шуңа күрә
кыш буена
кәрнизләрдә
яттылар.

...Яз килде дә,
нурлар торды
камчылап.
Туры килде
тәгәрәргә
тамчылап.

Нишләтәсең —
биектән бер
төшәсе,
Табигатең
асылына
күчәсе!

Түбәләрдән
тамчы тама
тып та тып...
Яз кодрәтен
буламыни
туктатып!

*1986, 15 март*
*Казан*

## ГЕЛ ГЕНӘ ИМАН ЯҢАРТЫП ДӨНЬЯНЫ КАРГАУЧЫГА

«Дөнья — усал-фәлән...» — диеп
кан елау яхшы түгел!
Бөтен искән җилләр дә бит
гел генә каршы түгел.

Төп кыйблаң булмый торып,
гел-гел иман яңартсаң,
гаҗәп түгел, «Язмыш ханым»
борыныңны канатса...

Иман ул үзгәрә алмый,
иман ул — ныгый гына!
Дөньяны «кыйный!» димик,
дөнья сыный гына!

*1986, 1 июль*
*Казан*

## БЕРНӘРСӘ ДӘ ЯНӘ КАБАТЛАНМЫЙ

Күп нәрсәләр күрдем, татыдым —
зәңгәр бәллүр диңгезләрдә,
    кояшларга якын тауларда,
        сәмум җилле серле чүлләрдә...
Беренче кат тойганлыктан,
көтелмәгән ачышлардан,
гаҗәпләнеп хисләнүдән,
илерә-илерә шатланудан
күз яшьләре чыга иде!
Шул чакларда —
(кимсенгән дә көннәр булды) —
янымда син бер булмадың!..

...Хәзер менә без дә бергә —
Син янымда. Дүрт күз белән йөреп була теләгәнчә.
Була кабат
    диңгез күреп,
        таулар менеп,
            чүлләр кичеп.

Тик шунсы бар:
ачышлардан бигрәк, мин бит хәзер
бу якларны беренче кат кемнәр белән күргәннәрне
искә төшереп,
    чагыштырып йөриячәкмен...

*1986, 2 июль*
*Казан*

* * *

Яманлыкны
таптый-таптый
җиргә күм!

Ил-халкыңны
мәңге яшәр
җырга күм!

*1986, 17 июль*
*Тольятти*

* * *

*«Авыл» циклыннан*

Яфраклар лепердәшә,
күгәрченнәр гөрләшә...
Җансыз, димә, — түбәдәге
морҗалар да сөйләшә!

Иртүк торып башлый алар
төтен телләре белән, —
алар өйләр эчендәге
әллә ниләрне белә!

— Безнекеләр коймак пешерә,
ә син никтер соңладың?
— Кичә кунаклар озаклады,
килен иртүк тормады.
Мине әйтмә, кара күршең —
ахылдавык торбаны!

— Әйттең тагы... Ялкау ирнең
утыны гел чи аның!
...Шундук ул да телгә килә,
торган күк сакта гына:
— Артык телләнмәгез әле
гел минем хакта гына.

Үзегез дә шым буласыз
газ яккан чакларында!
— Әхмиләр төтене нигә
үрли сәлам бирмичә?
— Кабат ирдән аерылып
кызлары кайтты кичә...

...Тыңлап тора-тора да җил,—
ачуы чыга бугай,—
морҗаларның зәңгәр телен
бөтереп урый-урый,
өрә-өрә гайбәтләрен,
офыклар буйлап юллый!
Аңа карап морҗаларда
барыбер төтен тынмый!

Яфраклар лепердәшә,
күгәрченнәр гөрләшә...
Бу дөньяда бөтен нәрсә
үз телендә сөйләшә.
Җиһандагы бөтен серләр
барыбер бер берләшә.
Иң дөресе: бу тормышта
гадел һәм ачык яшә!

*1986, 1 сентябрь*
*Казан*

* * *

Аягүрә йоклап йөрсәң —
көн дә йолдызлыдыр ул.
Халык уенда янмасаң —
йөрәк тә тузмыйдыр ул.

Гамьсез яшәү— сизенмичә
туфракка күчүдер ул.
Вакыт исәбенә керми
Хәтердән төшүдер ул.

*1986, 11 октябрь*
*Куктубә*

## ЧОРМАДА

Ярыктан кергән дә шуып,
әйләнә җил,
туглана җил!
Эх-ма!
Кадими тузаннар белән
бии дә бөтерелә!

...Чөйдән салынып карап тора
заманында ил алдында
аю биеткән гармун.

*1986, 15 октябрь*
*Куктубә*

## ҮЗЕМНЕ ЮАТАМ...

Зәмһәрир кыш көнне, чәчкәгә кунам дип, исәр кош
бәрелде тәрәзгә, имгәтте канатын.

Мин дә шул кош кебек, кул җитмәс матурга
җан атып, күпме кат җанымны канаттым...
Шулай да үземне юатам: гүзәл хис — Ярату!

*1986, 15 ноябрь*
*Казан*

## ТӨНГЕ УЙ

Йокы ояларын туздырып,
Хәтер барабаны әйләнә.
Үткән еллар, ахры, мидән саркып,
бүгенгемә килеп бәйләнә?

Бер дә җуймам, диеп, яшь чакта без
алган идек рухи бер баеп...
Хәзер әнә, эшләремне узып,
күпме ялгыш тора ыржаеп!

Гасыр кичмәсәк тә, аз тормадык
замананың җилле чатында.
Юллар...
    Еллар...
            Аерылу-кавышулар...
Яшәленгән шулар хакына.

Кичкән-күргәннәрне тәртипләргә
компьютерлар көче кирәкме?
Җавап урынына кулым тота
чәнчеп-чәнчеп алган йөрәкне...

*1986, ноябрь*
*Новосибирск*

## КАЙСЫН ПИГЫ ИТӘГЕНДӘ

*Кайсын Кулиевка*

Ватаныңа килеп, тауда йөрим.
Үзең исән чакта соңладым.
Бер юаныч: исемең йөрткән пикны
үз күзләрем белән күралдым.

Монда булып киткән зур шагыйрьләр
данлап язсалар да тауларны;
таулар җанын йөрткән халык рухын
килгән-киткән сәйях аңлармы?

Таулар матур. Әмма кырыс та алар.
Ташны тирең тишсә — син ашлы!..
Әйтә идең: тауларымның минем
күләгәләре дә кояшлы!

Киртләч-киртләч икән тау очлары —
гүя кардиограмма сурәте!
Ничек түздең икән, йөрәгеңә
ишелгәндә халкың хәсрәте?

Синдәй ирләр барда, аз халык та
ишле, бөек булып танылa.
Әйтелгән сүз, күкрәү-яшен булып,
әверелә дөнья данына.

...«Ах! тау юклыклар...» дип язган идем
күптән инде — үсмер чагымда.
Гомер тавын төшеп кабатлыймын:
«Таулар юк!» — дип тагын, тагын да...

Казаннарга килеп чыга идең,
көнчелләргә шатлык өләшеп.
Егет булып калдың көнчелләрдә,
бер символы булып көрәшнең.

Син бер ныклы тере күпере идең
болгар иле белән балкарның.
Җәрәхәтле таш та җанланадыр,
канат тисә — синдәй Шоңкарның!

...Кайсын пигы. Биек. Итәгендә
яшь бөркетләр канатлананалар.
Таулар биеклекне югалталмый —
алар Күккә кадакланганнар!

*1987, 9 февраль*
*Казан*

## УЙНЫҢ ИКЕ СУРӘТЕ

Яшь чакта
күңелдә бөредәй яралган һәрбер уй
ашкынып оча да биеккә —
кошларның канатын иркәләп,
болытлар катында тибрәнеп,
(болытлар үзләре гел тоташ хыялдан!)
нурланып, шәбәеп, мең тармак җибәреп,
әверелә ямь-яшел мәһабәт агачка!

Олайгач, еш кына,
күңелне канатып туа да авыр уй,
әйләнеп яфраксыз энәле куакка,
(чәнечке чыбыклар шикелле),
тора гел каршыда, һич китми, —
һәм янә яралап,
тамырын җибәрә... бәгырьгә...

*1987, 22 февраль*
*Казан*

## БОРЧЫЛУДА ТУГАН ЫШАНЫЧ

Безнең замана кешесе
бик күп нәрсәгә ия…
Бер җан башына фәләнчә
шартлаткыч кына тия!

Шундый авыр йөк тагылгач,
нишләсен мескен Адәм…
Ышаныч-максат күрмәгәч,
хәйраны… була әрәм.

Әйтик, Европа илләрендә
бала туу аз хәзер.
Аның каравы, ишәеп,
ракеталар тора әзер.

Әкият булып яңгырамый
хәзер «ахырзаман»ы.
Мифта түгел, чынлыкта шул
бандиты, наркоманы…

Нурланып туа һәр кеше.
Була якты хыялы!
Яши-яши күңеленә
иблис кереп оялый.

Каян килә имансызлык?
Вату-җимерү уе?
Шәхси «мин»нән — дәүләткәчә
үзеңне өстен кую?

Нигә күп көч куя кеше
һәлакәт уенына?
Нигә дип аркылы төшми
чын афәтләр юлына —
әмәл тапмый яман шешкә,
вакытсыз картаюга?..

Ник карамый киләчәккә
баласы күзе белән?
Кем ни алып китә ала
туфракка үзе белән?
Кала барсы... һәр киткәннән —
үзгә кала Ил йөзе.
Ныгытып китә — йә яхшылык,
йә яманлык нигезен.

Нигә таянып үсмибез
хакимнәр мирасына?
Тарих битендә күбрәк
иң әүвәл тиран чыга!..
Җиһангирлар, каләм алып,
халык канына манып,
язалар җиңү турында
рухланып һәм мактанып.
Гел тукыгач, әйткәннәре
чынлыкка охшап китә,
елъязма булып кала да
байтак буынга җитә!

Дәһшәт булып көч калыкса,
Тынычлыкка бетә рәт...
Аптырап һәм мәэюсләнеп,
Акыл кала читтәрәк.
Ни мәгънә ачышлардан,
афәт китерер булса,
Табигатьнең ямен көчләп,
асылы — үтерү булса?
Сугыш юлы — билгеле юл —
һәлакәткә туп-туры...
Күз нуры түгел икән шул
радиация нуры!
Моңарчы Адәм шикләнмәгән
һәрдаим җиңәренә,
хәзер үзе аптыраштта
матдә-атом җегәреннән.

Гүя аткан угы кире
үзенә төшеп килә.
Төзәтелмәс ялгышлары
исенә төшеп килә.
Тиккәмени күпме җаннар
чаң сугалар айнырга!
Ашкынып коралланута
каршы коралланырга!

Җир — уртак өй. Бу яшәүнең
белик кадерен генә...
Белик чикләр шартлылыгын
җилләр кадәрле генә!

Кояш Зәңгәр йомгагына,
бәлки, карыйдыр көлеп;
Җирдә Тереклекнең мәңге
бетмәячәген белеп.
Ә безгә дә белү кирәк
алданиләр буласын.
Яңа туганнар иң әүвәл
синнән-миннән сорасы!

...Бүген без дә — үзгәрештә,
Яңарышта һәр күңел!
Гасыр ахыры булса да,
Заман ахыры түгел!

*1987, февраль*
*Казан*

* * *

Кулы — эштә. Җаны — утта.
Күзе — синдә — юлдадыр...
Кеше арасына алып чык,
«Ирем!» дисен ул да бер!

Яшьлек уза, дип янасың...
Аныкы янмаганмы?
Картаюдыр: бәхет, дибез
кемнәрдер алдаганны.

*1987, 13 апрель*
*Кукчубә*

## ҖАН КӨЕГЕ

*Д-ка*

Ашыгасың? Хәер, ашык.
Алгысын. Чап. Йөгер...
«Янса янсын, — дисең, — минем
аңлаешсыз гомер».

Чибәр булып үсеп җиткәч,
язмыштан кыйнатып,
сукбайлыкта йөргәч, шикле
юллар буйлатып,
үзең дә шул бетәшкәнсең —
кечерәйгән буең.
Синең яшьне чамалап та
әйтү хәзер кыен...

Йа Хода! Ни өчен сиңа
шундый җәза-сынау?
Нигә күзләрең яшереп,
керфекләрең сына?

Эндәшмисең... Авыр сиңа
туры итеп карау.
Яңа дөнья күлмәгенә
килешми шул ямау.
Гомер кичеп дөньялыкка
бер нур өстәдеңме?
Кешелекле рухың әллә
бераз көчләндеме?
Ата-анаң, җирең-илең
багып үстерсен дә,
ә ул имгән сөт-кан өчен
пычрак түкерсен дә,
каян килсен кешеләрдә
кызгану йә шәфкать?
Гыйбрәт итеп күрсәтәләр,
«Бичара!..» дип фәкать.

Ашыгасың? Хәер, ашык.
Син әлегә тере...
Тик кара, сабый балалар
күрмәс юлдан йөре!

*1987, 13 апрель*
*Күктүбә*

## МИН ЯШӘДЕМ!

Мин яшәдем —
күрдем елның кабатланмас фасылларын,
хатын-кызның мәхәббәттән янган йөзен.

Мин яшәдем —
җир җимереп хезмәт иттем.
Чөнки тойдым илнең якты күзен,
ишетеп тордым кешеләрнең хуплау сүзен.

*1987, 14 апрель*
*Куктубә*

## ТӨНГЕ СӘГАТЬ ТАВЫШЫ

Сәгать келт-келт итә.

Дисбесе өзелгән дә гүя,
коела Вакыт!
Шыбырдый гына!
Үзе белән тәгәрәтеп алып китә
безнең таза кан шарларын,
        көлүләрне,
                дәрт-хисләрне...

Хәтер генә зәгыйфь карт күк азаплана
һәр «келт» саен,
кайтмакчы гел үткән якка —
        яшьлек якка,
                бала чакка,
                        сабый чакка... —
без кайчандыр бөтен килеш
        калган якка.

*1987, 14 апрель*
*Куктубә*

## СЕНТЕНЦИЯЛӘРДӘН

Мәгънә төрле рәвештә:
имеш, кәләпүштә,
фуражкада,
панамада яки чалмада...

Кем нәрсәне
нидә күрә!

...Өстән — илаһ галәм катларыннан —
бәлки әле
мәгънә дә,
хакыйкать тә
бер формада,
бер төстәдер?!

*1987, 14 апрель*
*Куктубә*

## УКЫДЫМ ДА ТАНЫШЫМ КИТАБЫН...

Сиңа кирәк, ахры, дустым,
шөһрәт Эвересты!
Ялгышма, Шигърият бу!
Күпне күргән Шигърият бу!
Ирексез хөррият бу!

Минлегеңне күрсәтмә син,
күңелеңне күрсәт!
Күңелең бай түгел икән,
гомереңне күрсәт!
Гомерең дә ярлы икән,
белемеңне күрсәт!
Белемең дә чамалы икән,
дипломыңны күрсәт... —
дусларыңа.

Кызык табып, алданып,
уйнама Шигърияттә!
Бу заманда бигрәк тә!

Үткән гасырлардан килгән
шагыйрьләр даны үтте.
Әллә атом-төшкә сеңде,
әллә космоска китте?..

Шигырь-җырга хаҗәт бетсә,
белмим, ни заман җитте?

*1987, 16 апрель*
*Куктубә*

## «КЫЗЫЛ ӘТӘЧ»

«Кызыл әтәч» менеп алса
җил канатына! —
көл асларына күмелеп,
калалар тына...

Киек-җәнлекләре көеп,
урманнар яна.
Иген кырлары, далалар
кап-кара кала...

Кикерикле әтәчләр дә
шүрлиләр аннан!
Булмый калмый авылларда
берәр өй янган.

«Кызыл әтәч»не күрәләр
очынгач кына.
Ялкынланып хәвеф килгәч,
эш узгач кына.

Кайчак яшен тудыра аны,
кайчак — бер шырпы...
Гомер бакый кешеләрдә
бар аннан курку.

Гамьсез булсаң, «кызыл әтәч»
илеңне иңләр.
«Кызыл әтәч» ул бары
рәсемдә чибәр!

*1987, 17 апрель*
*Куктүбә*

## КИЧКЕ ЭЛЬБРУС

Яшеннәр — кайдадыр түбәндә.
Елгалар — кара җеп — бормалы чигештә.
Аҗаган балкышын капларлык кыялар!..

Күпме генә кара-карама —
бала чактан бу күренешнең
горур рәсеме юк шул җанда!

*1987, 18 апрель*
*Куктубә*

## ЯЗГЫ КАР СУЛАРЫНДА

Икәү янәшә атлыйбыз,
кулларың — кулларымда.
Без басмалар салмадыкмы
язгы кар суларында!

Безнең таныш кошлар бардыр
торналар чылбырында.
Елмаюың челтерәп тора
язгы кар суларында.

Тал бөреләрен иркәләп,
язгы күкләрне күзлә.
Зәңгәрлектә ак болытлар
бәхет телиләр безгә.

Гомер искә төшерер әле
салкын көзләр барын да...
Йөзләребез чагылып калсын
язгы кар суларында!

*1987, 26 апрель*
*Куктубә*

## АЛТЫН КАПКА! АЛТЫН КАПКА!

Алтын капка! Алтын капка!
Алтын кайчы булып,
алтын кайчы булып
кистең бәгъремне!

Алтын ярым! Алтын ярым!
Үтте бергә азы,
азы үтте бергә
яшьлек гомеремнең!

Алтын капка! Алтын капка!
Күпләр килгән сиңа,
бездәй күпләр килгән
сөю кичүенә.

Алтын ярым! Алтын ярым!
Бәхет — бергә чакны,
бер җан булган чакны
искә төшерүе дә!

...Еллап түләнгән шул
барсы өчен дә
гомер исәбеннән!
Гомер исәбеннән...

*1987, 1 май*
*Куктубә*

## ЕЛАН КАБЫГЫ

Елан кабыгы таптым мин
(тире, дисәң дә була).
Бер төше дә имгәнмәгән,
кире кисә дә була.

Таптым мин аны еракта —
Кырымда ял иткәндә.
Истәлеккә диеп алдым,
өйгә кайтып киткәндә.

Кайткач уйлыйм: кая моны
куярга йә эләргә?
Аптырагач, элеп куйдым
вазадагы гөлләргә.

Гөлнең аткан чәчәгенә
орынып тора башы.
Бер карасаң, хәтерләтә
табиб эмблемасын.

Танышлар сорап куялар:
бу әкәмәт нәрсә, дип.
Сискәнепләр уянырсың
төшләреңә керсә, дип.

Һәй, димен, юкка шүрлисез,
бу — җансыз кабык кына!
Еланның үзен эзләп тә,
бик сирәк табып була!

Үзенә тимәсәң, беркемгә
һич зыян салмый, диләр.
Ала белсәң, агуы әле
шифалы дару, диләр!

Шулай да артык димибез
саклану чарасын да.
...Тик менә чагу күбрәк, ди,
адәмнәр арасында!

Якындагы бер чагар, дип
кем уйлар гомерендә?
Елан булып чагачакның
сөт булып кереренә?

Аңлыйсың сыгылып төшкәч,
төзәлмәс яра калгач...
Күпләргә кәмит, яралы
җаның ялангач калгач...

Янәшәңдә әллә кемнәр
дус булып гомер итә.
Елан-кабык эчләреннән
шомлы уй шуып үтә.

...Гөлдәге кабыкка карап,
күңелдә сурәт туган:
Яшел аланда ваемсыз
чалкан яткан бер олан.
Баш очындагы куакта
балалап ята елан.

*1985—1987*
*Куктубә — Казан*

## ИНДЕ МИН ДӘ: «ЯШӘМӘДЕМ!» — ДИСӘМ...

Бу күңелем чама белмәс, ахры...
Инде мин дә: «Сөймәдем!» — дисәм, —
Хыялдан оят! Наздан, сәгадәттән
Күккә ашканнар әле дә исән.

Бу күзләрем туя белмәс, ахры...
Инде мин дә: «Күрмәдем!» — дисәм, —
Ходайдан оят! Җир шарының байтак
тарафларын гиздем югыйсә.

Бу җаным һич тынычланмас, ахры...
Мин дә: «Гомер кичмәдем!» — дисәм, —
Язмыштан оят! Күпме егылып та,
гаҗәп әле — һаман да исән!

*1986—1987*
*Әстерхан — Казан*

* * *

Шатлыктан да, хәсрәттән дә
тама яшь тамчы-тамчы...

...Шөһрәт даулап, энҗе эзләп
диңгезгә атылганчы,
Тилелек җилкәне белән
Яшьлектә утырыр идем,
«акылга» утырганчы!

...Җәелеп тә, шаулап та актык,
ярларга кайтылганчы.
Кече булсаң да, син кеше бул —
даннарда ватылганчы,
малларга сатылганчы!

*1987, 8 сентябрь*
*Казан*

## БУЛСА ИКӘН УЛ!..

Гел торып ла булса икән ул
Салават күпере астында!

...Усак агач төбе өстендә
хәтта тычкан утын фейерверк күрер
дөм караңгы төннәр була.

Гомергәчә булса икән лә ул
беренче мәхәббәт хисләре!

Мендәр ертылып очкан мамыклар күк
бөтерелә гайбәт тирәндә!

...Һәм торасың шул «буран»да
елмайган булып.

*1987, 12 сентябрь*
*Казан*

## ТАНСЫК ТӨШЛӘР

Төштә дә өндәге кебек
бик күп нәрсә буталчык...
Шулай да байтак нәрсәләр
өндәгедән күпкә ачык!

Уенмыни! — төштә кайчак
үткәнгә кайтып була!
Мәңгелеккә киткәннәрне
кире апкайтып була.

Хыялдагы гүзәл белән
кочаклашып йөреп була.
Балачактагы таңнарны
яңадан күреп була!..

...Төштә дә өндәге кебек
бик күп нәрсә буталчык...
Ә шулай да татлы төшләр
олыгайгач бик тансык!

*1987, 15 ноябрь*
*Казан*

* * *

Ятып үлгәнче, йөреп үл,
дөньяны күреп үл,
кемлегеңне белеп үл,
дусларыңа елмаеп үл,
дошманыңнан көлеп үл.

*1987, 29 декабрь*
*Казан*

## ТУГАН ЯКТА

Мәңгелек чишмәле бу яклар!

Челтерәп гөрләсен дисәләр,
юл ачып, чистартып аларны
илсөяр уллары улаклар.
Тургайлар су эчкән чишмәдә
салават күпере уйнаклар!

Үлемсез җыр иле бу яклар!

Кешене гомере буена
хыялдан хыялга җыр әйдәр,
җыр назлар... Кирәксә, җыр — яклар!
Кем телне, кем җырны күтәргән —
халыкның йөрәген шул саклар!

*1987*
*Казан*

## ҖӘЙГЕ ТӨННЕҢ БЕР БӘЛӘКӘЙ ВАКЫЙГАСЫ

*Юк, ирексез мөмкин түгел бу дөньяда!*
*Юк, ирексез мөмкин түгел бу яшәү!*

Бүлмәмә — ачык балконнан
бер кош очып кергән төнлә.

Ят тавыштан уяндым да,
ярым аңсыз торып бастым.

Мескен кошчык
бүлмә бетереп бәргәләнә караңгыда,
тыпырчына чыгу юлын табалмыйча.
Матур төшем шундук эреп юкка чыкты.
Герле сәгать йөрүеннән туктап калды.
Сабый улым уянып елап җибәрде.
Стенага элгән карта шуып төште.
«Ни булды?» дип, әнисе сикереп торды.
Ут яндыргач, кош, җилпенеп,
лампочканы бәреп ватты.
Өстәлдәге ваза авып, кулъязмама су түгелде.
Кош куганда пианинога ялгыш басып,
яман әче аккорд чыкты.
«Нишлисез?» — дип, күршеләр ишек какты.

Ә югыйсә
бер кош ялгыш,
бүлмәгә очып,
вакытлыча
(бер биш-алты минут кына)
иреген җуеп алган иде.

...Һәм, ниһаять, юлын табып,
кош тәрәздән очып китте.

Балконга чыксам, йолдызлар атыла —
(әйтерсең лә)
күкне бизгәк тотып тартыша...

*1987*
*Казан*

# КАЗАНСУДА БОЗ КАТУ

Казансуны суык яулап алды,
дулкыннары тынды агымның.
Шулай өшеп кенә буладыр ул
җанлы килеш тынсыз калуы...

Күз алдында параличлангандай
хәрәкәтсезләнә су өсте.
Ике яклап ярдан, бозга әйләнеп,
тамчы арты тамчы биреште.

...Өстән карап торам. Күз алдында
боз элмәге һаман кысыла.
Ах, бу җиңелү агониясе —
ихтыярлы килеш буйсыну!

Табигатьнең гади халәте лә,
ник күңелгә авыр алына?
Әллә суык җилләр артыграк
кагылганмы гомер талыма?

Пошыну бу,
үлчәүләрдә — янганнардан битәр,
туң йөрәкләр күпкә шул баса!
Нәрсә булыр — хәтер-тарихларны
эремәслек бозлар капласа?

Атмосфералардан суык иңсә,
шартлаулардан янса җир йөзе,
калмас микән бушап Җир-планета
Тынлык белән генә берүзе?

Күк катында гына түгел хәзер,
күңелләрдә «озон тишеге».
Тел-илләрне, халыкларны күмеп,
битарафлык килә ишелеп.

...Җил көчәйде. Җирне, суны
бердәй итәм, диеп, кар төшә.
Ә уртада суык белән соңгы
шадра дулкынчыклар тартыша.

Әллә нинди уй-гамьнәргә салды
күз алдында Казансу кату.
Фаҗигаләр көтмәсә дә, барыбер
кешеләрне кирәк юату.

Боз ятса да, аста агым кала —
бәрер рухы язгы ташуда!
Чөнки һәрбер чишмә-елгаларның
башлангычы — тере тамчыда.

Без дә тере ләса! Ил-кыйтгалар хәзер
уртак язмыш,
уртак хәвеф белән беректе.
Кояш булган чакта ышаныч бар —
яшәү калыр, калыр тереклек!

*1987—1988*
*Пицунда — Казан*

## ТӨНГЕ УЧАК ЯНЫНДА

Офыктагы кара болыт —
толымнарың күләгәсе.
Ялкын теле —
күз нурыңның бер очкыны.

Каршында — мин.
Матриархатның
үзе теләп әсир төшкән
бер тоткыны.

*1988, февраль*
*Казан*

* * *

*«Бу минем хактамы?» дип сораган*
*бер ханым турында түгел бу юллар.*

Сине күрә алмаган һәр көн —
май аенда
яфрак яра алмаган шәрә агач.

...һәм мин —
бер томаны шул көннәрнең —
шыр ялангач!

*1988, март*
*Казан*

## АСРАУ

Ятим үсте.
Кияүгә чыкмады.
Кешеләрдә гомере буе
асрау булды.

Килде бер көн —
үзбаш яши башлады ул.
Мал асрады.
Картлык көндә
песигә калды.

Ул да үлде.

...Хәзер үзе япа-ялгыз
ялгыз өйдә
җан асрый.

*1988, 24 март*
*Казан*

## КАТАКЛИЗМ

Күк катлары убылып төшә.

Шәмнәр кебек төтенләнеп таулар эри.

Елгаларның кая акканын белеп булмый.

Китап кисәкләре бергә оча төрле телдә —
(тәрҗемәнең кирәге юк!).

Исән калган адәм-затлар барсы тигез —
(демократия!).

...Тик җил генә,
атмосферик күренеш буларак,
бернәрсәгә исе китми
исә бирә!..

*1988, 2 май*
*Казан*

## ЯЗЛАР КИЛӘ...

Вакыт кушкач,
Кояш җәнабы да
карда уелып калган
соңгы эзләрне безнең
ялмарга дип ялланганмы?

Эзләр бер хәл,
гомерне дә эретмәкче...

...Язлар килә
кемнәрнедер
тудырыр өчен!

*1988, 3 май*
*Казан*

## ТАУ ҺӘМ ҮЗӘН

*(Монолог)*

**Тау**

Без — тау. Хиссез без...
Юкса, күптән очып китәр идек...
Динебез — биеклек. Түбәнлекне танымыйбыз.
Болытлары кагылып узса — Күкнең безгә назы, дибез.

Аваз салабыз бик сирәк. Җавап кайтарабыз эндәшкәнгә.

Кем батыр, куркусыз — шул кунак. Менгән икән,
торсын басып, —
безне тагын биегәйтеп!
Башы әйләнгәннәр алдында һич юк гаеп.
Хәбәр-нисез югалсалар, давылларны гаепләмик!

Без — тау.

Без Галәмгә батып кергән өркәч-өркәч антенналар.

Без — Тау!

**Үзән**

Без — Үзән. Бүтәнчә әйтсәк, Җир эченә иңгән Тау без.

Үзәгебез күпчак яшьле: гөрләвекләр, чишмә-инешләр...

Без — Яшәеш учаклары, без — Яшәеш казаннары.
Җан иясе бездә тынмый.

Адәмнәр бала үстерә, казан аса, чәчә, ура, төзи, кора...
Кошлар нәни балаларын очыра,
кырмыскалар кайный түмгәкләрдә,
бал кортлары чәчкәләрдән нектар җыя,
тугайларда көтү-көтү маллар утлый...

Без — Үзән. Без Тормышның казаннары.
Кояш нуры безгә соңрак төшә.
Дөнья көтәр өчен эчке нур кирәк: тереклекнең хәрәкәте.

Без — Үзән.
Көйсезләнеп (яки үч алып) Тәңре-Җир бер ут төчкерсә,
Үзәннәрнең Тау булуы,
ә Тауларның убылуы бар...

*1988, июнь*
*Корноухово (Балык Бистәсе)*

## ОЧРАШТЫК КЕШЕ ТУЕНДА...

Гомер эзе — маңгаеңда...
Еллар эзе — муеныңда...

Сискәнеп киттең шикелле —
ишеткәч кеше туенда
икебез белгән бер җырны:
«...Синең белән даным чыкты,
җаным чыксын куеныңда!»

Борылып миңа карадың, —
мин идем үз уемда.

...Уеным да, чыным да,
әкиятем дә, җырым да!

*1988, июнь*
*Казан*

## КӨЗ — КӨЗ ИНДЕ...

Җилләр ни тарафка иссәләр дә,
һаваларда ташкын — бер якка,
китә кошлар янә көньякка...

Күңелләр тулыша моң белән
урман-кырлар бушанган чакта.

*1988, 7 июль*
*Корноухово*

## ХАЛӘТ

*Илдус Гыйлаҗевкә*

Син миңа, аргансың, диден.
Әйе, мин арган идем.
Дөньяның күзенә карап
бер тынып калган идем.

Үткән еллар баскычына
гүя менеп утырып,
Үткән белән Киләчәкне
тоташтырмакчы булып
уйга тардым.

Кемнәрдер хәтерлиләрдер:
без дә бит янган идек!
Очкынын балачактагы
хыялдан алган идек.

Яшьлек чаклары ялкыны
хәйран күренә иде.
Хаклык белән халык хакы
йөрәк түрендә иде.

Иман күбрәк булган, ахры,
ачлы-туклы буында.
Девиз иде: сынатмаска
Дөнья сабантуенда!

Безгә ул чак егерме иде...
Хәзер чагыштырам да,
бүгенге яшьләрне күреп,
әрнүләр туа җанда.
Бихисап сораулар тулы
билгесезлек тора алда...

Безнең дә өлеш үткәндә —
җиңү-җиңелүләрдә...
Күпме патшалар мәтәлде
безнең гомерләрдә дә!
Сәбәпсезмени чатнаулар
буыннар чылбырында?
Горур тора алдыкмы гел
елларның торгынында?

Көн итү җиңеләйсә дә,
уй-гамьнәр авырайды!
Безнең кулдан исән үткән
факел кемнәрдә калды?
Чын утмы ул? Тычкан утын
Балкыш дип йөрмибезме?
Юлдан яздыручыларны
алкышлап йөрмибезме?

...Син миңа, аргансың, дидең...
Әйе, мин арган идем.
Дөньяның күзенә карап
бер тынып калган идем.
Шактые үткән гомерне
бер барлап алган идем.

Кешенең шундый халәте
табигыйдер дөньяда.
Җиңгән гладиаторлар да
хәлсез бер тынып кала.

Яздым да уйлыйм: сиңа да
минем хәл таныштыр, дип.
Булмый һәм кирәкми, туган,
язмышны алыштырып!

*1988, 28 июль*
*Корноухово*

## ЮКӘ ЧӘЧӘГЕ ҖЫЙГАННАР...

Юкә чәчәге җыйганнар
ак яулыклы апалар.
Ак төенчекләргә төйнәп,
саулык алып кайталар.

Дөнья күргән апалар бу,
тормыш кичкән апалар!
Җиләк-как койган апалар,
сөлге чиккән апалар!

Урман аланыннан чыгып,
бал кортлары озата.
Табигать җанын аңлаган
җаннар шәһәрдән кайта.

Кемнедер оныгы көтә,
кемнедер улы көтә...
Юкә чәчәген тансыклап,
чәй эчәр кышлар җитә.

Ниндидер бер пакьлек балкый
кыяфәт, йөзләрендә.
Затлы кеше әверелә ул
Яшәүнең бизәгенә.

Юкә чәчәге җыйганнар
ак яулыклы апалар.
Ак төенчекләргә төйнәп
саулык алып кайталар.

...Бер карт сәрхуш чатка басып
тукталып карап тора.
Сау чакларын искә алып,
ахры, аптырап тора.

*1988, 4 август*
*Казан*

* * *

Санамагыз киткән торналарны!
Килер язны искә алыгыз...
Төркемдәге кошлар кимрәк чыкса —
сыкранып куяр җаныгыз.

...Ә кем белә: алар кайтканчы
тигез торырбызмы барыбыз?

*1988, 8 август*
*Корноухово*

## АУ СЕЗОНЫ АЧЫЛГАЧ

Җанлы күләгәләр кими көннән-көн
елга-күлләр, болын-үзән өсләрендә...

Кискен шарт-шорт шартлаулардан
йолдызлар
күбрәк
коела
Күкләрдән...

*1988, 21 август*
*Корноухово*

## ТӘРӘЗӘДӘН БЕР КҮРЕНЕШ

Телеантеннада — кара карга.

Экраннарда — кайный халыклар!
Оча президентлар!
Яшь ботлардан шуыша СПИД!..

Ә карганың исе дә китми —
тора шунда һаман каркылдап
шул борынгы белгән үз көен!

*1988, 27 август*
*Казан*

* * *

*Шигырьнең кирәклеге турында кайчак кирәкмәгән бәхәсләр дә булгалый.*

«Шигырьне укымыйлар...» дип
«сөенү» җиңелрәк.
Бездә әдәбият әнкәсе
гомердән Шигърият!

Әнкәләрне санламаучы
сантыйлар да җитәрлек.
Бездә шигырь — аңлаганга —
башың Себер китәрлек!

*1988, 13 сентябрь*
*Казан*

* * *

Татарстан — Төтенстан...
Дәүләт тимерчелеге!
Казан яшьләренең даны —
сугыш-тукмаулар буенча
илдә «беренчелеге».

Нинди кара, авыр эш бар —
безгә бит башкарасы...
Казан мәллә туган телне
оныту башкаласы?

Иман өсти дисезме сез
КамАЗлары, АЭСы?
Көн-төн суыргач нефтен,
көпшәкләнде Җир эче.
Күңеле дә бушап калгач,
маңкорт булды «җиңүче»!

Шәрә килеш кем гәп сата —
«татар» түгел, «болгар» син...
Заманында дөнья тоткан
«Тартария» булган син!

Халык исән — атап әйтер
үз суы-җире булса.
Җиренә хуҗа булырлык
дәүләте-иле булса.

*1988, 22 октябрь*
*Пицунда*

* * *

*Карап бак бер дөнья картасына —*
*күпме анда безнең исемнәр!*
*Әле исән калганы гына...*

Туган якта күпме атамалар! —
«яңартылганнар» да яңалар!
Төтен-бетон оялары корып,
яңа исем китереп тагалар...

Завод асларында сеңеп кала
җанга изге күпме исемнәр!
Алар әүвәл, чишмәләрдәй тибеп,
халыкның рухыннан тишелгән.

Килгән-киткәннәргә нәрсә исемең!
Җирең яхшы — бирсә акча, дан...
Шунсы авыр: бар бит арабызда
үз исемен дә саклый алмаган.

Әй, кардәшем!
Белмисеңме, тамыр корткан өчен
килер буын кызарып янасын?
Анаң иренenә салыр суны
килмешәк кулына саласың!

*1988, 30 октябрь*
*Пицунда*

## ЧИТТӘН КАЙТКАН КАРТ СОРАША АВЫЛДАШ КОРДАШЫННАН

*(Диалог)*

— Хәлләр ничек?
— Гөлләр кебек!
— Тазалыкмы?
— Аякта әле...
— Ни бетереш?
— Бәбкә саклыйм.
— Балаларың?
— Таралдылар...
— Пинсең күпме?
— Чәй-шикәрлек.

...Һавада тилгән пәйда була. Картларның сүзе өзелә. Икесе дә, башларын чөеп, сабый балалар шикелле онытылып, талгын гына очып үткән тилгәнне күмелгәнче озатып, бер мәлгә тынып калалар.

— Ни кыласың —
чиккә җиттек.
— Туарылды
гомер аты.
— Чакырып тора
зиараты...

*1984–1988*
*Казан – Пицунда*

## КАЗАН КРЕМЛЕ ЯНЫНДА СҮЗСЕЗ ТОРДЫК БЕЗ БЕР ҖӘЛИЛЧЕ ВЕТЕРАН БЕЛӘН

Кан өстендә — Җәлил һәйкәле.

Казансуда,
Иван явы килгән якта
батып бара кызыл офыкта
канлы Кояш.

...Баскынчылар мәетстанында
очты кара карга
Елан тавы якларына.

*1988*
*Казан*

## «ЯЗМЫШ» ДИГӘН АЛМАГАЧТАН...

Кем тик торыр дөньяда?
Һәммәсенең шөгыле бар!

Берәү иген чәчә,
берәү корал ясый,
берәү ил баета,
берәү урлап ташый...
Берәү дару ясый,
берәү тәнен сата,
берәү йортлар төзи,
берәү сүтеп ята...
Берәү яла яга,
берәү ода яза.
Берәү хаклык өчен
кайчак ала җәза...

Ә һәрберсе —
үзе белеп, инанганча
(алдатмыйча!),
иң акыллы,
иң-иң дөрес
яшәештә!

Ә шулай да,
Күк астында
«Язмыш» дигән алмагачтан
һәрберсенең
башына төшә
үзе теләп яулаганы:
йә череге,
йә алтыны...

*1988*

## СИН ДӘ БЕР КОЯШЫ ДӨНЬЯНЫҢ!

Алсу йөзләргә артык көнләшмә!
Үз язганнарын үзләре күрер!

Матурлык хакын китерер Язмыш —
К-а-й-г-ы
бүген килмәсә,
иртәгә килер...

*1989, 12 март*
*Казан*

## ШУНДЫЙ ЧАК...

Ияремне җиргә куеп,
өстенә утырган чак.

Алдымда— күмере төшеп,
ялкыны кайткан учак.

...Ә үземә нибарысы —
өч тапкыр унсигез чак!

*1989, март*
*Казан*

## ЯЗМЫШ ТОРСА ДА ӨСТӘН

*Хыял өнди, хыял өстери.*

Ун яшь чакта кем ышанмый
хәзинә табасына?
Унбиштә мәхәббәт-гөлнең
алдына тамасына?

Утызда аның һич шиге юк
мәйданнар тотасына.
Кырыкта хис итәр үзен
дөнья уртасында.

Илледә — акыл иясе,
алтмышта хаким сизеп,
Кеше һаман куяр үзен
гел биеккә менгезеп.

Яше ашып, нәсел үрчеп,
уллар-оныклар җиткәч,
нәфсе адәм хыял тотар
хәтта Үлемсезлеккә!

...Ишеттем гүя Язмышның
каһкаһәле көлүен:
«Бар хыялың юк итәргә
җитә бер төчкерүем!»

*1989, 3 апрель*
*Куктүбә*

## КӨНЬЯКТАГЫ РӘСЕМЕҢ

Утырасың диңгез буенда,
тезләреңне кочаклап.
Дулкыннар көенә яраткан
шигъри юллар кабатлап.
Чәчләреңне кояш ягына
иркәләп җил тараткан...

...Бәлки, шушы күренеш өчен
Тәңре сине яраткан?

*1989, апрель*
*Куктубә*

## ӘЛМӘТТӘ ҖИР ТЕТРӘҮ

*Әлмәттә җир тетрәгән...*
*Дүрт-биш баллга җиткән, ди!*
*«Татнефть»тәге графиннар*
*чайкалышып киткән, ди.*

Җирне җансыз дисезме сез? —
күрсәтер «җансызлыгын»!
Килер буыннар каргаячак
бүгенгеләр аңсызлыгын.

«Таланылып, көчләнелеп
чирле булып кал да син,
бәгырь каның — нефтең биреп,
алмашка су ал да син,
үзеңнән чыккан алтының
үзеңә ятмасын да,
шешә ватыклары белән
өслегең каплансын да,

чишмәләрең тозда эреп,
дегетләнеп бетсен дә,
тәнеңә күп меңәрләгән
скважиналар үтсен дә,
өстеңдә үскән игенең
ярым агу булсын да,
буыннар вагая барып,
зәгыйф алмаш тусын да,
бакый гомер туган җырлар
капылт онытылсын да,
шушы мәхшәрләрне данлап,
кемдер язып торсын да... —
бер тетрәп куярсың шул!

Әлмәттә җир тетрәде.
Бик күптән түгел әле...
Кемнәрнеңдер, кардәшләрем,
тетрәдеме күңелләре?
Тетрәдеме күңелләре?..

*1989, 4 апрель*
*Куктубә*

## ҮТКӘННӘР — БҮГЕННЕҢ БАШЫ

*Ялгыз калулардан куркасың син,*
*Тынлыгыңнан өркеп качасың...*
*Килми синең, үткәннәргә кайтып,*
*Хатирәләр биген ачасың...*

Хәтерләүләрдән курыкмыйм.
Нигә куркырга?
Хурлык-каза китермәдем
Идел-йортыма.

Әгәр кемдер үткәннәргә
күзне йоммакчы, —
димәк, гөнаһсы аның
көн кебек ачык.

Нинди серле мәкерне дә
Вакыт бер чишә!
Кешелекне кеше иткән
Хакыйкать — чишмә!

...Безгә кадәр дә акыллылар
булып киткәннәр.
Киләчәкне күреп була
фәкать үткәннән.

*1989, апрель*
*Куктубә*

## ТУГАН ЯККА КАЙТКАЧ

Һәр яз саен санап карыйм:
күпме яңа яшел яфрак
лепердәшә минем телдә?

...Моңыбыз сеңгән карт имәннәр
торбаларда төтенли — шул.

*1989, 6 апрель*
*Куктубә*

* * *

Яшәдең, эшләп җан аттың...
Йә, үзгәрттеңме бераз
Дөньяны, Илне?

...Сизәме тау — очып төшкән
тәмәке көлен?

*1989, 8 июнь*
*Казан*

* * *

Заманында манаралар кистереп йөргән,
мирас калган китапларны көл иттергән,
илдәшләрен җиреннән сөргән,
«кадим мәктәпләр»не дөмектергән
зур пенсияле «милләт хадиме»
алсу шәфәкъ яктысында,
сукыр килеш,
яшел мәчет түбәсенә
карап ята.

*1989, 18 июль*
*Казан*

## САЛЬВАДОР ДАЛИ ҮЛЕМЕНӘ

«Мине үлем ала алмый!»
дигән Дали да —
газеталар хәбәр итте —
киткән дөньядан...

Лоркалар белән исемең
калган иде кереп,
тик үзеңне исәнлектә
булмады күреп.

Үзеңнең дә безгә килү
булган теләгең.
Ничә әйтсәң дә, син бит әле
Казан кияве*!

* Хатыны — Галина Дмитриевна Казанда туган.

Бездә әйттеләр: Дали — сәнгать
хатасы! диеп,
сюрреалист каһәрләрнең
атасы! диеп.

Кемдер йөргәндә останың
«тетмәсен» тетеп,
Замана күптән таныган
даһие итеп.

Без фәкыйрь дә Мадридта
күргәзмәң күргәч,
шедеврларың тезелгән
залларда йөргәч,

Рәдиф* белән шаклар катып
тордык без икәү.
Менә Рухның нинди дә
була ала икән!

Хезмәте әйтә: Сальвадор ул —
титан эш аты!
Димәк, экспериментларга да
булган чын хакы!

Талант җанын аңлый алмас
тәнкыйтьче гыйбат.
Даһи теләсә ни кылсын —
нәтиҗә кыйбат!

Иҗатчы заман үзәген
ачык сиземләр.
Ничек чагылмасын анда
катаклизмнар?

---

* Рәдиф — Рәдиф Гаташ.

Сүз чыкса испан Пикассо,
Дали хакында, —
шул кавемнән искә төшә
безнең Бакый* да.

Күпме булды сәер хәлләр
шушы гасырда!
Эверест күк торып кара
тоеп барсын да...

...Инде гүр иясе булган
Сальвадор Дали.
Аның замандашы булдык,
ансы да ярый.

*1989, октябрь*
*Пицунда*

* Бакый — Бакый Урманче.

## ЭЗ

Җир. Галәм. Дөнья үзе
тора гел хәрәкәттән.
Җанлының һәр кузгалышы —
бер эз-юл — бәрәкәткә
яисә һәлакәткә...

Вакыт мәңгелек саналса,
тере матдә булса — җан,
гомер кардиограммасына
һәрбер эзең салынган.

Күзәнәкнең күчешен дә
Эз дип санарга була.
Иманлы икән — максат-эзең —
хәтта янарга була!

Бер максатка җиттем дисәң,
яңасы алга баса.
Эзләнү дә «эз» сүзеннән
алынган икән ләса!

...Сабый яңа тәпи баскан.
Җирдә беренче эзе!
Сизми — үзен күзәткәнен
бөтен дөнья күзе...

*1989, 7 ноябрь*
*Казан*

## МЕТАМОРФОЗА

**Яшьлек (иртә)**

Ай түгел, көн торып булмый
бер-беребездән башка.
Бар газапка да ризабыз
аерылудан башка.

**Ирчак (көндез)**

Ыгы-зыгы. Вакыт җитми, —
эш, аш, йокыдан башка.
Миһербанлы күзәнәкләр
үлеп баралар башта.

**Картлык (кич)**

Күмәклеккә омтылып,
яшь җан саташа башта.
Дөньяның гармониясе
фәкать тик ялгыз башта.

*1989*
*Казан*

* * *

Тамчыда да,
      күлдә,
          диңгездә дә
чагыла икән йолдыз —
ни гаеп! —
димәк, якты!

Яшьлектә дә,
      хәтта картлыкта да
яндыра икән сөю —
ни чара! —
димәк, татлы!

*1989*
*Казан*

## ТОПОНИМИК МОЗАИКА

*(Туган як)*

Биектаулар* кичмәсәк тә,
Күгәрчен очырмасак та,
Күкиләргә күктән төшеп,
Зәңгәр Күлгә чуммасак та, —

Балтачларда туып, балачакның
алтын тәхетендә утырдык!

Яңа Салалары — кала булган,
Ямашлары — күзне камаштырган,
Түләкләре — бүләк тоелган,
Кадрәкләр дә кадерле чакта —

Котлы Бөкәшләрдә бәхет юрап,
хыялыйлар булып укыдык.

Уракчыда — урак урылмады,
Тегермәнлекләрдә — тартылмады,
Көлдә көлчә пешереп ашап,
Кызыл Ярда ятылмады... —

Ә шулай да Шомыртбашта
миләш җыйдык бер яр белән!

Бөрсетләрдә бурсык тотар чорда,
Солтаннарда солтан,
Чаллыларда шанлы,
Үрнәкләрдә үрнәк булыр чакта —

* Баш хәреф белән язылган исемнәр авторның туган ягындагы, нигездә, Балык Бистәсе районына кергән авыл исемнәре.

Балык Бистәсенең балыгыдай
Казаннарга киттек кайнарга!

Гомер үткән саен газиз —
Корноухы, Ыргасы да,
Әшнәсе дә, Елгасы да,
Анатышы, Арышы да —
барысы да,
барысы да...

Кая барсам да каерылып
карар җирем — Туган як!

*1989*
*Казан*

## 90°

Ава агач.
Очы белән зәңгәр һаваларда
әйләнәнең чиреген ясап.

90°.
Биек булсаң —
егылып ауганда
зуррак чыга почмак-әйләнәң.
Биеклектән егылу авыррак.
Җил дә тибә сиңа ауганда!

90°.
Безнең гомерләр дә
сыя ласа
шушы чирек бүлем аууга:
вертикальдән — горизонтальгә.
Чирек бүлем: ел фасылы —
яз, җәй, көз, кыш кебек.
Тулы әйләнә кичтем дигән
табылырмы бер зат дөньяда?

Ә күпләрнең гомер тиз өзелә...
90° кискән өлге
аз чыга.

*1990, 6 май*
*Пицунда*

* * *

Дүрт кылым бар иде Сазымда,
Берсе сүзем иде — аңламадылар.
Берсе көем иде — тыңламадылар.
Берсе күзем иде — карамадылар...
Тик бер кылым калды хәзер —
ул — Син!

Туры карый алырсыңмы?
Тыңлый-тыңлый арырсыңмы?
Җанны аңлап карыйсыңмы?

Хак Тәгалә белә микән?..

*1990, 24 октябрь*
*Казан*

## БИЕКЛЕК

Тау өсләрендә наратлар
җилләрдә чайкалалар.
Очлары белән Күкләргә
нидер язмак булалар?

Бөркетләр узышып яулый
Күкнең яңа катларын.
Янәсе, киң офык күрсен
хакимлек канатларын!

Төнге күктән күп йолдызлар
атыла яна-яна.
Биектәнрәк төшкәне
күзләргә сеңеп кала.

Кеше дә үрләмәкче гел...
Ә рухының — үз Күге.
Кылган игелеге белән
үлчәнә биеклеге.

*1989—1990*
*Чегет — Казан*

* * *

Яшь вакытта — көчле чакта
дуслар йөзләгән була.
Сызгырсаң да кемнәреңдер
янга тезелгән була.

Куәт арта, дәрман арта
бер торып яткан саен.
Дус күбәя, сау тәнеңдә
күзәнәк арткан саен.

Шау яшьлектә ул шулай да,
олайгач — хәлләр бүтән.
Хәзер уйлыйсың: кем синең
хәлеңә керер икән?

Кемнәреңнең иңнәренә
кулны салырга икән?
Җилкәнле ялгыз көймәмә
кемне алырга икән?

Соңгы юлны уйла икән
акыл керә башлауга.
Лозунглар укыганчы,
өйрән кабер ташларын!

Гомер тегермәнен үтеп
мең өшегәч, мең янгач,
акылланмый, ялгызлана
адәм бер олыгайгач!

...Яшьлек — гомернең иртәсе.
Ә картлык — киче була.
Эңгердә дә табышалар
язмышы иш булганнар.

Шәфәгында таңны күреп
юанмаган кем генә!
Бик еш була: бер кешең юк...
Кала янда җил генә!

*1990*

* * *

Кирәктер карау да
таулардан — талларга.
Вакыттыр җандагы
дәрманны барларга.

Юл ач күңелеңдә
буылган салларга.

*1990*

## РӘСЕМ

Әни биргән бер карандаш,
бер бит кәгазь алда.
Нәрсә төшерим аңа?

Ник аптырап торырга,
баш кашып утырырга?
Нәрсә ясыйсым беләм —
кәгаземә кош төшерәм!

Тәвәккәлләп тотынгач,
булсын булгач —
сандугач!
Йомры башын төшердем,
томшыгын килештердем,
канатларын җәюле —
оча торган иттердем.
Кул белгәч, рәхәт кенә!
Тиз генә, җәһәт кенә
карандашымны йөртәм,
тәпиләрен җәпле иттем,
түшләренә миң төрттем —
рәсемемне өлгерттем!

Карадым барып читтән,
рәсемем ничек икән?
Уңга да чыгып карыйм,
сулга да чыгып карыйм,
карый-карый аптырыйм —
ошамый бит күңелгә.
Бу — сандугач түгел лә!
Әнигә әйтәм: булыш, дим,
әйтче, бу нинди кош? — дим.

«Бигрәк олы икән, — ди, —
карга түгел микән?» — ди.
Үзен бер дә күрмәгәч,
артыннан йөгермәгәч,
юньле-башлы белмәгәч,
китаптан укып кына,
җырлардан отып кына,
сурәтен тотып кына,
тиз генә, ансат кына
булмады ясап кына
кошларның мактаулысын.
Нишлим соң шулай булгач:
Сау бул инде, сандугач!

Яңа рәсем ясасам,
күргәнне ясаячакмын,
белгәнне ясаячакмын:
карлыгачны, чыпчыкны,
үзем ясаган ояда
кагынган сыерчыкны.
Йә булмаса, әбиемнең
кулындагы орчыкны...

Ясар идем әллә ниләр
әни биргән ак кәгазем,
карандашым бер генә...

Гомерем шул бер генә...

*1990*
*Казан*

## БОРЧЫЛМА!

Караңгы төннәрдә,
шомлы җил шавыннан
сискәнеп уянсаң,
кадерле кешең бар —
сыену табырлык,
юата алырлык
кадерле кешең бар —
борчылма!

Кайгылар ишәйгән
борчулы көннәрдә,
күңелең тулышып
сыгылып төшкәндә,
тураеп торырга
таяныр кешең бар —
борчылма!

Акылың җуярлык
шатлыклар килгәндә,
Җир хисен югалтып,
Күккә ашам дигәндә,
кочагыннан чыгармас
ышаныр кешең бар —
борчылма!

*1990*
*Казан*

## ҮКЕНЕЧ

Инде ашыкмасагыз да була.
Моңарчы ашыкмаганны...

Сез капка ачып
кергән чагында,
Газраил алды җанын...

Күз йомык.
Тән суык.
Дөнья сынык.

Тынлык...

*1990*
*Казан*

* * *

Ил хәлен беләсең килсә —
кешеләр йөзенә кара.
Җир хәлен беләсең килсә —
гөлләр күзенә кара.

Үз хәлең беләсең килсә —
халык сүзенә...

*1990, 11 октябрь*
*Казан*

* * *

Зәңгәр күктә бер ак болыт
җәйге эссе челләдә —
аккош булып тиберәнә
җәйрәп яткан күлләрдә.

Ә һәр күлнең үз юравы:
ак болыт — аңа гына!
Керфек-камышлар эченә
бу бәхет таман гына!

Шул уйда һәр тымызык су
үзе йөзендәгегә —
коедагы, буадагы да,
тояк эзендәге дә...

Ә болыт йөзә челләдә...
Күк йөзе — зәңгәр-зәңгәр!
Болытның да үз хыялы —
«Тулышып җитсәм әгәр,
ташлап бушлыкның катларын,
Җиргә төшеп килешкә
кушылыр идем, тамчы булып,
чишмәгә йә инешкә».

*1991, 9 апрель*
*Куктүбә*

## ШАГЫЙРЬ БУЛСАҢ...

Нечкә җанлы, чын иманлы
булып тууың кирәк.
Шатлык-кайгыңны аңларлык
җирлек булуы кирәк.

Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны халыкларның
күмәк тануы кирәк.

*1991*
*Казан*

## ГОМЕР — ОЧКЫН...

Төнге учактан сикереп очкын,
иярмәкче иде дә җилгә
(җилнең җилфер ялы мәңгелек!)...
Керфек тибрәнеп алганчы,
караңгыда эреп юк булды.

Тартыш-көрәш,
сөю-яну сыйган
безнең яшәү ләса бу мизгел.

Гомер сурәте лә бу очкын...

*1991, 11 апрель*
*Куктубә*

## АРКАНЛАНГАН АТ ЯНЫННАН ҮТӘ ИДЕМ...

Котырынып өскә килде ат.
Мин сискәнеп абынып егылдым.

Керфекләргә тияр-тимәс кенә
яшьнәп үтте күздән тояклар.

Шул дүрт бәкәл, шул дүрт тояк
җыйган иде дүрт тарафның,
бар дөньяның бөтен дәһшәтен!

Минем өчен бу мәл юк иде
сәясәт тә,
　　　　　ил дә,
　　　　　　　　сөйгән дә...
Ята иде җирдә ихтыярсыз
коты очкан тере бер «капчык».

...Ат ярсулы булган, ә мин гамьсез.
Күктә тургай иде, җирдә гөл.

*1991, 25 апрель*
*Куктубә*

## ЯЗГЫ БЕР ТОЙГЫ

Колакка тыгылган мамык күк
чокырлар эченә кар яткан.

Ләйсән ява коеп. Шул юештә
кызлар итәгенә ут капкан!

...Минем дә гамьле уй, онытылып,
яшендәй атылды яшь чакка!

*1991, 9 октябрь*
*Казан*

## СОРАУ

*Уянгач та бер хушаваз:*
*гөл... гөл... гөл... гөл...—*
*күңелемә сарыла гел!*

Син кем миңа? Чын исемең ничек?
Син дип —
үлеп терелимме яңадан?
(Миңа бик кирәкме яңа дан?)

Мин җавап көткән арада
исте назлы саба җиле
бөтен тәнемне,
бөтен җанымны,
бөтен гомеремне аралап.

Бөтен үткәнемне яралап...

*1991, 3 декабрь*
*Казан*

* * *

*...гә*

Бер-беребезгә артык якынлашмыйк!
(Ерагая башларбыз дип куркам!)
Хыял күкләренә менеп шашмыйк!
Син дә тукта!
Мин дә...
Тамчы күз яшь куйсын нокта.

Калыйк без Яшәү Картасында
сагыныплар көтәр якынлыкта,
гомер буе теләр ераклыкта!..

*1991, 9 декабрь*
*Казан*

* * *

Элеп киптер мине кер итеп.
Яфрак булып калыйм имиеңдә.
Тәмле төшең булып уятыйм.
Өмет булып куныйм иңеңә!

Мин барсына риза.
Кеше булып калсам,
япь-яшь җаның аша
янә күрсәм
хыялый таң —
Яшьлек чагымны.

Ә син әзерме соң,
яшел тирәк килеш,
зәмһәрир кыш урталарында
яланаяк басып торырга?

*1991, 28 декабрь*
*Казан*

## КАЗАН АЛДЫ

Казан арты! Казан арты!
Телдән төшмәгән яклар!
Булгандыр бит Казан алды
дип тә йөртелгән чаклар.

Кала түгел, абзарның да
була арты, ал ягы…
Фасад ягына эленә
һәр Ил-Йортның байрагы!

Казан алды! Казан алды!
Зөяле ул, Иделле!
Шушы якларны камады
яулар килеп иң элек.

Идел күрке булган Казан —
калаларның шанлысы.
Агым булып ташып төшкән
дулкыннарның канлысы.

Дошман явы җир җимертеп
аударгач Төп Капканы,
Казан алдында коелган
күпме асыл зат каны!

Казан алдында күпләрнең
яшәү җелеге кипкән.
Казан алдында Ил-бишек
ватылып-тузгып беткән…

…Фаҗига — башларны яргач,
зиһенне «ача» икән!
Җиңгәннәр — итеге белән
күзеңә баса икән!..

Шул чагында исән калган
калаламы калада?
Казан артына күчә Ил
арбада һәм чанада.

Көнчыгышка таба кемдер
җан саклап качып киткән,
кемдер, көч белән кайтырга,
үч белән ярсып киткән.
Киткән…
Киткән!..
Киткән!..

Инде менә ничә гасыр
Казан арты ал булган.
Шул төбәктә тамырланып
калган милли бар булган.

Без беркадәр белгән тарих
шушы якка тоташа.
Курсавилар, Мәрҗаниләр,
Тукай, Камаллар аша.

Бүген дә әле бу төбәкнең
байтак асыл затлары
арабызда. Эшләренә
мөһер — халык яклавы.

Тәкъдир итик, даннар юллыйк
шанлы Казан артына,
булган һәм янә булачак
Казан алды хакына!

...Менеп бас та, Сөембикә —
Хан мәчете кашына,
Казан алды әкият булып
җәйрәп ятыр каршында!

Бу иркенлек — безнең җир бит,
безнең җир бит бу Ватан!
Безнеке бит бу искән җил,
безнеке бит бу ал таң!

Казан өстеннән ераграк
күренә шул офыклар.
Бөек Болгарга табамы
ашыга бу болытлар?

Ярга каккан дулкыннарның
юлы дисез кайларга?
Агабазар аша күчә
борынгы Сарайларга!

Юлында — безнең зурлыкка
шаһит таулар, атаулар...
Күпме тарихи катламнар
безсез өнсез яталар!

Биеклектән тирәнлеккә
бак, ачылыр үткәнең —
Иделнең тулысы белән
безнең елга икәне...

Җанга, канга, җырга сеңгән
Иделе, даласы да...
Мишәре дә, типтәре дә
һәм нугай баласы да.

Теге чакта, Казан аугач,
дошман әйткәндер: «Бетте!..»
...Таш ярып гөлләр шикелле
яшь буын үсеп чыгасын
шәһитләр белми китте...

Казан алды алынды дип,
баскын туйлаган чакта,
Шомбай кебек, вакытлыча
бордырдык алны артка.

Алдыбыздан алынып килә
җәбер-золым япмасы.
Казан алды түгелме соң
Шәрык-гареп капкасы!

Казан алдында очрашыр,
ил-дәүләтләр кул биреп,
Сәяхлар сокланып узар:
«Татар иле шулмы?» — дип.

Хаклыкка йөз белән карап,
бәйсезлек яулаганда,
үз әләмебез астында
дөнья шаһит булырлык
көрәшләр тора алда.

Безгә күптән вакыт инде
бу дөньяның уңын-сулын,
алдын-артын аңларга!
Биеккә карарга өнди
манарада айлар да.

Казан алды! Казан алды!
Телгә менәчәк яклар!
...Тарихларда калып бара:
«Казан арты», «Казан арты!» —
дип кенә әйткән чаклар.

*1991*

## КҮРЕНЕШ

Балконнан карап торам.
Күләгәң очында кош тора.
Үттең киттең...

Кош калды асфальтлы җирдә.
Сурәтең калды күңелемдә.

*1992, июль*
*Бурса (Төркия)*

* * *

Язмышымда упкынмы син?
Әллә — төп терәк?
Ирексездән тамыр җәйдең
җанда Гөлтирәк!

Болай да ярсулы йөрәк —
булды куш йөрәк.
Сине кисеп ташлыйм дисәң —
куш кылыч кирәк!

Теләсәм, андый кылычны,
бәлки, табармын...
Тик аны үз күкрәгемә
ничек кадармын?

*1992, июль*
*Конья (Төркия)*

* * *

Күчә чирләр. Күчә илләр.
Күчә утраулар су өсләп.
Күчә хәтта таулар җил белән...

Беркая да күчми күңелемнән
(синең белән икәү
дүрт күз белән күргән
яшьлектәге илаһи сурәт).
Кызыл Байрак яры астындагы —
тын Иделдә
җәйрәп яткан көмеш табак ай!

*1992, 15 август*
*Юлсубино*

## БЕР АГАЙ СҮЗЛӘРЕ

Ялган гаеп
чыннан безне
гарип иткән...

Шул ялганны
фаш итүе —
гаеп икән!..

*1992*
*Казан*

## ҖАНЫ КӨЙГӘН АКБАЙ ТУРЫНДА

*Камил туганым истәлегенә*

Халык чабышып
килеп җиткәндә —
өй кысасы янып беткән...

Авыл өстендәге ап-ак болыт
киезләнгән ысланудан, тончыгудан.

Халык аһ-ваһ килеп йөргәндә,
абзар-кураларга ут күчкән.

...Бәйдәге эт ярсый-сикерә,
өрә бөтен җанвар тавышы белән.
Авызында кеше сүзләре дә шәйләнә —
җан ачысы шулдыр инде.

...Чылбырыннан ычкындыргач,
инеш янына барып
кан коскан.
Күзләрендә ят кызыллык
әллә ничә айга барды.

...Вокзалларда, болын, мәйданнарда
чатыр корган качакларны күргәч,
янгын кичеп, чак котылган
шул Акбай-эт искә төшә.

*1992, 16 август*
*Юлсубино*

## ӘНИ ИШЕТМИ КАЛГАН ҖЫР

*Бар күңелләрдән җылы,*
*йомшак синең кабрең ташы.*

Г. Тукай

Яшь чакта, сау чакта
дәрьялар, диңгезләр кичәргә
ишкәк тә, каек та табылыр.
Давылда адашсаң,
караңгы төннәрдә яктыртып
әнкәңнең йөрәге кабыныр.

Яшь чакта, сау чакта
даныңа, малыңа, җаныңа
дуслар да, ярлар да сарылыр.
Хәсрәткә тарысаң,
догада, күкләргә илереп,
тик газиз әнкәең сагыныр.

Яшь чаклар, сау чаклар,
болыттай, мәңгегә кайтмаска,
җилләргә сарылып агылыр.
Ахыргы көндә дә
чәчәкләр күзендә күрерсең —
әнкәең карашы чагылыр.

*1992*
*Гәрәмәчкә (Балык Бистәсе) — Казан*

* * *

*Кеше ник дип өзә икән*
*үзенә иң газиз кылны!*

Үзем эшафот та,
кискеч балтасы да...

Җәллады да,
корбаны да —
барсы — Үзем...

*1992*
*Казан*

## САУ ЧАКТА
## ЯКИ «ШУЛ» ХАКТА

Җелеге суырылган Дәү Сөяк. Исеме дә бар: Р-л.
Бөтен күзәнәкләргә сүнгән йолдызлар тулган.
Күзләрдә генә икесе пыскып азаплана,
йөрәк тибә бугай. Балык саңагыдай —
бер кабарып ала күкрәк, бер иңә.
Аяклар камыр. Куллар эленеп тора (чөйдәге чыбыркы
сабыдай).
Бишмәт электерелгән бер төймәгә генә. Теләк тә,
хәл дә юк...

...Өйалды ишеге төбендә саубуллаштык инде,
бер ун тапкыр сарылып, кысышып бихисап...
Келәне күтәреп ачасы гына бар.

Ә ул һаман,
торса да читтәрәк, кулларын кушырып,
магнит сыман, җибәрмәскә тартып тора!

...Ниһаять, мин тышта!
Таң беленеп килә.
Морҗа түтеннәре шәйләнә.
«Шамук мәче»седәй кайтып киләм.
Коры салкынлыктан кар шыгырдый.
Шыгыр...
шыгыр...
шыгыр...
Калтыранып, өшеп атлыйм;
өстәвенә җил дә үрти күк:
«Берәр шигырь тумадымы, иптәш Шагыйрь?»
Ә кар һаман
шыгыр...
шыгыр...
шыгыр...

Ә шулай да,
Яшәү шәп бит,
анасын саткыры!

*1992, 8 декабрь*
*Казан*

* * *

Озак эзләдемме мин сине?
Әллә тиз таптым?..
Егермеләп еллар үткәч —
Инде очраттым...

Синең яшьнәп Дөньяга
килешең иде.
Минем, арып, Язмыш белән
килешү иде...

Син парлы була торып та,
канатсыз идең.
Мин җайдак була торып та,
...атсыз идем...

Дәрт очкыны чәчрәгәч
синең йөрәктән,
яшьлек таңы янә туды
минем күкрәктә!

Җандашлыктан игезәкләрдәй
охшаш ук булдык.
Бар вөҗүд бергә кушылгач,
тоташ ут булдык.

Ходай үзе өсти мәллә
хисне, теләкне?
Икебез бер, тәнебез
бер — куш йөрәкле!

Аякларың — «алтын кайчы!»
Кисә дә тора!..
Бәгырьеңдәге татлы «шартлау»
ыңгыраштыра!..

Озак эзләдемме мин сине?
Әллә тиз таптым?
Шунысын беләм: мин кич таптым.
Кичегеп таптым...

«Аралар юк, без — тиңнәр!» — дип,
рәхмәт, юаттың.
Мин дә, ахры, бәгыреңдә
нидер уяттым.

«Сөю — сәгадәт» дигәне
шушыдыр инде.
Син — Мәхәббәтемнең соңы —
«хуш»ыдыр инде.

Әйттең ничә, күземә карап,
айлы төннәрдә:
«Әйе, абыем! Бу хәлемдә
калам кемнәргә?..»
Үз соравым — башым ята
синең иңнәрдә.

Нидер әйтмәкчемен, булмый
аңлатып кына!
...Күрәсең, җавапны әйтер
тик Вакыт кына.

*1992*
*Казан*

* * *

Соравыма бик еш, тапкыр итеп,
шигырем белән җавап әйтәсең.

Мөлдерәп карап, «әй, абыем!» дип,
әллә нишләтәсең!

Бер гаепсез килеш оялам мин
ул җыр-шигырьләрнең
синең өчен булмаганы өчен.
Соңлабрак тумаганым өчен...

*1993, 14 февраль*
*Казан*

## УЛ КАМЫШЛАР...

*Камышлыкта танышмадык,*
*Без — шигырьдә кавыштык.*

Ул камышлар серлелеген
аңлар өчен яшь шул Син!
Гомерләрнең аермасын
тамырлары яшерсен.

Ул камышлар әйләндеме?
Безнең башмы әйләнде?
Күзеңдәге очкыныңнан
күңелемә нур иңде.

Ул камышлар колагыңа
миннән нинди сер әйтте?
Тәнеңнең калтыраулары
акылымны исәрәйтте...

Ул камышлар өскә ава —
билне ныграк кыс сана!
Тәннәр ялкын. Тирә-юньдә
тоташ яшел ут яна.

. . . . . . . . . . . . . . .

Ул камышлар сызлангандыр
сынганда, сыгылганда...
Кыяклар кисә бәгырьне
ө-з-е-л-е-п с-а-г-ы-н-г-а-н-д-а!!!

*1993, 27 август*
*Казан*

* * *

Байлыгыңны кочаклап ят
Картлык чүлмәгең белән...
Мин синең сатлык күзеңнән
кендегем белән көләм.

«Ялганчы!» сүзе дә сиңа
аз шул,— ярамас инде.
Әгәр Оятның күзе булса,
Сиңа карамас иде!

...Мин исә — түбәнлегеңә
биектән карап торам.
Тимим. Язмыш үзе сине
Вакыттан талаттыра.

*1993, август*
*Казан*

## ПАРАДОКС

Көтәсең газиз кешеңне —
бер имгәк шылтырата...
Ялманып алтын эзлисең —
алдыңда нәҗес ята.

Җилләр белән җыр юллыйсың —
ул гайбәт булып кайта.
Хәер бирсәң, кыйбаткарак
үзеңә китереп сата.

Бераүгә икмәк сузасың —
ә ул сиңа таш ата...
Гавам җанын пакьлим дисең,
ә ул — күзен акайта.

Изге хөрлеккә өндисең —
вәхи сүз ката-ката:
Ыржаеп Тарихи хата
ботын күтәреп ята.

*1993, 1 сентябрь*
*Казан*

* * *

Тапканга артык сөенмим.
Соңрак күбрәк югалтам...
Ни бәрабәргә икән дим,
Сине бүләк итте таң?

Якты чакта көне буе
Сине уйлап егет мин.
Төнен «тота», сискәндереп,
Картлык дигән рэкетмен.

*1993, 13 сентябрь*
*Казан*

* * *

Качар җир — убежищелар
нәрсәгә ди миңа?
Иң хәвефсез урын — ул бит
Синең куеныңда!

Күкрәгеңә терәлеп бер
йоклап киткәнмен дә,
төш күрдем: имеш, бер тиен
зур бер куш имәндә
нигъмәт җыяр куыш тапкан,
өй булыр дип кышкы.

...Ә төптән кисеп яталар:
чыж-чыж килә пычкы!

*1993, 14—17 сентябрь*
*Казан*

* * *

Көтмәдекме безне баскан
басымның басылуын?
Җанга, рухка, хөр фикергә
юлларның ачылуын?

Көттек. Көттек... Ниһаять,
күзләр шәрран ачылды.
Күз алмасына шәп-шәрә
чынбарлык кереп тулды.

Кануннар шартлап ярылды.
Ил-җирләр тетрәнде.
Әләм-әтрәкләр көрәйде,
хезмәтле — бөкерәйде...

Империя коллыгында
гел күнеккәч искегә,
«Демократия»сеннән дә
юылмаган ис килә.

Әче төтене заманның
күзләрне ачыттыра!
Яхшыга да, Яманга да
капкалар ачык тора.

Ә Вакыт ашыктыра...

*1993, 18 сентябрь*
*Казан*

* * *

Авыл чите. Инеш буе.
Яшел чирәм — язгы ямь.
Яңа бура күтәргәннәр
гәрәбә бүрәнәдән!

Бу бурага кояш үзе
төшеп утырыр сыман.
Бала-чага уйнап йөри
йомычка арасында.

Сары каз бәбкәләренең
хуҗасы тилгән түгел!
Ак яулыклы әбиләрнең
күзләре чөйдә түгел!

Тал «песи»ләре ачылган
җылы җилләр иркенә.
Тургай моңнары коела
ак болытның читеннән...

Колакта — чишмә чыңлавы.
Борында — коймак исе.
Изге Рамазан ае бу,
иртәгә Кадер киче!

Авыл чите. Яшел чирәм.
Инеш буе. Ак бура.
...Еллар үтә. Ә шул бура
һаман күңелдә тора.

*1990—1993*
*Мамадыш*

* * *

Сабыйдай сөенәм кайчакта, югалткан
юк кына бер нәрсәм табылса.
Уйланмый еш кына, ни бәхет икәне —
әниең, әтиең сау булса!

Күпмебез бичара хәлендә калабыз,
югалту убылса һәрьяктан.
...Исәннәр аңа дип багышлап юллаган
догасын тапмаган әрвахтай.

*1993, 26 сентябрь*
*Казан*

* * *

Мин, бәлки, бер бөртек
яшеңә тормыймдыр?..
Ә Үзеңә торам!

...Безнең озын гомергә —
бер кыска юрган.

*1993*
*Казан*

* * *

*Галәмдәш —*
*замандаш —*
*илдәш —*
*милләттәш —*
*кардәш —*
*кандаш —*
*җандаш...*

Нәрсә әйтим?
Рәхмәт! диям Сиңа —
Төнге яңгыр шавын тыңлап, изерәп
упкындагы чыра яктысына
дүрт күз белән
карый алгач!

*1989—1993*
*Казан*

## БЕЗНЕҢ ТАЙ

Су эчте дә җирән кашка,
таена карап алды.
Башын иеп, баласының
маңгаен ялап алды.

Колын сыенып торды да
әнкәсенең ялына,
әй, сөенеп чабып китте
безнең ишек алдында!
Тавык-чебешләр сибелеп,
тирә-юньгә качтылар.

Акбай, койрыгын кысып,
посты капка астына.
Бер почмакта велосипед:
«Бу ни хәл?» — ди аптырап.
Гараждагы машина да
тора ярыктан карап.

Ә колын бии — уйнаклый!
Ишек алды тар, диме?
Койма аша сикереп чыксаң,
иркен дөнья бар, диме?
Колын дисәң дә колын шул!
Тай дисәң дә тай инде!
Ат булып җиткәч, үзенә
атланып чапсаң иде!

Чапсаң икән офыкларга
болын-яланнар буйлап!
Их!
Беренче булып бәйгедә
килергә Сабантуйда!

Җирән кашка кешнәп куйды.
Колын йөгереп килде.
Әнисе, иелеп аңа,
ахры, «ял ит!» диде.

*1993*
*Казан*

* * *

Мин хәтта —
юньле төш күрмәдем Дөньяда!
Чынлыгы булды — иң яман!
...Уйласаң, лаек та мин моңа.

Булганы —
бик таман.
Бик таман!

*1993*
*Казан*

## КӨЗГЕ КҮКРӘҮ

*«Мин Синең тормышыңа соңга калыбрак, гомереңнең көзенә табарак килеп кердем...»*

Хатыңнан юллар

Әйтәләрме — Сине яратты! дип?
Сөйлиләрме — Сине сөйде! дип?
Син горурлан! Сөйсәм-сөймәсәм дә
тормышыма инде кердең бит!

Тавышыңнан — балачактан калган
бер кадерле өнне шәйләдем.
Күз карашың Кояш булып торгач,
мин Йолдызга, ахры, әйләндем.

*1992–1993*
*Казан*

## «КЫЕК АТЛАМА»ГА КАРАП*

Ташкүмер күк тере,
үзе соры,
уалучан көлсу туфрак.

Түбә-сырттан шуа як-яклап
(көшел өслегенә менеп баскач,
ашлык шулай коела ындырда).
Шыбыр-шыбыр...
            Шыбыр-шыбыр...

Талгын яңгыр шавы чыгарып
коелалар нәни кантарчыклар.
Тәгәриләр аска —
Кара диңгез дулкыннарына —
Көн дә, төн дә,
               таң да,
                    кич тә...

Чик-ахыры булыр хәрәкәт.

Сәбәп итеп —
            җилләргә сылта,
                  куныт-куныт алган бөркетләргә,
                       очкычларның вибрациясенә...

Ишелү ул — барыбер ишелү...
Сырты һаман тәбәнәкләнеп
чүгеп, сүнеп бара кыя-тау.

* «Кыек атлама» — Кырымның Күктүбә култыгындагы кыя-тау (руслар «Хамелеон» дип йөртәләр).

...Беркөн монда
(бер гасырдан, бәлки, күбрәк?..)
тау урынында
зәңгәр рәшә торыр тибрәнеп.

P.S.: Тик кем карар, күрер икән?
Бу җир хуҗалары — татарлармы?
Килмешәк оныкларымы?
Әллә,
Бөек Фаҗигаләр булып,
адәм заты барын оныткан
әкәм-төкәм, елан-чаянмы?

*1990 – 1993*
*Куктубә – Казан*

* * *

Серләреңне әйтеп
бетер дисең...

Юк!

Ләхет кортларына
калсын кайберләре!

Йолдызларга күмелде
Йөрәгең...

*1994, 4 гыйнвар*
*Казан*

## КИЛДЕ ЧАК...

Килде чак:
адымнар санар чак.
Көчне чамалар чак.
Сак чак...

Хәтер канатында
кайчак
ялкынланып ала
Яшьлектәге учак.

*1994, 29 гыйнвар*
*Казан*

## КАР ТӨШЕРӘМ ТҮБӘДӘН

Кар төшерәм түбәдән, кар төшерәм.
Куеннарда назлы март җиле!
Шул карлар күк иңнән елларның
бер кадәрен төшерәсе иде!

Ә түбәнең кояш төшкән ягы
күптән кибеп, инде ялт иткән!
Гомер төшлегеңне бер уздыргач,
гел «I love you»лар* оят икән…

Күләгәле якта кар катламы.
Шул якны бит кирәк көрәсе!
…Ә шулай да, яшьне тыеп, килә
Кояш якка карап көләсе!

*1994, 3 май*
*Казан*

* I love you (инг.) — мин сине яратам.

* * *

Мин карт булам яшәрмәгәндә.
Яшәрмәгән көнем бик сирәк!

Кемдер көлемсерәп әйтеп куя:
«Агай, сиңа күптән шул кирәк!»

...Белми алар —
Миңа Син кирәк!

*1994, 22 май*
*Казан*

## ГЕЛ «ҖИҢҮ»ДӘН ТОРГАН ГОМЕРЛӘР!

Торабыз, имеш, Күк катларында
чиратта.

Киенеп-ясанып килгәнбез.
Тагын чыктылар медальләр
«Әрәм үткән гомер өчен!»

*1994, май*
*Казан*

## ҖУЙМАГЫЗ МӘХӘББӘТНЕ!

*(Җыр)*

Алуын алдым
гөлләрнең алын,
туйганчы карармын дип.
Көтмәгән идем
сөю утында
тагын бер янармын дип.
Җирдә ямьнәр арттымы,
җанда гамьнәр арттымы
минем бу
соңарып
шашудан?
Ә синең күңел каткан,
яшь килеш төрле яктан
очраклы
җилләргә
ачылган...
Үкенү дә юк,
үтенү дә юк
җанда бушлык та аклык.
Күңелләр бизгәч,
ахырны сизгәч
аерылышу да шатлык!..
Җирдә ямьнәр арттымы,
җанда гамьнәр арттымы
минем бу
соңарып
шашудан?
Күкләр күкрәде аңлап,
гөлләр тетрәнде аңлап
әрнүле
күңелем
ярсудан.

Гомерләр үтә,
уйлап кич-иртә
кайтам яшьлек таңына.
Ялгышларым да,
сагышларым да
кабат килә аңыма!
Тере күбәләк кенә,
тәүге мәхәббәт кенә
күңелдә,
җилпенә,
кагына.
Бул икән нык һәм көчле
Таһир-Зөһрәләр төсле
беренче
мәхәббәт
сагында.

*1994, май*
*Казан*

* * *

Һәр зат Җирдә тигез булса —
кыя-таулар бөгелеп килеп,
үзәнгә тулыр иде!

...Каргалар шигырь укыса —
күгәрчен булыр иде!

*1994, 11 июль*
*Казан*

## БЕЗНЕҢ КӨННӘРГӘ БЕР ШТРИХ

Урылмый калдылар игеннәр.
Кыраулар өшетте мул кырны.
...Базарның чатында угрылар
гармунын алдылар сукырның.

*1994, 21—23 август*
*Гәрәмәчкә (Балык Бистәсе)*

## ЯШЬЛЕК ДӘФТӘРЕНДӘ БЕР РӘСЕМ

... Ак кәгазьнең уртасында
офыктан калыккан болытлар.

Ул чакта ук — ясагач та —
бу болытлар сурәтендә
берәр чалым шәйләдем микән?

Еллар үткәч,
ничектер бер күз төшкән иде
әлеге шул таныш кәгазьгә.
Бакчы, бакчы! — болытларда
Синең профиль икән бит!

Менә бүген, чал чигәмне тотып,
янә актардым шул дәфтәрне.
Әлеге рәсем —
коеп куйган Синең силуэт!

...Дулкынланып
күрсәткән идем
Сине белгән танышыма:
«Эскерткә охшаш
әллә нинди шәүләләр...» — ди.

*1990—1994*
*Казан*

## АЙНУ ЯКИ ТАРИХИ МАХМЫР

*Җир кемнеке булса,*
*җил — шуныкы.*

Кайта татарлар, кайталар
ата-баба җиренә.
Күзләрендә өмет булса,
хәсрәтләре — иңендә.

Ничә гасыр «китү чире»
әйләнгән бер йолага.
Заман-Җиһан тоткан халык
«артык» булган Дөньяга.

Илнең зурлык-хурлыгы да
барсы бу Җирдә икән!
Башың Күккә тигәндә дә,
егылмам димә икән!

Бармы җиңгәннәрнең Җирдә
яшьтән, каннан туйганы?
Җиңелгәннең нәселен кортып,
буганнар да суйганнар...

Кол калганын, бил бөгәргә
җәһәннәмгә куганнар.
Туң якларга, чүл якларга
илтеп олактырганнар.

...Петрбур нигезендә дә
күпме ята туганнар!
Соңрак чорда «вербовка»га
«ирекле» кул куйганнар —
кем иленә йотылдылар
ул — меңнәр, миллионнар?..

Туган илдә бакча-җирләр
һич иясез калмаган.
Җир-суларны баскыннарның
утарлары камаган.

Гөмбә шикелле калыккан
«тавык тәпи» — чиркәүләр.
Чукынып «икеле» булган
Җәүдәт атлы Җәкәүләр!

...Җирләр киткән. Геннар кипкән.
Боз утырган бәгырьгә.
Тик илбасар «дуслыгы» да
түгел икән мәңгегә!

. . . . . . . . . . . . .

Кайта татарлар, кайталар,
берәмләп, кумәкләп тә...
Тик шунсы бар: «кара сакал»
һаман да килә рәттән.

Үргә йөзгән балык хәле:
куп газап кайтыр юлда!
Йөзгән-йөзгән — чәчәр өчен
юк бит уылдыгы да!

Киткән чакта — Яшьлек киткән.
Кайта — күбрәк Картлык...
Әллә таңнарга моңсулык,
әллә шәфәкъка — шатлык?

Тир түктеләр ят җирләрдә
маңгай җиргә тигәнче.
Картаеп бөкерәйгәнче,
«килмешәк сез!» дигәнче.

Кылган хезмәтләре, бәлки,
торырлыктыр да җырга —
кайтыр мөлкәтләре сыя
бер-ярым контейнерга.

...Кайта татарлар, кайталар
Азиядән, Кавказдан —
«Советлар мәмләкәтенә
мәңге хөрмәт, мәңге дан!»

Кала өйләр, кала йортлар —
гомер буе казганган.
«Балаларыма ни диим,
шундый язмыш язганга?»

...Бер агай белән тордым мин
басып вокзал янында.
Еллары үткәндәй булды
поезд вагоннарында.

Ярты малы ватык килгәч,
«ах» дип сукранмады.
Мондый чакта юатмыйсың,
кирәк бары аңлавың.

«Малым түгел, гомрем әрәм,
читтә үткән — яшьлек җәл!
Калган нәселемә килсен
Туган җиремдә әҗәл!»

Күктән — белепме, көлепме? —
Ярым Ай карап тора.
Гүя әйтә: бу кавемгә
айну да ярап тора.

*1994, август — ноябрь*
*Азнакай — Казан — Балык Бистәсе*

* * *

*Куңелем Ленин белән сөйләшә.*

С. Хәким

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит ничек буласын
соңгы көн, соңгы төнем...

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит нигә әйләнер
Илем, Телем һәм Динем...

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит, бу уйланулар
әллә төш, әллә өнем?..

*1994, 3 декабрь*
*Казан*

* * *

Сезнең урам аша үттем бүген.
Тәрәзәңдә калды күзләрем...
Керфекләрем йомып нидер әйттем,
хәзер хәтерләмим сүзләрен.

Шактый ара бардым белешмичә,
хатирәләр алды бөтереп.
Ул елларның асыл бөеклеген
мөмкин түгел аңлап бетерү.

Булган Яшьлек, булган чын Ярату
һәм Яңару булган һәрдаим.
Нәселемнең ни догасы өчен
бүләк иткән Сине Ходаем!

Кеше гомеренең буладыр ул
Бәхет тажы иңгән бер чагы!
Әйтүчеләр булды: боларның бу —
сүнү белмәс Сөю учагы!

...Хатирәләр, татлы хатирәләр
керфекләргә дымны тарата.
Казан нинди мәрхәмәтле булган
бу йорт аша безгә карата!

...Калтыранып куйдым. Әйтерсең лә
кышка кердем җәйге киемнән.
Кире килгән чакта караңгы иде,
мин таксида кайттым өемә.

...Төн уртасы. Йоклый алмыйм,
мең-мең сорау биреп үземә.
Сиңа, хәзер, бәлки, Ай карыйдыр
тәрәзәңдә калган күземнән...

*1990 — 1994*
*Казан*

* * *

Кояш бата...
Нарат очларында гына
соңгы нурлар әзрәк янасы...
Тиен булып сикереп, шул нурларда
килә иркәләнеп каласы!
Әнкәй күзләрендә соңгы якты сүнә...
Ярты дөньям сүнә... Шашырлык!
Юньле гамәл кыла алырмынмы Җирдә —
теге дөньяларда кавышырлык?..

*1994, июнь — декабрь*
*Октябрьск (Башкортстан) — Казан*

## ТРИУМФ ЯКИ КҮРЕНЕШ

Ятактагы бу ак җәймә,
без төйнәлеп әүмәкләшкәч,
нишләгән соң?

Пешекләгән карта сыман җыерылган.
Янып тамган тир-тамчылар парланып тора.
Тез башлары төйгән урын —
бомба төшеп убылган күк чокырайган...
Җиңүемә әзерләгән ак әләмең — шушы җәймәң.
Мунчаладай җәйрәп ята. Бөек сурәт!

...Ай янында нәни ак болыт
тәрәзәдән күреп манзараны,
соклануын (көнләшүен?) җилдән әйттерде:
«Җирдә тормыш-хәят бар шул ул!»

*1994, июль — декабрь*
*Казан*

## ҖӘЙ АХЫРЫНДА ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ ЯКИ ЮБИЛЕЙДАН СОҢ

Качарга миңа, китәргә
бу чытык кәефтән!
Дөрес, мин картлыкның
җәтмәсенә эләккән!..

Йә Хода, мин генәме
ярты гасыр кичкән?
Ә кемнеңдер ул гомерен
төрмә-зиндан «эчкән»...

Гыйбрәт ал ятимнәрдән,
гарипләргә кара...
Нәселеңнең агымында
син әлегә — кораб!

Сөенә бел, бәйдә түгел
«чатлы багана»да.
Син һаман үзәктә әле
Җиһан яңарганда!

Кирәксә — тау бул, кирәксә —
үзән булып кал.
Кешеләрне рәнҗетмичә
Үзең булып кал!

Онытма, син Мәхәббәттә
сәбәп кенә түгел!
Шигърият язмышында
сәдәп кенә түгел!

Сулышыңа карап җырла,
күрсенмә йә күрсен.
Язмыштан телә бер теләк:
җиңел үлем бирсен!

*1992—1994*
*Юлсубино — Гәрәмәчкә*

* * *

Бетте ул,
бетте ул,
бетте ул
Кешегә ияреп көлүләр!

Болай да артымда бер көтү
тилеләр шаркылдап йөриләр.

*1994*
*Казан*

* * *

Яшь чагында һәр нәрсәне
өйрәнеп була кебек.
Теләсәң, патша кызына
өйләнеп була кебек.

Теләсәң, дистәләп телне
су кебек эчәр кебек.
Гашыйк булгач, алларыңа
йолдызлар төшәр кебек.

Телә икән, Олимпларда
син — барсыннан көчлерәк!
Бу дөньяда тумаган ди
синнән дә бәхетлерәк...

Әйди сине хыял көче,
йөртә сине җилкенү!
...Яшьлек белми шул Гомернең
үтәчәген җил кебек.

Бер көн сискәнеп куясың —
гомер-шәм янып бара...
Хыялдагың — бүгенгә юк,
иртәгә калып бара...

Ир булсаң, кулдан килгәнен
хәзер үк эшләп кара!
Күкләр яңгырап дәште:
әйдә,
нәсел җебеңә янә бер
ялга бер бала-тамыр!

...Бу сүзләр раска килсен дип
яуды өскә ләйсән яңгыр.

*1994*
*Казан*

* * *

Париж түгел, Пар-Иш!
Безнең атамабыз!

Иш-Пар булып яратканнар
безне — Ата-Анабыз.

...Шуңа да Ир белән Хатын
диеп аталабыз!

*1995, 15 гыйнвар*

* * *

Иштем дә,
тиштем дә —
эскерт түбәсен.

Иштем, иштем дә
күрдем саламда
тычкан койрыгын.

Ишеттем иртән
түрә боерыгын.

Кичен килеп бастым
ишкән җиремә.

Бер песнәк кунды
килеп иңемә...

*1995, 10 февраль*
*Казан*

## БЕЛАЯ ГОРЯЧКА

*(УЗИ аша үзебезгә үзгә бер караш)*

*Бу юлларны язган чакта*
*якты иде утыбыз!*
*Килешкән җирләре булса,*
*килешмичә укыгыз!*

Белая горячка!
Кызылы юк бит...

— Белая горячка!
Пора кипучая!
Хотя и синею —
зато могучая!
Бас, Ахмет, Апипа!
Син басмасан, мин басам!
Зачем мучаешь меня ты,
если баса алмасан!..

— Без яшибез, без яшибез
самый Бәхет илендә!
Типтереп калыйк әле
ике «дәүләт» телендә!

Акыл, диләр, — көчтә!
Тозлы кыяр — өстә!
Дәүләтчелек — төштә!
Кануннар — аста...
Селәгәй малайлар
менеп басты башка!
...Без яшибез әле!
Налей-ка, Машка!

Китсен әле башка!
Селедка астына
гәҗит кирәктер бит!
Андагы указлар
акыл өйрәтерләр!

Белая горячка!
Кызылы юк бит...
Дөнья болай барса —
кызыгы юк бит!

Тургай канатларында үсә бәяләр.
Суырылган теш хәлендә карт-коры ветераннар.

Ясалып бетмәгән ясалма дебиль балалар.
Ә сауларын... «кайнар нокталар»га салалар!

Руханилар ботарлаша берсен-берсе
(Мәккә ташы — «Лобное место» түгел дә бит...)

Хәерченең калтыранган сул кулында — тиен акча,
уң кулында — шәфәкъ нуры...

«Уятмакчы булсаң халык күңелләрен» —
барып кайт син Салмач ягына...

Мадьяр казларына — «Пионер» кукурузы ашатсаң?
«Монитор»да безнең өмет!..

Милли сәнгатькярләр «Просто Дурак»
«Просто Мария»не үпмәгәч... Махсус рейсларда
үтмәгәч...

Яшь Тукайлар!
Тамагыгыз туяр иде — хет башкортча иҗат итсәгез...

Җиңү бәйрәмнәрен үткәрәбез! Җиңелгәннәр акча
бирсәләр...

Урак-чүкеч берлегендә хәзер урак кына һаман ура
шул...

Ике-өч катлы коттеджлар витражында —
юксылларның, сабыйларның күз яшьләре...

(Фасоль — борчак, ясмык — борай... Бүрттерергә
бар да ярый...)
Хәтер Көнен бинокльдән караганчы
Зиратларга барып килсәгезче!

Сандугач тамагын корыткан нефтьле суларда
салават күпере көнен дә, төнен дә...

«Төрмәдәме? Парламенттамы?» диеп әйтте берәү
трамвайда —
татуировка япкан бер бәндә.
Әйдә, Сонц, уйна! Тирә-юньдә «Симха» ярый +
«семь сорок»!

— Эй, Ахмет, Ахмет!
Где твой ответ?
— Атаң урыс булмагач,
Наташадан тумагач —
булмый инде булмагач...
— Я же жду...
— Әйдә, актив булыйк әле,
тиздән җитәр
«демократик» сайлауларда!

— Кайда?
— Алда!..
— Нәрсә?
— М… да!

— Налей-ка, Машка!
Пусть загудит башка!
Син бит «өлкәншә» дип
язылган ди ташка…

Белая горячка!
Белая горячка!..

— Где мой бумажник?
— Где мой паспорт?
— Кая Шартнамә?
— Разве прошли Дни?
— Кая безнең халык?
— Причем Дудаев?
— Я говорю: Басаев!
— Ты сам Басмиев!
— Нацменга тимә!
— Где мои трусы?
— Где мои очки?
— Хватит!
— Точка!

Белая горячка!
Белая горячка!

*1995, март*
*Казан*

* * *

Күрдек.
Сөйдек.
Булды...

Ә хәтерне
яңартырга һич вакыт җитми!

...Шул гадәтне белеп микән кызлар
безгә хәзер кулъяулык чикми.

*1995, 10 апрель*
*Гиссен (Германия)*

## СИН ӘЛЕГӘ ЯШЬРӘК БИТ!..

Күзге кара төндә тамды күз яшем.
Нидән тамды?
(Ак кәгазьдә йолдыз чагылды.)
Искә алдыммы —
Вакыт — бәләк-чукмар булып —
тетеп, сытып киткән Гомерне?

Язгы алсу таңда тамды күз яшең.
Нидән?

*1995, 10 апрель*
*Гиссен (Германия)*

* * *

О, сәрдә үләне!
Күз-кышын төшләргә кергән
беренче язгы аш!

Насыйп икән
герман җирендә.
Эрфурт.
Шәһәр чите.
Тау буе.

Иелеп өзгәч тансыгымны,
тураеп басып караган идем,
офыкта калкулык — Бухенвальд.

Иренемә алу түгел,
кулымнан ук төшеп китте
быелның
беренче
ымсынган үләнем.

*1995, 11 апрель*
*Эрфурт (Германия)*

## ЧЫН ТӨС СОҢРАК...

*(Яңа кабер)*

Яңа гына сары балчык өеме иде.
Көрәкләр биегән өслектә —
әнә хәзер кызыл гөлләр.

Чын төсләр соңрак булыр:
җәен — яшел,
кышын — ак кар
бераз инде утыра төшкән
озынча түмгәктә.

*1995, 12 апрель*
*Веймар (Германия)*

## СИСКӘНҮ

*— Икебезгә бер очтан кистереп алдым.*
*— Бергә күммәсләр шул.*

Фараз-диалог

«Мәңгегә бергәбез!..» диеп,
кәфенлек бүләк иттең.
«Мәрмәр!» дип йөргән күңелне
бу гамәлең көл итте.
Вөҗүдне өнсез итте.

Ир булыйм дип, җавап итеп,
Сиңа гөл бүләк иттем.
...Соң эшем: ләхет катында
яңа чәчәкләр көтү.

*1995, 28 апрель*
*Казан*

* * *

Төрле чагым булды —
ярлы, бай чагым...

Ә күңелдә һәрчак
Шатлык йөрттем
яшереп тә...
Ә кайчакта —
бар дөньяларга кычкырып!

Шул коткарды мине
бүгенгәчә.

*1995, май*
*Казан*

* * *

Алма апай. Туган апай.
Матур апай. Чибәр апай. Бал апай...

Малай чакта
Кояш кебек апайларның
һәрберсенә гашыйк идек!

...Кайттым быел җәй авылга.
Капка төбендә утыра карчыклар.
Муеннары — алда, җилкәләре — артта.
Куллары (гафу!) —
кипкән гөберле бака...

Ак яулыкларында — чәчәкләр.
Ә чыннары — бакчада ата.

Алма апайның итәгендә
зур бер матур алма ята...

*1995, 27 май*
*Аккош күле*

## МЕТАМОРФОЗАЛАРДАН

* * *

Тау убылып, үзән-чокыр булды.

Түбән биеклекләр эзләп микән
йолдызлар төшteләр коенырга
шаулап узган яңгырдан соң.

* * *

Шау яфраклы имән идем.
Син китергән хәсрәттән
чыпчык кунмас
шәрә ботак калдым.
Күңелем катты
чакматаштай.
Кабынырга
теләк, көч тә юк...

*1995, 31 май*
*Мәскәү*

* * *

Минем таралган салларым бар.
Төшләремдә шуларны җыям.

Үскән җирләренә илтеп
утыртамын агачларны.
Төпләренә сулар сибәм,
ботакларын ябыштырам.
Яфракларын ялгау —
ансы — яз эше.

Өннәремдә
гомрем буе җиһан буйлап
сүзләр җыям күңелемә.
Бәгырьләргә үтәрдәйләреннән
оран салам!

Милләттәшләр, кан кардәшләр
җыелыр дигән өмет белән
Дәүләт дигән Сабантуйга.

*1995, 3 июнь*
*Мәскәү*

## ЧЫН АККОШ КҮЛЕН САГЫНУ

Нарат исле талгын җилләрдә
Аккош муеннары иркәләнгән!..
Канатларында — салават күпере!
Йөзгеч тәпиләре — көзге булган купшы
алтын балыкларга!
Камышлар — сөңгеләр илаһ ямь сагында...

... Хәзер әнә этләр коена.
Яр тулы чүп. Шешә ватыгы...
Күңелләрдә — рәнҗү. Колакларда —
исерекләр сүгенүе,
бульдог, овчаркалар һау-һавы...

Бер юаныч:
су йөзендә элеккечә
каеннарның ап-ак сыннары,
болытларның талгын шәүләсе.

*1995, 25 июнь*
*Аккош күле*

## ТӨН

Шакал корбанын ботарлады да,
лакыл булгач, канлы бугаз белән,
Күккә карап сузып улады...

Ә Ай—болыт
арасыннан —
тулышып балкып тора!

*1995, 13 июль*
*Казан*

## ГЕЛ ТУЙЛАРДАН ТОРГАН ДӨНЬЯ...

Яшәүме?

Туу дигән Үлем башының
бер мизгел хәрәкәт уены!

Бәби туе — сөннәт туе...
Кавышу — никах туе...
озату — күмү туе...

Әй, бәби, әй, сабый!
Әй, егет, әй, туташ!
Әй, кардәш, әй, гүрдәш!...

... Күңелләрдән күчеп —
рәшәләрдә язып куелган (насыйпларга!):
Гомернең өч туе.
Гомернең өч туе.
Гомернең өч туе...

*1995, июль*
*Балык Бистәсе*

## ЭПИТАФИЯ

Мәхәббәт баласы булып,
тугансың бәхетемә!

Син исән чакта булганмын
Яшәүнең тәхетендә!

Рәхмәтем, сагышым булып,
нур иңсен ләхетеңә.

*1995, 7 август*
*Казан*

## УРАК БЕЛӘН ЧҮКЕЧ

Шигъри тел — бездән.
Моңлы көй — бездән.
Ипи-сөт — бездән.
Яшь солдат — бездән.

Гәҗит — сездән!

... Дөнья — тубыктан.
Тубык — диңгездә!

*1995, 10 август*
*Балык Бистәсе*

## КАРТЛЫК

Төнге аяз күк шәүләсе
кунган мәллә бу тәнеңә?

«Йолдызлары» гына никтер
тары ярма — соры тимгел...

Ә беләктә ярылып ята —
татуировка —
Күккә ашкан зәңгәр кошчык.

*1995, 17 сентябрь*
*Казан*

* * *

*Үпкән-кочкан —*
*жилгә очкан...*

Очуын очкандыр да...
тик җилләр, кире китереп,
янә бәгъремә сипкән!

Йокыдан татлы сагыш итеп,
янә Хәтеремә чиккән.

*1995, 23 сентябрь*
*Казан*

* * *

*Сәясәт — үзе бер ярминкә...*

Ярминкәләр! Ярминкәләр!
Кайсы Хөрмә тәгәрәп төшәр
бу Кызыл Кәрҗинкәдән?

... Чын гамәлең ни? дип бер көн
сорар бит Җир-Әнкәләр!

Ярминкәләр! Ярминкәләр!..

*1995, 3 октябрь*
*Казан*

## БӨЕК ЛӘЗЗӘТ

Фикер-уйларымның кәттәләрен, иң шәпләрен
җыймак булам каләм очына.
Юк килмиләр!..

Куып, күче белән килгән төнге уйларымны,
китмәкчемен йокы багына.
Юк, китмиләр!..

Кунак булып килмәүләрен,
чирү кебек китмәүләрен
газап дибез.

Ә шулай да,
Иҗат итү —
бөек ләззәт!

*1995, 15 октябрь*
*Казан*

* * *

Төн һәм Суык. Бу икәүдә
нинди дәһшәт көч ята!
Караңгылык һәм Салкынлык
Җиһанны калтырата!

Тик...
Чигенә алар: шом түреннән
Кеше чыга уртага.
Җир актарып, чакма ташын
яшен итеп, ут таба!
Ут — ул жиңү! Ут — ачык юл
Яктылыкка, Җылылыкка,
Язга — Кояшка таба.

*1995, 15 октябрь*
*Казан*

## УЛ ЧАК... БУ ЧАК...

Ул чак, юктан да бар ясап,
кызык-ямь таба идек.
Кызлар ярыктан да көлә...
Без дә шул чама идек!

Итәк җилпеп үткәннәргә
кызыгып чаба идек!

... Акча юк. Дөнья күргән юк.
Хыял — барсын тутырган.
Нинди тәхет бар Яшьлектә —
без — барсында утырган!

... Дәрман бар. Дөнья гизелгән.
Яшәлгән. Нигез корган.
Җәен баздагы кар кебек,
булган акыл утырган.

... Таңны Шәфәкъ белән бутап
теземне кочаклап торам.

*1995, 26 ноябрь*
*Казан*

## ТЕЛЕФОН

*Органнарда эшләгән*
*пенсионер сүзе*

Сөйләш син сак-сак!
Нәкъ дөресен чак-чак...
өстен-башын япкан,
«башлы кондыз» капкан
өй иясе — ябалак
тора көнең саклап,
тора төнең саклап!
Эч сереңне ваклап...

*1995, 27 ноябрь*
*Казан*

## ӘТИ ЯККАН МУНЧАДА

Мунча иркен! Эссе! Пар шәп!..
Җәлләмичә якканнар!
Бер кырыйда сөялеп тора
яңа нарат такталар...

Тиз арада кипсеннәр дип,
әти керткән аларны.
Ясамакчы икән язга
умарта оялары.

Үз җаена кибәр иде дип,
әйтеп кара — ни файда?
Кабергә куяр ташын да
ясатып куйды алдан...
Кайчан вакыты җитәрен
белә бары бер Алла.

...Чабынам шашып! Борында —
себерке, нарат исе!
Такталарга карыйм: парда —
күренә күк корт күче.

Мунча шәп! Рәхмәт әтигә —
бик вакытлы якканга.
Ни тора атылып чыгып
аунавы бер ак карда!

*1995, 29 ноябрь*
*Балык Бистәсе*

## МОРДАР

Гомерендә такмады галстук.
Көлде генә: муенны буа бит ул!

Наратлыкта илле яшьлек бер ир
билбавына асылынган...

Муенына ылыс кадалган...

*1995*

## СИН — БАР!

Сөяк атсалар да,
сөңге атсалар да,
сөяп атсалар да,
сөеп ятсалар да...
иелеп сәлам бирә
коллар —
патшалар да!

*1996, 27 гыйнвар*
*Казан*

## МӘДХИЯ

*Флерага*

Нәселебез бәхетенә
туган кыз бала Син!
Кама ярына куярлык
һәйкәл — Ана Син.

Күпмебезгә — һәр гамәлең
рух — көч өстәде.
Шәфкать фәрештәсе булса,
ул — Синең төстәдер.

Синең мәрхәмәтеңне
үзем дә күп тойдым.
Изгедер бу! дип, күңелемә
исемеңне уйдым.

Әрвахлардан — изге рух,
исәннәрдән — дога.
Бөек дигән тәгъбир бар бит, —
лаеклы Син шуңа!

*1996, гыйнвар*
*Балык Бистәсе*

* * *

Әй, бу Яшәү!
Шомлы! Тилерткәч кызык!
Илаһ көч йөри Биләүне
Кәфенгә кадәр сузып.

Таң, Шәфәкъ — кызыл. Арада —
Көн — ал-ак, Төн — кап-кара...
Мәхәббәт — Нәфрәт эчендә
саваплы булып кара!

Җитсәң дә Акыл тавыңның
биектәге читенә, —
Яшәү дигән Бөек Серне
аңламыйча кителә.

Шул сорау кала киткәндә
балаларның күзендә.
...Шундый ук вазгыять язган
аларның да үзенә.

*1996, 17 август*
*Аккош күле*

* * *

*Элеп киптердем мин Яшьлекне!..*

Борын юеш чактук,
үземә иш Яшьлек белән
ант итештек ташлашмаска.
Мәңге бергә! Гомер гомергә!

Заманында шәп яшәдек Яшьлек белән!
Мизгелгә дә яннан китмәде,
хыял канатларын үстерешт,
имтиханнар бирде минем белән,
кызлар озатышты таңнарда,
шатлык яше булып тамды чыкларга,
шигырьләргә сүзләр эзләште,
егылганда сырты белән башта үзе төште,
данлы чакта таҗны кигезде.
Хәтта кайчак: «Син — бөек!» — дип пышылдады.

...Һәм берзаман —
шул, шул Яшьлек
әйтмәсенме: «Китеп барам!» — дип!..
Ниндидер бер җилаяклы көндәш —
Вакыт-фетнә аркасында!

Кичерә алмыйм хыянәтне!
«Китсәң — кит!
Кит!
Кит!
Кит!» — дидем.

Мин шул килеш калдым —
күзләр генә уңды.
Мин шул килеш калдым —
кечерәйдем генә.
Мин шул килеш калдым —
пеләшләндем генә,
Мин шул килеш калдым —
туздым гына...

Кичерә алмыйм хыянәтне!
Мин Яшьлеккә рөхсәт итәм хәзер
төштә генә күренергә.

*1996, 23 август*
*Балык Бистәсе*

## КАЗАНСУ БУЕНДА

Үткән җәйне комлык янында
бер сабый җан батып үлде.

...Быел коры.
Су — чигенде.
Яр чүлләнде.

Ком тузанын җилләр очыра
Җир өстендә ятим калган
кемнәрнеңдер бәгыренә.

*1996, 24 август*
*Балык Бистәсе*

* * *

Иясез шатлык түгел хәзер.
Ияле шатлык булдым.

Пәрәвез җебеннән нечкә
Язмышым-сазым кылына
Кигәвен килеп кунды.

*1996*
*Казан*

* * *

Ялгызак иртәләр...

Кичләрен тәрәзә чиртәләр...

Сиг... ләр си...р дә китәрләр...

Юаныч: җәен дә, кышын да
күңелдә ямь-яшел болын бар!
Иртәнге энҗеле
ямь-яшел тугайда
тәгәрәп аунаучы колын бар.
Чынында — Улым бар!

Тагын бер юаныч:
Әлегә Дөньяда Мин дә бар.

(Ялгышма! Синеке түгел ул)
Алланың ихласый колы бар.
Тугры юлы бар!

*1996*
*Казан*

* * *

Тәннән аерылып чыккач,
кемнең җаны —
Күккә ашып, йолдызларга нур өстидер...

Кемнең — алай үрли алмый,
калай кәрнизләрдә,
карга ояларында каладыр...

Кемнең (хаиннарның, кеше гомерен
кыючыларның) —
Тәгәридер җәһәннәмгә —
нәҗес аккан торба, чокырлар аша...

...Ә әлегә утыралар бергә
челем тартып, җырулар җырлап...
«Бөеклекләр!» диеп лаф орып.

*1997, 1–2 гыйнвар*
*Балык Бистәсе*

* * *

Күз яшьләре бизе кипте.
Шаккатулар — бетте.
Тик исемен генә белмим —
ниндидер чак җитте.

Тсс!.. Исемен дә беләм!
Тик әйтмим генә!
Кешеләр бит халәтемне
бүтәнчә дип белә!

Кызык ул: юк тәкә башын
юк казанда булу!
Һәркемгә дә татымаган
яшь аралаш көлү!

*1997, 23 февраль*
*Казан*

* * *

Булсынга дип, тирләп-пешеп,
көн-төн эшләгән берәү.

Яшәп аргач, беркөн шаккаткан:
дөньялыкта бурычы арткан,
муеннан гөнаһка баткан...

Маңгаенда тимерәү...

*1997, 23 август*
*Балык Бистәсе*

* * *

Дөрләп янган зиратларны
сүндереп йөрүче без, имеш.

Бәгырең мең янып, мең көеп,
иманлы кала ал шул килеш!

...Күккә ашкан җаннарга ялвару:
«Безгә анда ни хөкем, ни өлеш?»

*1997, 2 октябрь*
*Казан*

* * *

Ул да вафат...

Әйттең шунда куркып-каушап:
«Юк! Юк, юк! Мин китмәм!»
«Озакка каласыңмы соң?» — дип,
җил сызгырды ишектән.

Кемгә — җитмеш. Кемгә — туксан.
Кемгә — унсигез генә...
Вакыт, иләп гомерләрне,
һәммәбезне тигезли.

Җирдә калган адәм юктыр.
Барыбыз бер үк юлда...
Калса калыр, балам аша,
Тәңремә кылган догам.

*1997, 22 октябрь*
*Казан*

## ГАСАБИЛАНУ — ИҖАДИ ЯНУ

Күрә — күз. Кабына — дәрт.
Күңелдә — утлы сурәт!
Моны, дим, бүтәннәр белән
уртаклашырга кирәк!

Шундый олуг уйлар башта! —
Җиһанны каратырлык!
Алар, бәлки, кем өчендер
бәлзәмгә ярарлыктыр?

Тик ни хикмәт... сүзләр, сүзләр,
сүзләр генә табалмыйм...
Димәк — көч юк... Ник үземне
«Син — фәлән!» дип алдалыйм?

Бәлки мин — кысыр чәчәкле
алмагачтыр ялангач?
Күңелеңдәген кәгазеңә
күчерә дә алмагач!

*1997, 8 ноябрь*
*Балык Бистәсе*

## КУЯН АТУ

I

Атуын аттым...
Әтидән тунаттым.
Җанымны канаттым.
Мылтыгымны саттым.

II

Тиресеннән кан саркыган
ул куяннар мине бик еш эзәрлекли.
(Башта үзем йөрдем эзләреннән, хәзер —
алар.)
Күзләре һич кылый түгел:
зурлар, җанлы һәм тереләр!
Вәхшилектән гаҗиз калган моңсу күзләр.
«Ничек инде? Кеше кадәр кеше булып...
Җан кыя ала?..»

...Әшнәк өстендәге япан кырның
тере бизәкләре кимеде.
Эскертләрнең төсе үзгәргән күк.
Ябалакның карашында — сагаю һәм мыскыл.
Кырпак кардан чыгып торган сап-камыллар —
чын нәфрәт энәләре.
Сагыш баса куе томандай.
Ямансу...

III

Өй, синтемент Кешем!
Ярты гасыр яшәп — күрмәдеңме?
Тарихлардан сабак ала белмәдеңме?
Җинаятьләр хәятенда йөрмәдеңме?

Син түгелме язган:
«Җирдә халыкларны юк итәләр.
Күк катында кемнәр бар анда?
Йә Алла!
Ләйсәннәрең җанны юа алырмы,
күздән канлы яшьләр акканда?»

IV

Бу бит ау, дим,
сунарчылык —
бакый гомер ирләр шөгыле;
табигый бер азарт, мавыгу, дим,
ерткыч асылымны яшереп...

*1997, 9 ноябрь*
*Балык Бистәсе*

* * *

Иртәнге җил, кичке салкын…
Яшьлек —җегәр, картлык — акыл.
Тормыш — сызык, яшәү — өтер…
Үткән гомер, калган хәтер…

Кан туңса да, йөрәк ялкын!
Иртәнге җил, кичке салкын…

*1997, 19 ноябрь*
*Казан*

## ӘЗЕРЛЕК

Бернәрсәгә гаҗәпләнмим:
күргән — күрелгән...
Шатлык-кайгыларны сөздем
йөрәк төбеннән.

Тамчы көнләшү юк — бездән
алдан өлгергәнгә.
Үзенә язган тиешлесен
барыбер ала бәндә.

Бетте ул әчеләнешү
җыен юкка-барга.
Әле бит азмы-күпме тагын
гомер бар күк алда.

Малга, данга да ис китми,
хәтта — яшь тәнгә.
Төп байлыгың — ул ныклыгың —
Рухың икән лә!

Үткәнем гел үк буш түгел.
Җаным әле тәндә.
«Аллаһым, Син бар әле!» дим,
ялгыз көрсенгәндә.

*1997*
*Казан*

* * *

«Син — яшь! Мин — яшь!» дигәннәргә
ышанып йөргәнмен дә...
Сандугач йокысы кадәр
Яшьлекнең гомере дә!

Тай айгырга әйләнгәндәй,
җиткәнмен картлыгыма.
Картлыкка ук булмаса да,
моңсу олпатлыгыма.

Уем белән олы икәнне
яшьтән дә белә идем,
тик аны тышка чыгармый,
сиздерми генә идем.

...Менә хәзер гармония!
Тән дә, җан да — бер чама.
Яшеренмичә яшәреп,
Иҗат итәргә кала!

*1998, 7 февраль*
*Казан*

* * *

*Г-гә*

Урал шаһинәсе булып Син үткәндә,
ярты Казан калды иелеп!..
Син турайткач, «князь-шагыйрь!» булып,
мин дә йөрдем: «Күрегез!» — диеп.

Бар күзәнәк шау иҗатта иде —
көч һәм назның тулышкан чагы!
Һәр тарафтан кемнәр караса да,
күренә иде Сөю учагы!

Төшләремдә итәгеңә тектем
дөньядагы байтак гөлләрне...
Әйттеләр дә бугай: бу егетнең
Күк Капусы ачкан көннәре!

Алтын кылчык булып кадалганмын
бәгыренә, бәлки, кемнәрнең?
...Бер үкенеч: ул чак бу бәхетнең
кабат кайтмаслыгын белмәдем.

Башкорт иле — Баймакларга баргач,
гөл исемең искә төште гел.
Көзге яфрактан Сиңа атлыйм.
Монсы чынлык. Монсы төш түгел...

*1998, 18 февраль*
*Казан*

* * *

Канда — басып алу, талау,
Канда — канга батыру,
Юлбасарлыкта, угрылыкта
басмач «туган» батыр ул!

Читләрдән акча теләнер,
хәрби заводлар корыр.
Башкисәрләр тәрбияләп,
хезмәткә урнаштырыр.

Иген игеп азапланмас,
күп җире кысыр калыр.
Тарих чүплегендә «Империя»
исемен алып калыр.

Һич булмаса, указлатып,
үз халкын ач та тотар.
Галәм нәфесле шаһларның
беркөн үзен Җир йотар.

*1998, 18 июль*
*Комкой (Төркия)*

* * *

Ике дөнья — бер моржа ла!
Калҗа ни дә, марҗа ни!
Дәртле уенда телдән төшми —
«И мани да и җаный!..»

Чир ега... Баскан җир тетри...
Хыянәт-ук кадала.
Күккә багып ялварасың —
«И әни дә и Алла!..»

*1998, 18 июль*
*Комкой (Төркия)*

## ЮАНЫЧ

*Ә-гә*

Таулар күчермәдем арырлык.

Ә шулай да
хезмәтем бар —
соңгы юлда
үз-үземне
күтәреп барырлык.

*1998, 20 июль*
*Комкой (Төркия)*

## МОНДА БИК ТИЗ ШӘФӘКЪ БАТА...

*(Диңгез буенда үз-үзем белән сөйләшү)*

— Монда бик тиз шәфәкъ бата!
— Киләсе үлем тиз килсен!

— Бездә таңнар сызылып озак ата!
— Яшьлек барыбер тиз уза.

— Сездә төнен нинди кош сайрый?
— Җан — күбәләк.
Барсын әйтеп йөрми кычкырып...

*1998, 21 июль*
*Комкой (Төркия)*

## БӘЛКИ...

Берәү вафат.
Дөнья кимедеме?

Туры йөргән, авып төшеп,
туфрагына ятты гына.
Күрер күзгә
кабер — таучык артты гына!

Яңа дустың — ярың артты.
(Кем белә?)
Бәлки, Дөньяң кимегәндер әле!..

*1998, 23 июль*
*Комкой (Төркия)*

* * *

Ара сакла! Бар бит әнә
бармакларның аралары.
Якынаймагач тиелми,
һәм... ачылмый яраларың.

Табигый ерак якынлык!
«Дистанция!» дияр кемдер.

Туу-үлем рәттән булмас,
арада — нәни гомердер.

*1998, 25 июль*
*Комкой (Төркия)*

* * *

Халыклар берләшеп беркөнне
(БМОлар һәм аңа кермәгән
милләтләр, кавемнәр, ырулар...)
бер бөек фикергә килгәннәр:
«Әйдәгез, корыйк уртак бер
гөл-бакча — пантеон, дигәннәр.
Капкада — исеме дә аты —
«Беренче Мәхәббәт зираты!»

Җәннәте торсын ди бер якта
мондагы илаһи балкыштан.
Монда бит хыялда булса да,
гашыйклар яңадан кавышкан!

Шәфәкъләр юк икән бу җирдә!
Гел яшьлек, гел гөлләр, гел ал таң!
Мең төрле телләрдә, рәшәдәй
тибрәнеп тора ди, изге сүз:
Яратам! Яратам! Яратам!..

... Мин дә еш ашкынам бу җиргә.
Табынам абына-абына...
Һәммәбез беренче ярларны,
Беренче Сөюне сагына.

*1998, 25 июль*
*Комкой (Төркия)*

## СӘХРӘЛӘРГӘ ЧЫККАН ИДЕК БЕР...

*(Хәтер)*

*Г. А-ка*

Бу җирләрне яд итәргә
төркем булып килдек каладан.

...Авыл беткән күптән.
Тау битендә
зират та чишмә калган...

Яктык учак. Кыздырдык шашлык.
Тостлар яңгырады телдән телгә күчеп.
Янда бөтереләә иясез бер көчек.
Фанилыкны искәртә талгын җил исеп
зират ягыннан...

...Бу адәмнәрнең дә күбесен юк дип була,
йөрсәләр дә монда ашап-эчеп.

*1998, 27 июль*
*Комкой (Төркия)*

## ИДЕЯ

Кош булып очты биектә!
Һәммәбезнең күңеле хуш!

Сабантуйның рухи сөлгесе!

Аннан Ат булды.
Чаптырдылар, тарттырдылар...
Төрле-төрле ипподромнарда.
(Ә кемнәрдер,
кемнәрнеңдер
эйфория-ыргымнарда исергәндә,
Аннан симез Дуңгыз ясады.
Рәхәтләнде бер кавем халык —
кикереп-биеп хәрәм мал җыйды,
вәхи иңгән Күккә төкереп...)

Соңрак әйләнде Ул — машинага.

«Тәлинкәләр төшкән, диләр,
Биек тауның ташына.
Хәлем җитсә, басар идем
Баш машина башына!»

... Иң соңыннан кәлтә елан булып калды.
Итек баскач, өзелде Бахыр!

Хыял-Кош күләгәсендә
сирпелеп калды —
кеп-кечкенә
нәни койрык —
Мөстәкыйльлек...

*1998, 27 июль*
*Комкой (Төркия)*

* * *

Читән кору түгел,
иман беркетү!
Ышанам дисәң дә,
шикләр бер көтү.

Ышану, шиксез, бар
Илаһ бер Көчкә.
Гөнаһыңа җәза
булу тиеш тә!

Килми калмый бер көн
көтмәгән Сынау.
Чыныга кеше йә
бөтенләй сына...

Качсаң да, Адәм зат,
хакыйкать — табар.
Онытма, Яшәүдә
ахирәт тә бар!

Гомердә бер гамәл:
табу-югалту.
Ярга кайту түгел,
Иманга кайту.

*1998, 26 июль*
*Комкой (Төркия)*

## ЯНА ВАКЫТ, БЕЗНЕ ЯНДЫРЫП...

Адымнарны сагайта.
Хатирәләр яңарта.
Әйтер сүзне сайлата.

... Йокысызлык офыгында
Шәфкать аша таң ата.

*1998, 28 июль*
*Комкой (Төркия)*

## ТӨРЕК МУНЧАСЫНДА УЙЛАНУ

Ятам төрек мунчасында.
Сөякләр эри...
Госманлы империянең
табасымыни!

Алтын Урда, ханлы чаклар
һаман истәме?
Әллә җитмиме төрекнең
эссе өстәве?

Әвәли массаж остасы!
Син — ит камыры!
Бу «җәллад»тан сау чыгармы
татар тамырым?

Мунчада без генә түгел,
Ята бүтән дә,
Яшәү ләззәтен һәркем
Сеңдермәкче тәнгә.

Ләүкәндә әнә кяфер
килмешәк ята.
Гүя бот күтәреп ята
тарихи хата!

Төреккә дә хаклы үпкә:
кирәк чакларда,
ирендеңме Казан җирен
килеп якларга?

Фиргавен илен туздыру
ник кирәк иде?
... Ярый диңгезләрең бар —
хәзер терәк әле!

Рәхәт, әлбәттә! Әмма
уй качамы соң?
«Тәрҗеман бабай» хыялы
чынга ашамы соң?

... Кайда монда Ата төрек?
кайда Али-Баба?
Тирлә дә кайт үз җиреңә,
чум үз дөньяңа!

*1998, 29 июль*
*Комкой (Төркия)*

* * *

«Теге бөекнең тамыры
татар каныннан икән!
Төгән шәхеснең әбисе
Казан ягыннан икән!
Тәхет күргән, ди, фәләннең
бабасының бабасы —
чукынганчы ул бабаның
әтисенең бабасы...
Елъязмалар тузаныннан
их, исемен табасы!..

Наполеон да әйткән, имеш:
«Урысны игәүләп кара —
асылына төшкән саен,
татары торып кала».

Менә шундый безнең халык!
Бөекләрне мул биргән!
Дөньясында андый юктыр, —
безнең татар «Во!» дигән.

... И кардәшем, сабыйланма,
горурлыгың — кабердә.
Ул бөекләр синекен дә
ашап киткән кавемнәр!
Бүген сине кол иткәннең
фәлән кемдер бабасы...

Әнә кырда чөгендерең,
эшлә, татар баласы!

*1998, июль*
*Комкой (Төркия)*

* * *

Һәм, ниһаять, бусы да булды!
Яптык бер сәхифә!
«Ах, ялгыштым!..» була алмый
кичә үткән кичә!

... Көткән сарык көтүендә
байтак бәрән булган...
Без Шигырьдә җайдак чакта
кемдер әрәм булган,
кемдер вәйран булган,
кемдер «бәйрәм» булган...

*1998, 15 август*
*Казан*

* * *

Ян, газаплан —
каңгырма гына!

Кыялар елый
яңгырда гына!

...Төшемә керде:
кабере югалган
Чыңгыз хан тора
яп-япан кырда!..

*1998, август*
*Казан*

## БАЛА ТЕЛӘҮ

Көлеп килә Төн!
Карынындагы
Таң белән килә!

Гаҗәп төш күрдем:
Диңгез-дулкында
тирбәлә силә!

*1998, 17 октябрь*
*Казан*

* * *

Яшәлгән... Күрелгән...
Тоелган... Татылган...
Бөтигә язылган
догалар онтылган...
Иш көннәр агыла
бер-берсе артыннан...

«Яндырам!» дисең дә...
Шәп инде яна алу!
Мәхәббәттә яну —
яңадан яралу!

... Миңа тик Шигырьдә
килә ала яңару.

*1998*
*Казан*

## ШИГЪРИ ПОПУРРИ ЯКИ ГОМЕР ФАСЫЛЫ

Һәр ярыктан — кызлар күзли!
Учта елан мөгезе!
Баскан төшем — Җир уртасы,
тәхетендә — мин үзем!

Без төкергән җирдә гөл үсә!

Тимәгән, тик тимәгән...
Әле яшьлек көймәгән!
Хәрабәләр торгызырга
безгә генә димәгән!

Их, метрополитен! Яраткач...

Яшьлектән китмим! Анда хет
швейцар булып калам!
Җиңгәң әйтә: мин, ди, сиңа
алтмышта угълан табам!

Шундый эшләр, бохар шәкерте!

Җыерчыклар арасыннан
кырмыскадай уй йөри.
Дөньяда озак яшәгәч,
картаюлар мәҗбүри.

Кырыгымда кырда кар явар...

*1998*
*Казан*

## ОЯЛМА!

Яшеңнән дә,
яшәвеңнең
рәвешеннән дә...

Таңда торгач,
чыкка төшкән
яшеңнән дә!

Эшең өскә чыккан!
Бу дөньяда
ни чинамас
сөткә төшкән тычкан!

Сират-кичүгә
кем нәрсә илтә!

Тыныч булсын төнең,
тыныч булсын иртәң!

*1999, 31 гыйнвар*
*Казан*

* * *

Картлык — йогышлы чир.
Йога — Вакыттан.
Булмый аны туктатып
атып та туптан!

Картлыкны тоймассың —
булмасаң гына.
Вакытта «куырылмассың» —
тумасаң гына.

*1999, 2 март*
*Казан*

## КИЧЕП ЧЫКМАДЫ...

Төнге бураннарда, чаңгы тагып,
бозлар аша тартып карадым.
Урау юллар аша,
төрле-төрле машиналарда
кичтермәкче булдым.
Сөйрәдем буксирдай,
йөзә-йөзә колач салып...

Һич булмагач,
турылатып күпер салдырдым.
Кызыктырмак булып,
каршы якта сарайлар кордым...

Иске нигезеннән яңа йортка
күченмәгән Ия шикелле,
калды Сөю Иске Шәһәрдә —
Казансуны кичеп чыкмады!..

...Әллә Үзе көчсез булды?
Әллә без юньсез булдык...

*1999, 25 апрель*
*Казан*

* * *

Җир сөрмәде.
Нигъмәт күрде...
Илдән бизде.
Дөнья гизде...
Этлек итте.
Рәхәт чикте...

Кадер белән гүргә керде.
Имди...

*1999, 29 июнь*
*Бәкер*

* * *

Бүләкләрме?

Алгаладык.
Һәрбер бүләк —
алды саулык.
Булса да ул
бер кулъяулык...

...Арттан килгән
ат булмадык!

*1999, 3 июль*
*Бәкер*

* * *

Уч тулы үч.

Нишләтергә моны?

Чәйгә салып болгатыргамы?
Сибәргәме Тегенең артына?
Пистолетның газы урынына
тутырыргамы шушы әчене?
Йотаргамы буар елан күк?

... Түктем ялантәпиләремә.
Гөнаһлы аяк кичерер.

... Кулны юып,
Әнием рухына
дога кылдым
белер-белмәс
дога белән.

*1999, 5 июль*
*Иске Иштирәк*

## АЧЫЛМАГАН ХАТЛАР ЯТА...

Яталар өстәл читендә,
яталар көннәр, айлар.
... Вакыт эченнән Вакытны
эзләгәннәр аңларлар...

Хикмәт цейтнотлыкта, —
тәкәбберлектә түгел!
Күнегелгән баналь хатка
битарафрак күңел.

Хат иясе кайчак шизик
«даһи» бер тинтәк була.
Йә утлы тигәнәк капкан
җилбәзәк итәк була...

Гаделдер син дә бик, бәлки,
бүгенгеңнең фонында.
Тик онытма, көне килгәч,
чыгар алар угы да!

Араларында юктырмы
бер җылы сүз көткәне?
Ышаныч ук булмаса да,
нидер өмет иткәне?

Дөнья бу! Көткәннәрнең
«җавабы» төшәр беркөн.
...Хат-сүзләр көтәрсең... Килмәс...
Сәлам дә бирмәс беркем.

*1999, 12 июль*
*Казан*

* * *

Шундый чак килә:
Җанга вәхи-хат иңә —
теләмим теләүләрен дә,
телефон челтерәвен дә,
ишек шакуларын да,
тәрәзәгә кар атуларын да,
почта әрҗәсендәге
чакыруларны да...

Һәй, Дөнья! Яшисе килә!
Солы урынына борчак килә!

... Таң алдыннан,
күз алдыма,
гөнаһларны яндырып,
киләчәктә балкыр
Учак килә!

Чын Хак килә.

*1999, 6 август*
*Казан*

## БЫЕЛ ҖӘЙ... ЯКИ МОҢСУ КАБАТЛАНУ

Быел җәй, быел җәй —
 эссе җәй,
  хәлсез җәй,
   мәнсез җәй...

Бәгырьләр көйгән җәй.
Тәкъдирем хәсрәтне
эскертләп өйгән җәй.

Бакчамда әрнешеп,
җиләкләр көйгән җәй.

Кочагым түреннән
Бәхетем киткән җәй.
Күңелең бозына
иреннәр тигән җәй.

Текә тау маңгаем
идәнгә тигән җәй.

Сау-имин картлыкка
Өметләр иткән җәй.

Үзем дә белмичә,
үземчә
 көткән җәй,
  көткән җәй...

*1999, 7 август*
*Казан*

* * *

Авырыйсыңмы — димәк, гөнаһың бар.
Җәза итеп Тәңре җибәргән.
«Череп кат!» диюче үзе корыша,
үз каргышын алыр бер бәндә.

Өч чукынып, бер бисмилла әйтеп,
ике зина кылып, бер намаз,
ике Дөньялыкның бер чите дә
андый җанга җәннәт булалмас.

*1999, 18 август*
*Казан*

* * *

Әче хәсрәт... Төче хәсрәт...
Татлы хәсрәт — синдер ул!
Гомерлек җандашка сусау —
Ялгызлыкка — синдром.

Тәүбәгә килгәнсең, имеш...
Тәүбә эчендә ни ята?
Түрдә янә таныш хата
ыржаеп көлеп ята.

*1999, 26 август*
*Аккош күле*

* * *

Кафтау. Сугыш. Ташлар егълый...
Бомба ява халыкка.
Таулардан да биек булып,
үлмәс нәфрәт калка.

Яна илләр. Вәйран булды
Әфган, Ичкер, Таустан...
Кылыч һәм Гөл булып шытар
сабыйлардан аккан кан.

*1999, 5 сентябрь*
*Аккош күле*

* * *

Үткәнне сорама.
Сиңа да — киләчәк...
Җавап урынына
бирием бер чәчәк.

Күпме су сипсәң дә,
ул да бер корыр.
... Кемнеңдер бер җыры
гомерләргә тора!

*1999, 12 сентябрь*
*Казан*

* * *

Козгын кунган киртәгә!..
Бүген — чебеш... Иртәгә?

Баскын тубы киртәдә!
Бүген — чечен... Иртәгә?

...Атмас диеп кем әйтә ала
канлы таңнар иртәңә?

*1999, 4 ноябрь*
*Казан*

## 99 ЯШЬЛЕК КАРТ

Ни әйтсәм дә хәзер, барысы дөрес...

Бар яшьтәшләр, замандашлар барсы гүрдә...
Гөнаһларыма шаһит бер адәм юк.

... Янган морҗа булып, Дөньялыкта
ялгыз мин калдым.

*1999*
*Казан*

* * *

Стресслар кирәк.
Чәйгә салган җимеш кебек.

Сынауларда сынып олыгайгач
Идел кадәр хәсрәт тә
инеш кебек.

*2000, 2 февраль*
*Аккош күле*

* * *

*Н-гә*

Затлы.
Татлы.
Атлы.
Хаклы.

Усаллыгы?
Минеке чаклы.
Тырышлыгы-үҗәтлеге
кырык сигез катлы!

...Өреп терелтә ала
арыган учакны.

Эңгер-меңгер язмышыма
Ходай биргән Якты!
Югалтсаң, тагын йөрерсең —
«улмы, минме хаклы?»

Орлыктан кибәкне аермый
күпме гомер акты...

*2000, 30 апрель*
*Аккош күле*

## АВЫРГАНДА

Моң-гамь белән мөлдерәмә
Гомеремнең савыты.
Йоклый алмый саташыпмы,
тартышыпмы, алмашыпмы...
бәргәләнә җан уты.

Гөнаһлыга да, савап өчен,
бәлзәм бирер вакыттыр.
Бурычым күп, үтәп китим,
И Ходаем, савыктыр!

*2000, 13 май*
*Аккош күле*

* * *

Урман авызындагы хәйран киң юл,
эчкә кергән саен,
гел тарая барып югалды...
Төртенсәң дә — дүрт як кыйбла!

Җыр яздырткан Олы Мәхәббәт,
ваклык-сатлыкларга түзә алмый,
еллар рәшәсендә эреде.
Калды — Нәфрәт
кара морҗа кебек.

Яшәүгә дәрт, хыял-өмет арта һәр ел саен.
Беркөн баксам — гомер шәмем
ике яктан янып килә!..

Алда маяк дигәннәре —
Билгесезлек —
пәри туе дигән өермә...

*2000, 28 май*
*Аккош күле*

## ИРТӘНГЕ МАХМЫР

Шешә төбендә
«ак» калган.
Идәндә гөлләр
тапталган...

Кичә кем кемгә
ят калган.
Җанда ниндидер
тап калган...

Димәк, әле бераз
оят калган.

*2000, 17 июнь*
*Аккош күле*

## БАР ДА ҮТӘ...

«Кызыл ыштан»* кигән
чаклар онытылган.
Беренче кырынган
көзгеләр ватылган.

Беренче сөйгән яр
бүтәндә капланган.
«Зөфаф»ның кан-тапсыз
җәймәсе акланган.

Туган йорт нигезен
әремнәр каплаган.

Хәтердә — яшьлектән
бер дога сакланган...

*2000, 29 июль*
*Аккош күле*

* Сөннәткә утырту.

## БАР УЛ...

Тотар өчен
килгәннәр бар.
Йотар өчен
килгәннәр бар.
Тотып, йотып
һәм куркытып,
отар өчен
килгәннәр бар

...Тагын кемең бар?

Кешеләр
    ятлап
        кабатлар
            үткәнең бар!

*2000, 5 август*
*Аккош күле*

## ЗИРАТТА

Озак күмәләр кешене!..
Зират туйдыра,
Тизрәк чумасы килә
Яшәү куенына!

Монда бергә яшәлгән
күпме җаннар иңгән!..
Бәлки, өмет итәләрдер
берәр дога синнән?

Синдә тизрәк чыгу уе
Мәңгелек Йорттан.
Үзеңне дә җибәрмәскә
Еллар буып тоткан.

Синдә әле, ләззәт тоеп,
бала теләү уе.
Туу-үлемнәрдән тора
Кешелекнең туе.

...Озак күмәләр кешене.
Тиз оныталар.
Уйласаң, алар — без бит,
ә без тиздән — алар...

*2000, 16 август*
*Аккош күле*

* * *

Дөньясы кагып-сугып,
бәгырен көйдергән җан —
чишмә суын өреп каба!

Асылың саклап,
сатмыйча-сатылмыйча,
шәмдәй туры басып калып,
халкыңда эреп кара!

*2000, 19 август*
*Аккош күле*

* * *

Тәхет — биек!
Түре — «бөек»!
Дөнья — аныкы!..

... Көне килгәч,
финал —
Калигула*ныкы.

*2000, 19 август*
*Аккош күле*

---

* Калигула — үзен Алладай санап, гамәле һәм холкы белән җәмгыятьтә нәфрәт уяткан борынгы Рим императоры. Соңыннан үз сенаторлары тарафыннан үтерелә.

## БАСЫП ТОРУ

*Тәртип бозган өчен Әни мәрхүмәнең үз тәрбия ысуллары бар иде: без — малайларны ярты яки бер сәгатькә урындыкта бастырып тота иде.*

Ичмасам, бәргәләп
алса гына икән!
Басып торам шәмдәй,
тере малай-һәйкәл...

Шундый гаделсезлек! —
риза түгел күңел.
Бәбкә югалганга
мин гаепле түгел.
Җәймәгә караны
ялгыш кына түктем,
беленмәсен диеп,
ерттым әле читен...
Күрше бакчасына
өч көн кергән юкка!
Әни биргән җәза
булды бер дә юкка...

Сәгать йөрми кебек.
Минутлар озак үтә!
Уйнарга урамда
дус малайлар көтә!
Әни күрмәгәндә
чүгәләп тә алам.
Бу вакытны тизрәк
үткәрсана, Аллам!
Эх, беразга гына
мәрткә китсәң иде!
Әни үрсәләнеп
янда йөрсә иде!
Әй, үкенсә иде!
Уйнар чак җиткәндә
янә терелсәң иде!..

Әй, газиз сабый чак!
Әй, үткән гомерләр!
Ул чакларны сирәк
төшләрдә күрү дә!
Үтте күпме көннәр!
Үтте күпме еллар!
Яшәлә-яшәлә
төз басып торулар
күп булды. Булган күк
үзгәртеп корулар.
Тордык төрле чатта
үсмер егет чакта,
тордык төрле постта
гади солдат чакта.
Кешеләр күмгәндә
церемонлы сакта...

... Басасы иде хәзер
урындыкка менеп!
Бөтен җаным белән
торыр идем көлеп!
Торыр идем сәгать,
торыр идем тәүлек...
Язмыш тарафыннан
бәхетле үртәлеп!

Әлегә әнием
кабере янында
тып-тын басып торам...

*2000, 20 август*
*Аккош күле*

## УЙЛАНДЫ ИР ИРТӘН УЯНГАЧ...

*Чыны ир-атның —*
*көн дә кичә сиратны.*

«Ир егетнең йөрәгендә
иярләнгән ат ятыр!»

Төшендә чапты-чапты да шул атта,
уянгач иртән уйланды шул хакта:
Су, батырып, кочмакчы булды;
Ут, көйдереп, куырмак булды;
Җир, «әйләнеп», башыннан төйде;
Хатын-кыз — кадады аркага...

Ә Күк менә нишләр?
Фәрештәләр канатында күтәрерме?
Җәһәннәмгә себерерме җилләре?..

*2000, 9 сентябрь*
*Аккош күле*

* * *

Үз вакыты җиткәч — имән ава,
йолдыз арып сүнә, рух какшый...

Нихәл итмәк кирәк: кемдер чынлап
Яшәештә мәңге калмакчы!

... Була кайчак, Дөньяны баскан
Явызлыкны җиңә бер Яхшы.

*2000, 4 ноябрь*
*Казан*

## КҮЛӘГӘЛӘР

*Күләгәсе дә юк бит аның!..*

I

Очкан җанның күләгәсе җирдән шуа
(шәүләсеннән шәйләп була — чыпчыклыгын,
бөркетлеген).

Атлаганның — кешеме, атмы — ияреп бара
янда
тай кебек.

Еланның да күләгәсе боргаланып, сузылып
«ага»
нечкә баудай.

Тигезлектә тигезлекне «боза» алган һәрнәрсәнең — баганамы,
борчакмы ул,
кабер ташмы —
күләгәсе...
Кояш булса!

II

Ә Кояшның күләгәсе?

Хәтта аны
күләгәләп була икән —
«тотылганда» —
Ай капласа.

Тымызык күлнең,
дәрьяның, диңгез-суның?
Алар — көзге. Күләгәсез.
Су-көзгедә бизәнүче
тал-тирәкләр, кыя-ташлар
беркөн корый, җимерелә, авып төшә...

Су йөзләре —
Ай-Кояшка гына мәңгелек.

III

Күләгәләр...

Кайсы — тере, кайсы — җансыздыр.

Ялкын кебек
хәрәкәттә генә тереклек!

...Күңелемә сеңгән бер сурәт:
чегән кызы биегәндә
үрсәләнеп шашкан күләгә.

*2000, 21 ноябрь*
*Казан*

* * *

Әрәм үткән кичләр,
мыскылланган таңнар...
Очлы субай какты̧ң
җәрәхәтле җанга!
Көйгән мәхәббәтнең
нәфрәте яман!

Тиледән алданган
ир-ат үзе юләр.
Бер Ходайга мәгълүм:
кем әле алдан үләр?
Кемне гөлләр күмәр,
кемне көлләр күмәр...

*2000, 10 декабрь*
*Аккош күле*

## БИЗҮ

Бизелсә бизелә икән
бөтен бизләр белән!
Үткән — микъдарлап үлчәнә,
акыл-бизмән белән.

Вертолетлар әверелгән
энә карагына!
Салават күпердән калган
ак та кара гына.

*2000, 21 декабрь*
*Аккош күле*

* * *

Талантын да, буй-сынын да
җәлләмичә ишеп биргән.
Ефәктән түгел, каештан
Язмышын да чигеп биргән.
...Бәхет дигән кулъяулыктан
бер чеметем кисеп биргән.

*2001, 2 гыйнвар*
*Аккош күле*

## АК ТӨШ

Күктә — акчарлак.
Суда — ак чабак.
Дулкын өстендә —
күбектә Ак Ат!

Каршыма минем
томырылып килә!
Җайдак соң үзе
күренми нигә?

Җилфер елларда
әллә ак хәбәр?
Ут-тоякларда
әллә ят хәбәр?

Җаным, тынычлан,
янма ул кадәр!

...Сүзем хак булды,
төшем ак булды!
Каршыма килгән —
хыялымдагы
Акбүз Ат булды!

Күктә — ак болыт.
Җирдә — ак канат.
Сабый чагыма
кайтылды кабат.

*2001, 2 гыйнвар*
*Аккош күле*

* * *

Беренче саф хисне
булмас та яңартып,
шулай да мендәрне
иплә әле кабартып!

Әйдә, кемдер йөрсен
гайбәтләр таратып...
Саулыкта сөелү —
байлыктан мең артык!

Тырышсаң буладыр
караны агартып.
Кояшны, Сөюне
булмый ул каралтып!

*2001, 20 февраль*
*Казан*

* * *

*Урыс белән дус бул,*
*Билеңдә балтаң булсын!*

«Дус»лыгы аның чиксез...

Ил булмагач,
бил сыек...

Өстәвенә
балтасының
сабы сынык.

*2001, 3 март*
*Аккош куле*

* * *

Өем — төзек. Тәнем — чиста. Уйларым — пакь.
Әчәкләрне генә юдырасы...
Ә шулай да, кайчагында килә
маңгаема берне тондырасы!

Дөрес яшисең бит Шагыйрулла! —
җыен кабих араларында...

Кем белә әле: гөлме, хәнҗәрме
шытар җаным яраларыннан!

*2001, 14 июль*
*Аккош куле*

* * *

*Ай Заман! Вай заман!..*

Күл өстендә черки аулый
энә карагы.
Шәхси боргалакта оча
казна карагы.

Энә бурын улым япкан
капка «шәп!» итеп.
Казна бурын сайлаганнар
депутат итеп.

*2001, 20 август*
*Аккош күле*

## КИЛДЕ БУ КӨН...

*Килер бер көн —*
*хәерчеләр йөрер төркем-төркем.*

Килер бер көн
мөтәгалим-«академиклар» йөрер төркем-төркем.
Гамәлләрен аңламас беркем.

Милләтнең күбәер «ата-аналар»ы.
Туган телдә сөйләшмәс балалары.

Идарәгә менәр угрылар —
Алдап җыйган малга тугрылар.

Закон өстендә закон булыр,
Указ өстендә Указлар,
берсен берсе бетерешеп бугазларлар.

Зур галимнәр акчага ялланырлар.
Клонлаштырмакчылар Алланы да.

Җиһандагы вакханалия-хаоска
шаклар катар Нострадамус* та!

... Ахырзаман килеп барсы килер вәйран.
Кояш кадәр кояш калыр хәйран.

*2001, 21 август*
*Аккош күле*

---

* Мишель Нострадамус — француз астрологы (1503 — 1566). Медицинаны да өйрәнгән, соңрак бик буталчык күрәзәчелек белән шөгыльләнгән һәм үзенең фараз кылуларын шигъри дүртьюллыкларда теркәп калдырган.

## ТАТАРНИК

*«Хажиморат» кыйссасында*
*Толстой герое ул!*

«Шайтан таягы» яки
«Татарник» диләр,
Идерә алмый аны
давыллы җилләр!

Татар үзе шыңшый:
Шул ук «Зиләйлүк»...
Сөялгәнсең чатта...
Әллә илең юк?..

*2001, 3 сентябрь*
*Аккош күле*

## ИДИЛЛИЯ

Куй өстендә тургай күкәй сала.

Дөньяның бар солдаты
җыйнаулашып корал сүтә.

Бодай көшелләре өстендә
мәтәлчекләр ата сабыйлар.

*2001, 5 сентябрь*
*Аккош күле*

## БЕРӘҮГӘ

Тузган кош оясын җәлләп
язган ул инша.
Күздән яшьләр китерерлек,
әгәр укысаң.

Үз гаиләсен ташлап качкан.
Сабыйлары — юксыл...
Гаҗәпсенмәм, бисмилла әйтеп,
әгәр чукынса.

*2001, 19 сентябрь*
*Аккош күле*

## БЕРНӘРСӘ ЮК...

«Җир йөзендә бернәрсә юк
Яшьлектән кадерлерәк!»

Гомерлеккә сөйгәнеңнең
тәненнән дә тәмлерәк!

Сабыеңның күзеңә карап
көлүеннән ямьлерәк!

*2001, 19 сентябрь*
*Аккош күле*

* * *

*Р. истәлегенә*

*Әллә ничек сәер генә*
*үтте китте бу гомер!..*

Бу юл(ы) юньләп яшәлмәде...
Яшәрбез киләсендә!
Беләм, минем бу сүзләрдән
кемнеңдер көләсен дә.

Кем-нәрсә булырмын икән
киләсе яшәүләрдә?
Бәлки әйләнермен чыкка,
ә бәлки рәшәләргә...

Бәлки, миллион еллар үткәч
әйләнермен металлга?
Йә бер кош булып сайрармын
канат кагып бер талда?..

...Ходай язмасын йөрергә
бер имгәктә сыр булып,
яки бабасыр булып...

Ә хәзергә яшик әле
берәр йөз ел җыр булып!

*2001, 27 – 28 ноябрь*
*Аккош күле*

## КҮПСЕНМӘ, ХОДАЕМ!..

*Иҗатым бар, балаларым үсә!..*
*Бәйрәм түгелмени бу тормыш!*
*Бәхет түгелмени бу яшәү!*

Җуймадым әле —
Аш тәмен,
    Эш тәмен
        Тән тәмен!

Яшим тоеп
Дөньяның
    күп гамен,
        күп ямен.

Өстәвенә яна
Каләмем!

Кирәкми
Язмышның
бүтәне!

*2002, 8 февраль*
*Казан*

## ФАРАЗ ҺӘМ ЧЫНЛЫК

I

*«Егерме елдан коммунизм була!»*
Н. Хрущев

*«Егерме елдан телегез бетә...»*
Ф. Табеев

Егерме ел үтте. Күбрәк тә үтте...
Коммунизм килмәде... Килде — СПИД.
Әфиүенчелек атты чәчәк...

Шулай да
шагыйрьләребез туган телдә шигырьләр яза.
Эшләп килә татарча гимназияләр.
Чын тарих ачылып килә чәк-чәк...
Ни әйтер киләчәк?..

II

*«Бердәм совет халкы булачак».*
КПСС программасыннан

Кырык еллап үтте. Хәтта күбрәк...
СССР таркалды. Аерылып ишәйде дәүләтләр.
Көчәйде җинаять.
Җәмгыять бүленде: байга — ярлыга.

Шулай да
азанлы манаралар күккә ашты.
Намазга баскан сабыйлар ничаклы.
Йә Хода,
без гөнаһлыларны ярлыка!

*2002, февраль*
*Казан*

## АБСУРДИЗМ

*(Халык санын алу)*

Атаңны син җизни димә! —
атаңны атам диген!
Татарны тат йә ар димә! —
татарны татар диген!

...Болыттан күләгә төшкән —
шул минем Ватан диген!

*2002, 10 август*
*Аккош күле*

## ЮК БЕЛӘН БАР

*Юк — бар түгел!*
*Яңа мәсәл!*

Барны
барлап
барганда
очрады Юк.

Әйтерләр:
ничек очрасын Юк? —
Юк бит ул юк!

(Пародокс! — Ә факт!
Була кайвакыт:
күңелсез — күңелле,
патшалар — шыр тиле...)

Бар булмакчы икән Юк!
    Кайчак кар булмакчы,
    кайчак шар булмакчы,
    кайчак яр булмакчы,
Барга пар булмакчы!..

...Ә соң Бар бармы?
Әлбәттә, бар!
Әмма Барны юкка чыгарырлык
бик күп җыен юк-бар.
Шулай да
уйланырлык бит:
әгәр Җиһанда
Юк —
Бар булмакчы икән,
димәк, юк дигәндә дә
нидер бар!

Бу юллардан азык табып,
сөенсеннәр пародистлар!
Ә моралистлар?

Дөньяга кикрик булмасын
юк кешеләр —
чүп ишеләр!

Барлар бар булсын!
Данга пар булсын!

*2002*

## АСКЕТ

*(Студент шагыйрь)*

Кап-кара төн килә!
Ул — ак күлмәктән...

Шома, тыгыз мускуллардан
дәрт ташый күкрәктә!

Бер көтү хур кызлары
килә җәннәттән!

Ишектә кыңгырау!
Ишетми...

...Тынлыкка инәлеп
көтә ул Берәүне —
Күктән иңәчәк
Шигъри Мәлне!

*2002, 9 ноябрь*
*Казан*

* * *

*Мич башында ятса ятыр,*
*мылтыгы янда булыр.*

Ары лап-лап, бире лап-лап,
чит кавемнәр җирен таптап,
халыклар бәхетен «яклап»,
вәхши гамәлләрен аклап,
энәгә салам саплап...

Глобаль затсызлык белән
тора таңымны каплап.

*2002*
*Казан*

## ИШЕК

*(Операция)*

Хирургның маңгаенда бөртек тирләр...

Күкрәген ярдылар хастаның.

Җан чыгарлык ишек ачылды.
(Куллар уйный, скальпельләр бии,
канлы мамыклар оча, салават күпере ясап...)

Финал кайда?
Катафалк сыртындамы?
Савыгуны көткәннәрнең
өмет-шатлык яшендәме?

...Янә булдым җеназада.
(Хәзер ешайды...)
Таза бәдәнле яшь ирләр —
куллары да көрәк кадәр! —
актарганнар җир куенын.

Кабер әзер. Мәңгелеккә ишек ачык.
Җәннәткәме?
Җәһәннәмгәме?

*1995 – 2002*
*Казан*

* * *

Ирлек чыкты бәреп тирләрдә!
Гөлләр шытты баскан җирләрдә!
Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?

Җиһан кичкән сабыр Ирне дә
Тал чыбыгы кебек идердең...
Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?

Хатирәләр — ялкын, без – күмер...
Яшәр өчен аз шул бер гомер!..
Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?

*1999 – 2002*
*Казан*

## ЧИБӘРЛӘР ЯРЫШЫНДА

Мисс!
        Алиһә!
                Браво!
                        Афәрин!..

Яралганнармыни чәчәктән!
Нинди грация! Нинди тән!
Оешып беткәннәр бит ундүрттә!
Пешеп җиткәннәр бит унбиштә!..

(Селәгәйләреңне эчкә йот!
Бөкрелегеңне туры тот!..
Алтын кашыгың юк йотарлык!
Дәрманың юк дәртең тотарлык...)

Яшьлек! Яшьлек!
Гомер язы — бәрхет яшеллек!

Шоуга гына түгел, сугышка да
бик тә хаҗәт икән яшь җаннар
(Ядрә бигрәк сизгер яшь канга!)...
Табутларга тамган яшь кайнар...

...Кем сискәнеп тора «Подъем!»га.
Кем таҗ кия Тәхет-подиумда.

*2000 – 2002*
*Казан*

# ХӘЛЕҢ НИЧЕК, АВЫЛ?

*Әй, авыл, син мең шәһәрдән*
*мең кабат ямьле вә хуш.*

С. Рәмиев

Хәлең ничек, авыл?

Хәлне әйтә табын!
Савым,
артым,
җыем...
Җыем, артым, савым...
Мал-каралтың-илең,
тирес түгәр җирең,
маңгаенда-тирең...

Төшкән тешләр кебек,
йортлар кимеп бара.
Беренче сыйныфта
быел ике бала...

Хәлең ничек, авыл?

Ару гына болай...
Өйләрдә газ яна.
Абзар тулы маллар.
Телевизор ачсаң —
яңа сериаллар.
Онытылды күптән
китап укыганнар...

Өйләнмәгән буйдак
ир-ат урам тулы.
Кызларның уенда
шәһәр-кала юлы.

Хәлең ничек, авыл?

Түгел зарланырлык,
өс бөтен, тамак тук.
Дөрес, акча бик юк...
Бетмәс, ахры, бездә
крепостнойлык...

Түләү — натурлата.
Ярый, кыр-басудан
иген, печән кайта.
Кем ничек булдыра —
шулай алып кайта...

...Тыкрык чатында
әйтте сәрхүш түтәй:
«Авыл — кабыгы сау,
эче аккан күкәй...»

Хәлең ничек, авыл?

Әлхәмдүлиллаһ, шөкер.
Аулак өйләр җыры,
тальяннар моңы
онытылды дисәм,
бәгыреңә тисәм —
кичер мине, дустым! —
авыл болай исән!
Сулар һава һәйбәт,
Сабантуйлар исән.

Буласылар булган,
кибәселәр кипкән...
Туган нигезләрдә
көлләр эреп беткән...
Безнең күбебезне
авыл кеше иткән!

...Буш мәчетләр өсләп
азан ишетелә.

*2002*
*Казан*

* * *

*Акча кирәк! Акча кирәк!*
*Казинога! Зинага!*

Бу бит хикмәт бай эшмәкәр!
Фамилиясе татар!
Ата-бабасы татар!
Бәлки, милли мәнфәгатькә
бераз тәңкәләр атар?

Әй, Наивҗан, Наивҗан!
Башың бар, дәүләтең юк.
...Акча уйнашчы хатын күк,
акчаның милләте юк.

*2003, 1 гыйнвар*
*Аккош күле*

## ЧЫНЛЫК

Күперләр яндырылган.

Ориентир-юнәлеш томанда эрегән.
Аяклар — арганнар.
Куллар — кыска...
(Якында булсаң да,
тәнеңнән
аерып тора галактик ераклык!)
Хәтер тирәген
черек гөмбәләр баскан...

Кавышу юк.
Бәлки, ахирәттә?
Мәхшәр көндә очрашулар ай-һай!..
Сиратлар кичелсә дә хәтта,
гөнаһлар нисбәтеңчә,
төрле якка булыр юллар да...

...Очрашулар (язган булса!) —
Ходай бирмеш төштә генә.
Фәкать төштә.

Төш — хыялланган чынлык үзе.

*2003, 1–2 гыйнвар*
*Казан*

## БӘЙЛЕЛЕК

Якты йөзе...
Мәгънәле сүзе...
Талант үзе!

...Илһамлы каләме өстеннән
гомере буе
карап торды ипи күзе.

*2003, 19 гыйнвар*
*Аккош куле*

## КИСӘТҮ

Гарәп?
Латин?

Язсыннар кириллицада
беткәнче каралары!
Чиркәү динен өйрәнсеннәр
мөселман балалары!

Эшлә, татар! Тирдә парлан...
Азма син үз башыңа!
Теләсәк хач беркетербез
Сабантуй колгасына...

*2003, 19 гыйнвар*
*Аккош куле*

## ПАРАДОКС ТАКМАКЛАР

*(Шаяру)*

Ике әби күмер чаба
шахтада.
Ир егетләр чигү чигә
яктыда.

Ябалаклар чут-чут сайрый
гөлләрдә.
Сандугачлар тычкан тота
төннәрдә.

Кабан күле спирт булган
алкашка.
Галимнәргә надан килә
алмашка.

Кем мәйданда, чүлмәк итеп,
баш вата?
Колмак баткан дәрьяда
таш калка.

*2003, 28 гыйнвар*
*Казан*

## БУЛМЫЙ УЛ...

Багар күгең аяз түгел икән, —
йолдызларны танып булмый ул.

Хәсрәт чигеп, аерым-аерым торып, —
бер шатлыкта янып булмый ул.

Илаһ көчләр әгәр белдермәсә, —
җандашыңны табып булмый ул!

*2003, 4 февраль*
*Аккош күле*

## ЯШӘҮ

Озын гомер телисең син, әй, юләр!
Бер көнемдә күпме газап-тетрәү!
Өлгералмый иртә таңнан төнгәчә
Ышанычка куеп йөрим мин терәү...

Озын гомер телисең син, акыллым!
Көнем туса, җиргә сыймый шатлыгым!
Һәр мизгелдә тоеп яшим: бәхетемдә
Тудыручым — Бөек Көчнең хаклыгын.

*2003, 5 февраль*
*Аккош күле*

## УЛ

Түрә-хакимнәрнең хозурында
Самоварчы малай булмады.
Ил колагы хуш булырлык итеп,
Ул үзенең көен уйнады.

Тәкъдир язган биеклекләренә
менмичә талмады канаты.
Халык бәгыренә үтә алгач,
Күкләрдә язылды үз аты.

*2003, 9 февраль*
*Аккош күле*

* * *

Алай итте,
болай итте...
Әле кайтты,
әле китте...

Әйтте Күкләр:
«Әй, балалар,
Ягез, җитте!»

Ачу туды,
үпкә туды...
Күңелләргә
рәнҗү тулды...

Әйтте Күкләр:
«Әй, балалар,
Ягез, булды!»

....................

...Инде менә
булынды да,
җителде дә!

Утырабыз
бәхетебез
китегендә.

*2003, 19 февраль*
*Казан*

* * *

Очкычлар ватылгач, җирдән
«кара тартма» эзлиләр...
Сер тулы «күңел төене»
бар ул һәммәбезнең дә!..

Күп серләр мәңге ачылмый,
һәм кирәкмидер дә...
Алар, ахры, Күккә ашадыр
Җан рухы белән бергә.

Карагыз Күк гөмбәзенә! —
йолдызлар — тоташ тылсым!
Уртак сер булмаса аларда,
ул берлек каян килсен?

*2003, 19 февраль*
*Казан*

* * *

«Бетсәң бет, әмма тәңгәлләш!
Сула минемчә генә!
Юкса тәрәзәңдә булыр
рәшәткә белән келә!
Үз өеңдә дә йөрерсең
билдән иелеп кенә!..»

Импер-интер кыланыштан
Күктәге Кояш көлә:
«Кеше ирегеп тыеп булмый,
ул — Табигатьтән килә!
Ул — Иләһ көчтән килә!»
Җир кирегә әйләнә алмый,
Пигмейлар әйтеп кенә...

...Тәңгәлләшеп буладыр ул
тик Мәхәббәттә генә!
Анда да әле азга гына —
назлы рәхәттә генә!

*2003, 19 февраль*
*Казан*

* * *

Мәктәп-сарай!
Укы гына!

Компьютерлар, спортзаллар…
һәм маңкалы наркоманнар!..

Алачыкта укып, күпме
бөек чыккан!
Һай Заманнар!

*2003, февраль*
*Казан*

## ПЕНСИОНЕР

Гомер буе налог салынды…
«Үзең теләп» заем алынды…
Авыздан өзеп җыйганны
«реформа» суга салдырды —
умачлык онга калдырды —
бер көн эчендә яндырды!

…Пенсия акчасы, белмим,
фатир түләргә калырмы?
«Якты киләчәк»кә чаба-чаба,
үләргә соңга калынды.

*2003, 13 июнь*
*Казан*

* * *

Шагыйрьләр алар картаймый.
Шагыйрьләр ара гына...
Вакыт иңсәсенә басып
ял итеп ала гына...

Туксанда да ялганның ул
суга ала яңагына.
Шагыйрьләр пыскый алмыйлар.
Шагыйрьләр яна гына!

*2003, 16 август*
*Аккош күле*

## АЙКАЛЫЙ-АЙКАЛЫЙ...

*Берәү авызыннан*

Нәсарани да җаный!
Гыйбарани да җаный!..
Яшь чакта, бәлки, ярый...

Олыгайгач, картайгач,
тарихи ген аваз салып,
күңел сызлый, җан каный,
айкалый-айкалый...

Бабайлар рухы — аңда.
Интер балалар — алда.
Кяфер телен шәп беләбез,
оныклар аңламага!

Бәгыреңә тулган моңны
кем аңлый да, кем таный?

Күңел сызлый, җан каный
айкалый-айкалый...

*2003, 4 октябрь*
*Аккош күле*

* * *

Яшьлек чыннан да яшелдер.
Яз төсе бит — яшел.

«Саргаеп бөрешкәнеңне
яшь күзләрдән яшер!» —
дип әйтүгә, Күк катында
яшьнәп алды яшен!

*2003, 5 октябрь*
*Аккош күле*

* * *

Мәхәббәттән — Нәфрәт туа ала.
Нәфрәттән —
туса туар
Үч кенә.
Ә Үчнең рейтингы кечкенә!

Парадокс:
Судан туа ала Ут!

...Кеше зирәгрәк булган саен,
күп чак
бәхете юк!..

*2004, 5 гыйнвар*
*Аккош күле*

## М. ЮНЫСКА

*Хәзер син кайсы ярларда?*
*(1970 еллар көндәлегеннән)*

Бу диңгезләр — йөзеп бетәрлекме?
Күк катлары — очып җитәрлекме?
Дөнья гамьнәре — исәпләрлекме?..

...Йөзгән, очкан, гамьнәр эчкән
бер егет бар — Исәргәпнеке.

*2004, 7 гыйнвар*
*Аккош күле*

## УЕНЧЫ

*Безнең әти уенчы!*
*Куенында куныймчы!..*

*«Безнең әти аючы» көенә*

Уенчының нәфес шәп була!
Уенга ул «отам!» дип керә...
Кайчак төлке дә бит капкынга
«Җимне йотам!» дип керә!

Еллар узгач,
йоннар тузгач,
төшә сәхнәдән
уен төлкесе...

Уйнамаганнар алдында —
адәм көлкесе!

*2004, 11 февраль*
*Казан*

## ЧАРАСЫЗ ЮАНУ

Беткән... Сөяк белән тире... Тиздән
бакыр акча ятар күзенә...
Юк! — бу якты яз, дәрте ташкан яз
мәет төсен алмас үзенә.

Кояш нуры өчен түгел, фәкать
туфрак кына йотар җәсәд бу.
Тән-кабыктан җаны чыгып очар —
Җир өстендә урын исәпле...

Ә шулай да кеше кадәр кеше
чыга алмыйдыр ул гел юкка.
...Хәтер булып йолдызларга кунар,
рәшә булып иңәр офыкка.

*2004, 15 февраль*
*Казан*

## ТОРМЫШ КЫРЫНДА

Шатлык кына шытсын диеп,
чәчкән идем мул итеп мин
гел Өмет орлыклары...

Каян чыгып тулышып үскән
Үкенеч башаклары?

«Ур!» ди Язмыш!

...Урак кебек бөкерәеп
аптырап торам.

*2004, 26 август*
*Аккош күле*

## ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР...

Заманында урыс патша Зөясуда шәһәр-кирмән салдырды.
Безнең башлык тәре-сурәт иконаны Ватиканнан алдырды.
«Казан нуры» мәчетендә шушы хәлгә нинди вәгазь,
белмибез.
Мәскәүдәге иң олы поп: «Вот басурман, һай, молодец!» ди,
имеш.
Тырышсалар, тәре-икона Казанга да хуҗа кебек кайтыр
әле!
Болай барса, һич шөбһә юк: милләтебез гөрләп «чәчәк
атар» әле!..

*2004, 3 сентябрь*
*Казан*

## БАР ИДЕ...

*(Түрәлектән киткәч)*

Таулар иелә иде...

Балта үтми!..
Сүз үтми...

Бар иде! —
һәр әйткән сүз
майга кергән пычак кебек
кисә-кисә
үтә иде!
Яшенташтай
өтә иде!
Хәтта сүзсез
күз карашы
җитә иде!..

Ятлап йөрерләр иде!
Әйткән сүзләрнең көенә
атлап йөрерләр иде...

Кайрадым балтаны —
үтә!
Сайлыйм сүзләрнең шәбен —
үтми...

Бу дөньяга
ни җитми?
Ә?

*2004, 14 октябрь*
*Казан*

* * *

*Бер каләмдәшкә*

Ходай аңа күпне биргән.
Иман гына бирмәгән.
Халыкныкын күпләп алган.
Кайтарыйм! димәгән.

...Күрәсең, рәхмәтле булу
Табигатьтән иңмәгән.

*2004, 17 октябрь*
*Аккош күле*

* * *

Дулкын арты дулкын килә.

Берәүләр — илдән илгә күчә...
Берәүләр — ирдән иргә...
Берәүләр — диннән дингә...

...Бүгенге тау мәшәкатьләр алдында
кечкенә кала
кичә үткән кичә.

*2004, 17 ноябрь*
*Казан*

* * *

«Картлык — шатлык түгел». Хак сүз.
Ялгыз калсаң, һай, авыр!
Элек дару — агу иде,
хәзер агу да дару...

Яшьлектәге авырлыкны
дәртле куәт җиңә ала.
Сирәк кеше саклый көчен
Картлык дигән финалга.

*2004, 20 декабрь*
*Казан*

## ӘЙ УЛ ШАЙТАННЫ!

*Шайтан Адәм баласының*
*Кан тамырында йөри.*

(Хәдистән)

Моның шайтан күзендә үк!
Ку, ди, шайтанны!..

Төнге шашкын мәхәббәттән
югалткач аңны —
шатлык яше булып чыкты
кызның шайтаны!

...Фәрештәләр кул чаптылар
каршылап таңны!

*2004*

## САКЛЫЙК РЕСПУБЛИКАНЫ!

*(Нурихан Фәттахның*
*«Васыять» язмасы уңаеннан)*

*Диоген дигән бер мәшһүр*
*мичкәдә яшәгән, ди...*

*Егерме беренче гасыр бу*
*миладм исәп белән...*
*Мин әле туган халкымны*
*исән-сау диеп беләм!*

*«Сызгыра торган уклар»ның*
*тавышы колагымда!*

Атлантида калкып чыгып,
күтәрсен иде Аңны!
Күңелдә йөргән Дәүләт бар —
саклыйк Республиканы!

Губернияләп, гөбердәтеп
таркатырга татарны.
Ак Патшаларның хыялы!..
саклыйк Республиканы!

Онытмыйк, заман бае,
кайдан килеп чыкканны!
Илгә зәкят-өлеш чыгар,
саклыйк Республиканы!

Демократмы, коммунистмы,
уңмы, сулмы, уртамы —
кирәк чакта аңлашыйк —
саклыйк Республиканы!

«Бәхет Илендә яшим» дип,
васыять итмим мин аны...
Кем булсак та, җәптәш булыйк,
саклыйк Республиканы!

Беләм, күпләр сүгенә бүген —
«атаңны да, анаңны»...
Соңрак, бәлки, аңлашырбыз, —
саклыйк Республиканы!

Җөмһүрият! — дип, чын ирләрнең
күп акты шәһит каны!..
Respublika — бөек исем —
саклыйк Республиканы!

Алыштыручылар булса,
телне, җырны, иманны, —
үзләрен «җен алыштырсын»,
саклыйк Республиканы!

Татар кайда яшәсә дә,
Казан — аның бакканы...
Өзмик кардәшләр өметен —
саклыйк Республиканы!

...Тарихка тирән кергәннең
тарихта калсын җаны.
Наивҗанлык чоры түгел —
саклыйк Республиканы!

*2004*
*Казан*

# *Балалар өчен шигырьләр*



## СИНЕКЕ — ИЛНЕКЕ

Бу таулар да синеке,
елгалар да, таллар да;
кышкы ап-ак бураннар да,
җәйге алсу таңнар да…
Күргән, ишеткән, тойган
һәммә нәрсә синеке!

Син үзең соң кемнеке?
Ә син Туган җирнеке!
Сөенечләр китерсәң дә,
көенечләр китерсәң дә —
барсы газиз илнеке.

## ТАБИГАТЬ КОЧАГЫНДА

Гөл-чәчәкләр өзмәдек без.
Куаклар сындырмадык.
Яшел урман аланында
уйнадык та җырладык!

Кояшка карап елмайдык.
Җилләргә сәлам әйттек.
Һәркем өйгә алып кайтты
бер кочак сәламәтлек!

## БЕРДӘНБЕР

Туган ил — бердәнбер.
Әниең — бердәнбер.
Әтиең — бердәнбер.
Син үзең — бердәнбер.

Калырсың беркөнне
дөнья каршында
бергә — бер!
Хәвефләр алдында —
бергә — бер.
Сынаулар алдында —
бергә — бер.
Бурычлар алдында —
бергә — бер.
Намусың алдында —
бергә — бер...

Башкарган эшеңә
ни дияр
Ватаның,
әтиең,
        әниең?
Аларның хөкеме —
иң гадел, бердәнбер!

Әтиең, әниең
куанып туялмас,
әйтсәләр:
«Ул егет — Илдә бер!
Илдә бер!»

## АТЛЫ МАЛАЙ

Поездга да утырган бар.
Ә мин атны яратам!
Атта рәхәт! Кая телим —
тезгенне генә тартам!

Поездлар баралар алар
бер салган эздән генә...
Аннан дөньяны күрәсең
бары тәрәздән генә.

Атта, телим — кырга чыгам,
телим — тауларга менәм!
Иректне тою рәхәт шул,
куышып җилләр белән!

## САПЕР БАБАМ — ГӨМБӘЧЕ

Урманда гөмбә эзлибез.
Бабай таба бик оста!
Тиккәмени биш ел буе
сапер булган сугышта.

Бабай кызык: зур гөмбәне
миңа калдырып китә.
Ял иткәндә сугыштагы
хәлләрне сөйләп үтә.

Минага әләккән дусларым
булды, ди, әллә ничә!
Кызыл гөмбәләрне күргәч,
шулар, ди, искә төшә...

## ЯҢА КҮЛМӘК

Урамнарны айкап керә,
тыкрыкларга сугыла.
Әле генә чатта иде,
хәзер — чишмә буенда…

Ә бүген көн салкынчарак —
болыт та бар, җиле дә.
Тышта йөргән кешеләрнең
күбесе җылы киемдә.

Ә Әхмәтнең авыз ерык —
кыска җиңнән җил өрә!
Яңа бүләк-күлмәктән ич, —
туңмый ул шуңа күрә!

## КАЙСЫСЫ?

Капчыклап та бар йокы.
Янчыклап та бар йокы.

Капчыклап ал —
ялкау буласың килсә!
Янчыклап ал —
бай-сау буласың килсә!

## МИЛӘШ

Кызыл болыт кунганмыни
безнең бакча түренә!
Минем яраткан миләшем
быел шулай күренә.

Теләсәң, как итеп кой!
Теләсәң, әчетеп кой!
Теләсәң, тәлгәше белән
киптерергә элеп куй!

Әй быел миләш, миләш!
Күзнең явын алырлык!
...Очларына кул җитмәде,
чыпчыкларга калдырдык.

## ТАБЫНДА БАЛАНЛЫ БАЛ

Бабай әйтә: «Аша, балам,
балга кушылган балан!»

Күз алдымда — җәйге яшел
Кояш төшкән аланнар!
Аланнарда ак чәчкәдә
күкрәп үскән баланнар!
Кортлар бит бу алтын балны
алардан да алганнар!
...Җәйне хәтерләтеп, янда
чәчәк аткан яраннар!

Якут балан! Гәрәбә бал!
Кашыгың тутырып ал!
Җәй нигъмәте алда торса,
кышкы табын бик ямьле!
Баланлы бал бик тәмле!

## БАБАЙ БЕЛӘН МАЛАЙ

– Көнозын хәрәкәттәсең!
Ничек армыйсың, балам?
Мин менә капка төбенә
чыгып йөрсәм дә арам...

– Сиңа, бабай, комачаулый
таянып йөргән таяк!
Кәвешләреңне сал, әйдә,
йөгерик яланаяк!

## МЕНӘ БЕЗНЕҢ ГАЗИЗ НИНДИ!

Китте көзен очар кошлар,
язын бер кайтырбыз, дип.
Кайткан чакта Газизгә дә
тел алып кайтырбыз, дип.

Язны көтми, Газиз кыш ук
сөйләп китте чатнатып!
...Кайткан сыерчыклар әнә
тыңлап тора шаккатып!

## БӘХЕТ ПИЛМӘНЕ

«Кемгә эләксә — шул бәхетле!»
диеп сүз беркеттеләр.
Бер пилмәнне итсез-нисез
гел камырдан бөктеләр.

Ашаганда һәркем көтте
шул хикмәтле пилмәнне!
Тик берәү дә әйталмады
«миңа чыкты!» дигәнне...

Карамый шул теләүгә дә,
чыкмады шул берәүгә дә!
Тәтемәсә дә кешегә,
эләкте пилмән песигә!

Ә песи һич шат түгел...
Боекса да ят түгел:
«Минем бәхет юк ла! — ди, —
итле пилмән чыкмады...»

## ТАУ ХӘТЛЕ АКЫЛ БЕЛӘН...

Абыйлар кинога бара.
Мин дә ияреп барасы!..
Тик абыйларның нигәдер
килми мине аласы.

Әбием килеп юата:
«Кайгырма, акыллым, — ди. —
Синең, кино күрмәсәң дә,
тау хәтле акылың!» — ди.

Алар китте. Ә без калдык
әбием белән икәү.
Эшең булса, аулакта да
күңелсез түгел икән!

Әле энә саплап бирдем
нечкә җефәк җеп белән.
Хәзер йомгак тотып торам
тау хәтле акыл белән!

* * *

Сизмәдем: ата каз өскә
килде ыслап.
«Чукыйм!» дигәндә, муенын
кыстым учлап!

Куркуын курыкмасам да,
яман кычкырдым!
Әни килгәнче муенын
тотып тордым.

Әни әйтә: «Сакланып йөр,
акыллым!» — ди.
Абый көлә: «Безнең өйнең
Гераклы!» — ди.

Гераклмы, мераклмы —
ансын белмим мин.
Малай булып, ата каздан
куркып йөрмим мин!

## АВЫЛ МАНЗАРАСЫ

Быгыр-быгыр кайнагач —
самавырдан пар чыга.
Тирләп-пешеп уйнагач —
түбәтәйдән пар чыга.

Йөгереп чапкан инештән дә,
чишмәдән дә пар чыга...

...Хәрәкәттә — бәрәкәт, дип
оча күктә карчыга!

## ШАЛКАН БӘЯСЕ

Булсынга дип эшләдек без —
хезмәт иттек, көч салдык.
Шалкан чәчеп үстердек тә,
рекордлы уңыш алдык.

Бер иң зурын күргәзмәгә
иттек без җибәрәсе.
Алтын медальгә тиң булды
безнең шалкан бәясе!

## ТЕШ

Тешсез кеше —
ашсыз кеше.
Ашсыз кеше —
башсыз кеше.
Башсыз кеше —
эшсез кеше.
Менә сиңа
тешсез кеше!

Ә син, малай,
авызыңны
ерма алай!
Һәм шулай ук
җебеп үк тә
төшмә алай!

Әгәр синең
теш сызласа —
табибка бар!
Карасыннар,
тишек булса —
ямасыннар;
черегән булса —
суырырлар да,
утыртырлар
яңасын да!
Һәм әйтерләр:
яхшы малай!
Вәт ичмаса
башлы малай!

## КЫШКЫ КӨНДӘ ҖӘЙГЕ АВАЗ

Җәйге көндә — басмада,
челтерәп чишмә агуын
язып алдым тасмага.
Магнитофон отып алды
сандугачлар тавышын,
өстәп тагын яздым әле
шаулауларын камышның...

...Хәзер кыш. Бөтен җир карда.
Ә мин өйдә утырам.
Ике кат тәрәз артында
Буран бабай котыра!
Магнитофонны алдым да
көйләдем җайлап кына.
Камышлар шаулап тора!
Сандугач сайрап тора!
Инешләр агып тора!

...Буранда тәрәз рамына
сыенып торган чыпчык та
канатын кагып тора!

## САРЫ ЧӘЧӘК — ТУЗГАНАК

«Башка сары таҗ
кидем мин! — диде, —
Кояштан да шәп
инде мин!» — диде.

Чыннан да матур!
Чыннан да сары!
Әллә ничә көн
нурланып янды.

Берничә көннән
таҗы урынында
ак бүрек иде.
«Мин айдан да ак
икәнмен!» — диде.

Чыннан да матур!
Чыннан да нәфис!
Торды ул горур
әллә ничә кич.

Ә бер көн баксаң —
сары таҗ кая?
Ак бүрек кая?

...Сузаеп калган
сулган сабагы
җилдә чайкала.

## ТЫРЫШЛЫКТА ЯРЫШЫЙК!

Шахматта Маратны җиңдем.
Бәхәс купты әйләнәмдә!
«Җиңдеме икән акыл белән?
Җиңдеме икән хәйлә белән?»

Багана очына менәм.
Классташлар телгә килә:
«Менде микән көче белән?
Менде микән хәйлә белән?»

Мәсьәләне алдан чишәм.
Алар тагын бәхәсләшә:
«Башы белән чиште микән?
Хәйлә белән чиште микән?»

...Ә мин эчтән генә көләм!
Ничек итеп җиңгәнемне,
ничек итеп менгәнемне,
ничек итеп чишкәнемне
бер үзем генә беләм!

Теләсәгез, тырышлыкта
ярышыйк бергә-бергә!

## БЕЗ — БАЛТА ОСТАЛАРЫ

Кемгә — койма!
Кемгә — капка!

Булсын гына
яңа кадак,
яңа такта!

Кемгә — бура!
Кемгә — колга!
Булса кулда
яхшы балта,
үткен пычкы
һәм дә теләк:
кемгә — келәт,
кемгә — көрәк!
Тагын кемгә
нәрсә кирәк?

Беләктә — көч!
Кулда — чүкеч!

Кемгә — шкаф!
Кемгә — киштә!
Күңел салгач
сөйгән эшкә,
туйдырмый ул
агач тәмен
тою һич тә!
Киләә бирсен
урман исе
иртә-кич тә!

Агач җаны
яши алса
без ясаган
җиһазларда,
без төзегән
биналарда —
сөенәбез
без шуңарга!
Урман булып
шатлык шаулый
безнең җанда!

Күңелдә дәрт,
кулда җегәр
йөрткән чакта —
кемгә — сандык,
кемгә — тартма!..
Булсын гына
яңа кадак,
яңа такта!

Эшләребез
балкып торсын
Туган якта!
Искә алып
яхшы сүзләр
сөйләсеннәр
безнең хакта!

## СУЫК!

Чеметтерә суык!
Бала-чага чаба
битен-кулын уып!

Үҗәт тә соң суык!
Якадан, җиңнәрдән
керә, явыз, шуып!

Тиктормас бу суык!
Тәрәзләргә куйган
мөһерләрен сугып!

Мәрхәмәтсез суык!
Кош-кортлар ояда
бөрешкәннәр туңып!

Озын куллы суык!
Әнә Ай тирәли
төшкән алка куеп!

Каныкты бу суык!
Йөри кешеләрне
өйләренә куып!

...Күпме нык торса да,
беркөн китәр ул да!
Йә качар ул сулга,
йә олагыр уңга...
Аны куар җылы
җилләр инде юлда!

## ӘЧЕ КҮЛДӘ

*Габдулла агай Шамуков белән Каракалпакстандагы бер сәяхәт истәлеге.*

Биек вышкадан сикерде
җитмеш яшьлек бер бабай!
Тел шартлатып карап торды
яр тулы малай-шалай.
«Менә, малай, вәт бу — бабай!»

Суга бик күп керсәләр дә,
ярда шаулап йөрсәләр дә,
дулкынга таш атсалар да,
ярда кырын ятсалар да...
малайларның берсенең дә
сикергәне юк алай!

Берсе әйтә: «Бабай — кыю,
ике йөрәкледер! — ди. —
Спортсмен түгел микән,
сорап карыйк — әйтер», — ди.

«Әй, малайлар, белмисезме?
Минем бит эшем шундый!
Сәнгать усал: артист булсаң,
төрле сурәттә бул! — ди. —

Патша булам мин, кол булам,
дошман булам, дус булам...
Кирәк икән, сезнең алда
балык булам, кош булам!

Вышкадан бу сикерүем —
кош һәм балык булуым!
Хәзер сезгә аңлатуым —
тренер булып торуым!

Сикерү — нәрсә? Сикереп була!
Тик булсын гына теләк!
Һәркем сикерә, әгәр йөртсә
Теләккә тәңгәл йөрәк!..»

...Ул көн һәркем су буеннан
үз уе белән кайтты.
Бабай сүзләре аларда
бер ашкыну кузгатты.

Арттан вышка карап калды,
шулай таңгача көтәр.
Иртәгә кайсы малайның,
белмим, йөрәге җитәр?..
Бабай күк сикереп шулай,
шәп итеп йөзеп китәр...

## ТӨНБОЕК

Тәпи — җирдә, гәүдә — суда,
башым — ачык һавада.

Кышын күл төбендә йоклыйм,
җәен — басам яңадан!

## МАВЫГУ

Телефильм, мультфильм...
Ун да унбиш серия!
Төн урталарына кадәр
барсын карый Сәрия.

Экранда тормыш бара —
яшәү, көрәш, хәрәкәт...
Син үзең дә хәрәкәтлән —
шунда булыр бәрәкәт!

Футбол, хоккей карауны да
саный Сәрия эшкә.
Иртәге көн өлгерә
төштән соңгы дәрескә...

## ТРАМПЛИНДА

Урман эченнән чыгып,
трамплин өстенә
тәгәрәп килде дә Ай —
әйтте, ахры, ай-яй!
Уңайсыз төшсәң җиргә,
йә менә алмам күккә, —
сикермим әле тиккә!

Трамплинда мәче!
Ахры, сикермәкче!
Колакларын шомартты,
уңга-сулга күз атты,
мыекларын кабартты... —
борылып кире чапты!

Чүлмәкчедән күрмәкче!
Ай сикерә алмаганны,
ничек сикерсен мәче!

...Трамплин өстенә
яшь егетләр килделәр.
Чаңгыларын киделәр.
«Без дә сикерә алмагач,
кем сикерсен?!» — диделәр.

Очтылар бер-бер артлы.
Җитезләр! Кош кебекләр!
Кирәк — җирдә, кирәк — күктә
дан ала шәп егетләр!

## КҮМӘКЛӘР ҺӘМ КӨЧЛЕЛӘР

Энә күзеннән үтәрлек
бөҗәкләр булсалар да,
шомлы кара урманнарның
эчендә торсалар да,
аюдан да курыкмыйлар,
еланнан да курыкмыйлар!

Бик исләре китми бугай
җилгә дә, яңгырга да!
Курыкмыйлар — үзләренә
ышанычлары барга!

Чөнки — бергә! Чөнки — күмәк!
Чөнки — уртак бар теләк!
Максаты бер булганнарны
ничек җиңалмак кирәк!

Табигатьтә бөҗәкләр күп,
тик беләбез сирәген.
Белмәгән кеше бар микән
кырмыскалар дигәнен?!

Кемнәр сокланып карамый
алар корган өйләргә!
Булдыра алар үзләреннән
күпкә зур йөк сөйрәргә!

Үзләренчә бер тәртип бар
яшәү рәвешләрендә.
Чисталык һәм мәгънә бар
кылган һәр эшләрендә.

Әллә инде кешеләр белән
уртаклыклары барга? —
кырмыскаларның үзгә бер
даны бар дөньяларда.

Табигатьтә бөҗәкләр күп,
тик беләбез сирәген.
Белмәгән кеше бар микән
кырмыскалар дигәнен?

## ТУП

Ул йөгерә —
мин чабам.
Ул качмакчы —
мин табам.

Ул сикерә —
мин тотам.
Очып китәр
дип куркам!

## БАКЧАДАГЫ КОМЛЫКТА

Кызлар эше димәдек —
иләдек тә иләдек!

Ком гел коела торды,
иләк эченә кирәкмәс
чүпләр җыела торды.
Кем нәрсәсен югалткан —
комлык барсын да йоткан.
Чыкты комнан —
төймәләр,
    каптырмалар,
        шөрепләр,
            шнур-баулар,
                авторучка башлары,
                    буяу карандашлары...
Чыкты ялтырап хәтта
        кемнеңдер йөзеге дә.
Табылмый калды шикелле
елан мөгезе генә!

Кайберебез ком «тетте»,
кайберебез чүп түкте...
Бергә-бергә эшләгәч,
бер сәгатьтән эш бетте!
Иләкләр бушап калды,
комлыгыбыз чистарды!
килсен хәзер нәниләр!
Уйнасыннар биешеп,
тәгәрәшеп, көлешеп...

Кызлар эше димәдек —
бүген без он иләдек...
Он түгел,
ком иләдек!

Апабыз әйтте: эшебез
әтиләргә сөйләрлек!
Әниләргә сөйләрлек!

## АПТЫРАШЛЫ ХӘЛ, ЯКИ УТАУ УРЫНЫНА БУТАУ

Бабай әйтте: кишерләрне
басып киткән чүп үлән!
Түтәлне карарга чыктым,
шуны ишетү белән.

Түтәл тулы — гел үлән...
Утап ташладым барын!
«Кишер кайда соң монда?» — дип,
хәзер карап торамын.

## ХЫЯЛ

Җир өстендәниләр бар?
Әтиләр, әниләр бар.
Шәһәрләр бар, илләр бар.
Урманнар бар, чүлләр бар...

Җир асты да хикмәтле!
Анда хәзинәләр бар.
Алтыннар, көмешләр бар,
диңгезләр, инешләр бар...

Күк катында ни юк дисез!
Йолдызлар бар, Айлар бар,
яшеннәр бар, карлар бар...

Ә Булатның күңелендә
беләсезме ниләр бар?

Бар аның зур хыялы!
Бәлки, андый зур хыялның
юктыр әле булганы!
Аны Җир дә белми әле,
аны Күк тә белми әле,
аны беркем белми әле!..

Бер көн килер, үсеп җитәр —
хыялын ул чынлык итәр!
Ул хыялны Җир дә белер,
эшкә ашуын Күк тә күрер!
Әлегә ул, серен саклап,
нәни генә малай булып,
чирәмлектә аунап йөрер.

## ОНЫТМА СИН!

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!

Бел син ерак бабайларның
ничек итеп көн иткәнен,
ни иккәнен, ни чиккәнен,
нинди уйлар, нинди моңнар
безгә калдырып киткәнен.

Исеңдә тот, аларның син
сугышларда кан түккәнен,
Туган җирнең иреге өчен
зинданнарда интеккәнен...

Һәр карыш җир сугарылган
шәһит җаннар каннарында.
Үткән яулар шәүләсе бар
Туган якның таңнарында.

Һәр нигезнең, һәр авылның,
һәр каланың үткәне бар...
Гыйбрәт алырлык мирасның
калганы бар, киткәне бар...

Горур сүз әйт, сорасалар:
«Ни кавемнән? Нинди җирдән?»
Киләчәккә аек карар
үз тарихын анык белгән!

Хәтерләүдән курыкма син!
Ил үткәнен онытма син!

## ЧИКЛӘВЕК

Өлгермәгән җәен
кызынып калырга.
Көз җиткәч уйлаган
киемен салырга.

Ялангач көенә
сикергән дә җиргә,
яңгырда чыланып:
– Туңам, — дип тилмерә.

Төньяктан җил өрә,
кыш аяк киенә.
Ярый ла чикләвек
очраса тиенгә.

## ИКМӘК ЗАВОДЫ ЯНЫННАН УЗГАНДА

Юк,
торбалардан чыккан төтеннәр —
хәрби завод төтене түгел!
Икмәк исле бу төтеннәр күләгәсе —
иген өсләрендә иңрәп торган
рәшәләрнең гүя чалымы!
Борыннарны кытыклаган
бу тәмле ис —
балачакның гүя сәламе!

## ТУГАЙДА

Йөрәк «дерт» итте —
чиртте!

Сабырлык җиткән чиккә:
кармак — күктә!

Әй, китте очып балык, китте —
кошлардан да биек —
алды бугай болытларга тиеп!
Аңлап булмый беравык —
әллә тургай, әллә балык?!

Бармак хәтле балык —
дөнья кадәр шатлык!
Чөнки бу чын балык,
алтын балык кына түгел, —
тере балык!

Әнә ята яшел чирәмдә,
күзнең явын алып,
ышанмасаң —
кара алып!

# ЯҢГЫРДА

Чәчәкләр җыярга
чыктык без болынга.
Очрадык яңгырга.
Барырга кая дип
торганда уйланып,
беткәнбез чыланып.

Ә нәни бал корты
аптырап калмаган.
Яңгырдан сакланган:
бер үлән астына
качкан да
өстенә
яфрак каплаган.

## ҖИЛӘК КАЙДА КҮП?

Әти, әни, мин — өчәү
йөрибез аланда.
Җыябыз җир җиләк,
үләнне аралап.

Җиләк бар аланда!
Яхшылап карале:
очрый ул алда да,
күренә янда да…

Шулай да җиләкләр
күбрәк табыла
әтием янында!
Әнием янында!

## ТУГАН КӨНДӘ

Өлгеләр тулы — Кояш,
көзгеләр тулы — Кояш,
әби күзлегендә — Кояш,
песи күзендә дә — Кояш...
Җиргә төшкән мең Кояш!
Күктәгесен дә санасаң,
бүген мең дә бер Кояш!

## НИ ЯХШЫ?

Нинди баш кием яхшы?
Эшләпә дә бик яхшы.
Түбәтәй дә бик яхшы.
Малахай да бик яхшы.
Фуражка да бик яхшы.
Папаха да бик яхшы!..

Тагын соң нәрсә яхшы?

Шуларны кияргә лаек
акыл булган баш яхшы!

## КЫРМЫСКАЛАР УТЫРТТЫ!

Бал утырсын дип салган
зур тәпән буп-буш калган!

Аптыраш хәл бабайны
бастырды бер, утыртты:
«Бал утырып утырмады,
кырмыскалар утыртты!»

## ҖӘЙГЕ ҖЫЛЫ ЯҢГЫРДАН СОҢ

Көтмәгәндә
җылы яңгыр
явып үтте.
Гөрләвекләр
җәй тузанын
юып китте.

Кояш чыкты
болытларның
читен ачып.
Җиде төсле
буй сөлгесен
иңгә асып.

## ТАҢ

Таң ата дип ишеткән бар
әбидән дә, бабайдан да;
ә үземнең таң атканын
күргәнем юк беркайчан да.

Бүген менә шуңа күрә
уяндым да караңгыдан:
«Таң ничек ата икән?» — дип,
тәрәзәдән карап торам.

Башта үзем куркып куйдым —
караңгыда күрә алмам.
Хәзер тышта якты инде,
таң атканын күрми калмам!

## ТУЗГАНАК

Мин эзлим кузгалак, —
очрады тузганак!
Башында ак бүрек —
кечкенә туп кебек!

«Тотам!» дип үрелдем,
ул миңа иелде.
Бүреген салды да:
«Өзмә!» — дип ялынды.

## ЮЛГА ЧЫККАЧ, УЙ КИЛӘ

Үткән ел йөрдем көн саен
ун чакрым чаңгыда.
Исәпләсәң, кыш буена
мең чакрым юл чыга!
Бездән Мәскәүгә кадәр ул
сәфәр чыккан юлчыга.

Шулкадәр еракка киткәч,
кайтасы да була бит!
Быел тагын мең чакрымлап
юл шууым шуңа бит!

...Карлар эрер. Килер җәйләр!
Бер уй йөри күңелдә:
Каспийга кадәр җитәм дип,
җәй йөзәрмен Иделдә.

## ЯРЫШТА

Чаңгы эзләре күмелгән.
Буран булды шул кичә!
Бүген тагын эз салырга
старттан — финишкача.

Бу эшкә Алмаз алынды.
Эз салды бата-чума.
Кар еру җиңел түгел шул —
бүрегеннән пар чыга!
Бер сәгать тә үтмәгәндер,
юл ачык ярышчыга!

...Өйләдән соң класс белән
чыктылар ярышырга.
Эздән күбрәк үткән саен
чаңгы шәбрәк шуа!

Әй чабышты соң балалар!
Әй узышты малайлар!
Финиш якын калган саен,
кызурак баралар!

Дистанциянең башыннан
бу юлы да алда Алмаз!
Комач финишка җитәргә
калган иде инде бик аз, —
кинәт алга ыргылып
беренче килде Нияз!
Өч-дүрт адым артка калып
икенче булды Алмаз...

...Ярыш беткәч тезелделәр.
Нәтиҗәләр әйтелде.
Физрук әйтте: «Икәвенә —
Алмаз белән Ниязга —
беренче урын!» — диде.

Берәү дә үпкәләмәде.
Һәммәсе дә сөенде.
Чөнки болай дип белдерү
бик гадел хөкем иде.

Алмаз да шат. Нияз да шат.
Елмая, көлешәләр!
Хәер, һәрбер җиңүчегә
елмаю килешә ул!

## ЯҢГЫРДАН КОРЫ ЧЫКТЫК

Күкне иңләп болыт килә.
Япан кырда без икәү —
абый да мин. Яңгырда, дим,
без күшекмәбез микән?

Абый әйтә: карап торма,
киемнәреңне сал, ди.
Чалбар-күлмәкләреңне син
төреп куенга ал, ди.

Шундук болыт каплап алды,
яңгыр басты дөньяны.
Күк белән җир арасында
тоташ су толымнары!
Йөгерәбез ера-ера
гөрләвек-елгаларны.

Йөгерәбез өйгә таба.
Йөгергәч, туңу кая!
Кара болыт та ашыга,
мичкәләп коя-коя!

...Берзаман яңгыр туктады.
Күкләр калды аязып.
Без дә кидек киемнәрне,
нәни түмгәккә басып.

«Нәрсә булды соң?» — дип бугай,
әрлән чыккан өненнән.
Бөтен дөнья манма суда,
ә без коры киемнән!

## ОЧТЫ, ОЧТЫ...

Очты, очты, каргалар очты!
Башта кара каргалар очты!
Аннан ала каргалар очты!
Аннан бала каргалар очты!

Артларыннан табалар очты!
Табада борчаклар бар иде!
Шундый эре борчаклар иде!
Шундый тәмле борчаклар иде!

Борчакны күргәч, каргалар
әй шатланырлар инде!
Болытлар да, кырын ятып,
ашап ятырлар инде...

Шундый тәмле борчаклар иде!
Торналарны да табынга
чакырсалар ярар иде!..

## БУ ПЕСНӘКНЕҢ САЙРАП НИ ДИЮЕ?

Ак карларга очып куна.
«Дзинь! Чинь!»
Аклыкка «сау бул» диюе!

Күккә карап, әй очына!
«Дзинь! Чинь!»
Зәңгәрлеккә сөенүе!

Пырх-пырх канат кага.
«Дзинь! Чинь!»
Суык җилләрне кууы!

Бөреләрне сыйпап ала.
«Дзинь! Чинь!»
Яшеллекне чакыруы!

## БИЯЛӘЙ

Үзе җылы, үзе матур!
Менә дигән бияләй!
Ник булмасын менә дигән —
әбекәем бәйләгән!

Бәйләм юлларына кара,
кара күзәнәкләргә!
Җепләрдән нурлар үрелеп,
әйләнгән бизәкләргә!

Суыкларга ис тә китми,
бияләем җылы ич!
Юешләнсә, өйгә кайткач,
киптерә аны җылы мич!

## БЫЕЛГЫ ЯЗ

Ак куяннар хәйран калды
быел яуган ак карга!
Тал песиләр су коенды,
ташулар менгәч ярга.

Тау башыннан карап тордык.
Инешләр дә — Иделдәй!
Бәлки, быел безнең якка
аккошлар да килерләр.

## САБИР НИГӘ СӨРТЕНӘ?

Урамнан Сабир килә.
Абына да сөртенә!
Тезе җиргә төртелә!..

Нигә соң ул сөртенә?
Күреп, кешеләр көлә!
Сабир артыннан, сөйрәлеп,
башмак баулары килә...

Сөртенә дә абына,
абына да сөртенә...

Шулай ул: кулың иренсә,
аякка авыр килә!

## КАР АСТЫНДА УМАРТАЛАР

Котыра буран! Ышанамы
дөньяны күмәренә?
Кар астында бал кортлары
йокымсырый өннәрендә.

Бал кортлары белмиләрдер
Җирдә Кыш бабай барын.
Үзе белән алып килгән
суыкларын, бураннарын...

Күрәләрдер нәни җаннар
төшләрендә болыннарны,
юкәләре чәчәк аткан
сандугачлы урманнарны!

## КҮКЕ НӘРСӘ ДИП ӘЙТӘ?

Аны гомер юрый, диләр.
Аны еллар саный, диләр.
Санамый ул, чакыра!
Аңласагыз, кычкыруы
бүтән нәрсә хакында.

Килегез, ди, урманнарга,
чыгыгыз, ди, болыннарга,
торыгыз, ди, безнең янда
бер тапкыр да,
өч тапкыр да,
ун тапкыр да,
йөз тапкыр да...

Суларсыз, ди, һавасын,
тоярсыз, ди, дәвасын!
Күңелләрегез яктырыр,
йөзләрегез балкыр, ди.
Шулай булса, гомерегез
санамый да артыр, ди.

## ТӨСЛЕ БУЯУЛЫ ТУПЛАР

Минем тупта — ат сурәте.
Ләйләнеке — аккошлы.
Кечкенә инеш аркылы
уйныйбыз туп атышлы!

Сикерә-сикерә туп чөябез
инеш җыры көенә.
Әле маэмай күккә менә,
әле аккош чөелә...

Туплар — шаян, туплар — наян!
гел-гел төшми куенга!
...Әнә аккош чирәмдә ауный,
маэмай суда коена!

## БАБАЙ ТАЯГЫ

Бабай таягына чыпчыклар куна.
Бабай таягында эшләпә тора.
Бабай таягында сөялле куллар.
Бабай таягына озак еллар...

## КАЙМАКЛЫ ЧИЯ

Өстәлгә килсен өчен —
кирәк:

Сыерга татлы үлән ашатырга.
Чия куагын яхшылап утыртырга.
Сыерга кышкы җылы абзар корырга.
Чияне суыклардан саклап торырга.
Сыерны җәй буе көтәргә болында.
Чиягә көн саен су сибеп торырга.
Сыерны вакыты җиткәч үк саварга.
Чия төбенә ашлама салырга.
Сепаратта сөттән каймак аерырга.
Чияне кызаргач ук җыеп алырга.
Каймак белән чияне бергә бутарга.
Салкын базга төшереп бераз тотарга.
Һәм —
(ашыкма!)
кирәк тагын:

өстәл янында әдәпле утырырга.
Ашап туйгач, рәхмәт әйтеп, торырга.

## ПАЛАСНЫ КЕМ КАГАР?

Мәш килеп һәммәсе,
уйнаган котырып,
паласны тутырып.

Куяннар биегән,
тиеннәр сикергән,
елтыр күз «Айсылу»
бахбайда йөгергән.
Уеннан калмыйм дип,
Мырауҗан да кергән
күрше бүлмәдән!
Мәтәлчек атканнар,
тәгәрәп ятканнар,
шаярып чапканнар.

Берсе дә калмаган:
аю да калмаган:
керпе дә калмаган,
алар белән бергә
Алмаз да аунаган.

Палас тузанланган,
чүп калган, тап калган...

Уйнадылар, шәт, ярар,
ә паласны кем кагар?

## КӨЗГЕ ПЫЧРАК БЕР КӨННЕ...

Юл чыкканда бер галошым
калды шул сазда батып!

...Бер галоштан, бер оектан
ике эз калды ятып!

Өйдән итек киеп чыгып,
кереп алдым мин аны...

Солдат абый бер итектән
урап кайтты дөньяны!

Ә мин — «батыр», өч эз салып —
галош белән,
оек белән,
итек белән
чыктым бер тар урамны!

...Ярый беркем белмәде,
шуңа күрә көлмәде!
Малайлар көләр иде дә,
алар моны күрмәде!

## САБЫЙЛАР ЕЛЫ

Бик күп илләр сүз беркетеп,
бирешеп кулга кулны,
әйткәннәр: «Булсын шушы ел —
сабый балалар елы!»

«Сабый» дигәч, кем уйламас
әни-әти турында?
Шулай булгач, быелгы ел
ул — әниләр елы да!
Ул — әтиләр елы да!

Нинди генә чәчәкләр юк
балаларның кулында!
Шулай булгач, быелгы ел
ул — чәчәкләр елы да!
Чәчәкләргә кунып йөргән
күбәләкләр елы да!

Сугышларның, кырышларның
аркылы төш юлына!
Әйләнсен сабыйлар елы —
дуслык, бәхет елына!

Яңгырасын бар дөньяда
хөрлек, тынычлык җыры!
Быел балалар елы шул!
Быел сабыйлар елы!

## БАЛЫКТА

Кармак, җимнәр алдык та
иртүк киттек балыкка.

Бу кызыл суалчаннарга,
бу ак чебен кортына —
без тиешбез ким дигәндә
ярты чиләк тотырга!

Әйтик —
бишләп сыла,
ике-өч чуртан,
җиде бәртәс, бер җәен...
Корбан белән чабак балык
сансыз кабар, тәгаен!
Бу җепләр дә ярамаса,
бу кармак та тотмаса!
Кайтканда иңең салыныр,
балыгың баса-баса.

Тизрәк Ыкка!
Таллыкка!

...Инде кайтып киләбез.
Шырык-шырык көләбез.
Ни өченме көләбез?
Без үзебез беләбез...

Булатка алты чиртте.
Соңгысында чыгарды...
иләмсез зур бер галош!
Ничек җебе чыдады!
Миңа чиртте зур балык,
тик... булмады чыгарып!..

Кармак калды җәеннең
мыегына уралып!

Рим ярда күп чуалды.
Төрле урынга салды.
Берсендә чыгарды... минем
кармаклы суалчанны!

Безнең уртак юаныч —
Азат тоткан бер маймыч.
Ята чиләк төбендә,
ун грамм бар кимендә!

...Бүген юл бик уңмады.
Тота идек тотуын —
урыны җай булмады.
Без утырган тугайлыкта
җиле уңай булмады...

Иртәгә тотарга калды
бүгенгесе өчен дә.
Әйтик,
унлап сыла,
алты чуртан,
ундүрт бәртәс...

## КҮП АШАП, АЗ ЙӨРСӘҢ, ТИККӘ КОРСАК ҮСТЕРСӘҢ...

Тегүче сөйләп алыр —
моңа костюм зур кирәк!

Пешекче әйтеп салыр —
моңа азык мул кирәк!

Таксист уйланып барыр —
моңа урын күп кирәк!

Врач та әйтер: йөрәгенә
авыр килә бигрәк!

Ә, гомумән, юан булу —
әйтегез, кемгә кирәк?

## БУЛМАГАННЫ!..

Тал очыннан былбыл белән рәттән
ишетелә арыслан тавышы.
Умарта оясы ярыгыннан
башын тыккан бер тавис кошы.

Авыл читендәге Кече күлдән
ак акула бер үрдәк тоткан.
Ярый әле Салих бабай күреп,
бармак янап аны куркыткан!

* * *

Бу агачлар миннән олы.
Бу кар-көртләр миннән олы.
Бу чәчәкләр миннән олы.
Уйлап куйдым: бәлки әле
бу песи дә миннән олы?..

Бу дөньяда һәрбер матур,
һәрбер яхшы, һәрбер күркәм
үз урынында үзе олы.

Кем белә, миңа карап та,
бәлки әле берәр уйлы
әйтәдер: бу — миннән олы!

## ТАҢ АТУ

Нур укларын атты Кояш
офык-ярдан — Күк йөзенә!

Качты Төн —
ябалак күзенә!

## ЯХШЫ СҮЗ

Әйт кенә
тәмле сүз —
иркәләр
күпме күз!

Әйт кенә
яхшы сүз —
һәркемдә
көләч йөз!

## МАРАТКА НӘРСӘ ҖИТМИ?

Аквариумда су тынчу...
Балыкларга һава җитми!

Корылыктан чүлмәкләрдә
гөлләр сула, су-дым җитми!

Маратның җитеш һәммәсе!
Уйный-чаба, чаба-уйный!
Урамда саф һава сулый.
Тәмләп чишмә суы эчә...

Шулай да аңа бер бик кирәк
нәрсә җитми, безнеңчә!
Ул ни икән, сезнеңчә?

## БИНОКЛЬ

Киләчәк үзе йөгереп,
килеп баса минем алга!
Телим генә, минем алда —
кешеләр дә,
    агачлар да,
        мәйданнар да,
            кош-кортлар да.

...Әнә әни, эштән арып,
кайтып килә зур урамнан.
Бинокльдән карадым да, —
әни шундук минем янда!

Өстәвенә — сагынылган да!

## ИКЕ ЧӘЧӘК

Кояштай янды көн буе!
Кичен арып, япты таҗын.
Ә төшендә ромашкабыз
күрде Айны — кыйгач кашын.

Ә күршесе — зәңгәр чәчәк
йомылмады — ачык калды.
Ул төн буе күреп чыкты
йолдызларның атылганын...

## ЯҢГЫР

Күк гөмбәзе тишелгән!
Ага бөтен төшеннән!
Күк белән Җир — бертоташ.
Яше-карты чайкый баш:
«Ай-һай яңгыр бу яңгыр!»

Ә яңгыр малайлары —
кирәклеме димиләр,
кирәксезме димиләр —
сикерешеп төшәләр дә
биләр дә биләр!

Күк капчыгы чишелгән!
Тамчыга ни — чишенгән!
Тәгәрәшеп биешәләр
җирнең яшел түшендә.

Биләр күлләвектә,
биләр гөрләвектә,
тояк эзләрендә дә,
чәчәк күзләрендә дә...

Күпне күргән кешеләр,
туктап калып эшеннән:
«Артыкка китте! — диләр. —
җиргә дым җитте!» — диләр.

...Күкнең төбе тишелгән!
Болыт тавы ишелгән!
Коела гына тамчылар
теләсә кай төшеннән!

Җирдә рәхәт, дип микән,
без иректә, дип микән,
биләр дә
биләр!

## КЕМ КҮПМЕ ЧӘПЧЕТӘ?

Мин өч тапкыр чәпчеттем.
Ул биш тапкыр чәпчетте.
«Әй, сулагай-булмагай!» — дип
шапырынды Нәҗметдин. —
«Ике чәпчер ташны да мин
алты тапкыр чәпчеттем!»

Үзем дә кызып киттем!
Ул мактанчык Нәҗметдиннең
үзен дә кызык иттем —
башымдагы кепкамны атып,
суда сигез чәпчеттем!

## НИНДИ ХӘЛЛӘР БУЛМЫЙ ДИСЕЗ?

Теләсәгез — ышаныгыз,
теләсәгез — ышанмагыз, —
тырма белән чуртан тотты
бакча артыннан абзагыз!

Ул язны елгалар, ташып,
бик күп җирләрне басты.
Күл булды уйсу бакчалар,
кое күк — идән асты.
Сулар арткач, балыклар да
бакча эченүк килде.
...Аннан безнең өстәлгә дә
ерак калмый бит инде!

Берзаманны сулар качты.
Чуртан кача алмады!
Алты кило ярым чыкты —
кайткач үлчәп карадым.

...Түтәл өсләрендә язын
уйнаклап йөрсә чабак,
хәзер — чуртан тоткан төштә
тәгәрәп үсә кабак.

## ҖӘЙГЕ ТАЛГЫНЛЫК

Бабай утыра күләгәдә.

Басуларда рәшә тибрәнә.

Күбәләк кунган
җилтегермән канатына.
Үзе ял итә,
үзе әйләнә...

## ҮСҮ

Эшләр бара кая?
Эшләр бара шуңа —
Алмаз озыная!

Көннәр кыскара,
койма кыскара,
җиңнәр кыскара...
Әнә күктә Ай да
кечерәеп бара.

Ә Алмаз үсә дә үсә!
Һаман озыная!
Менә безнең өйдә
эшләр кая бара!

## ЭНҖЕ ҺӘМ АНАР

Ташта калын карлар...
Ә өстәлдә — анар!
Әй Энҗе куана —
кучтәнәч ул аңар!

Сеңдергән бу җимеш
җылы якның таңын.
Эче тулы кат-кат
кызыл энҗе аның.

Матур безнең Энҗе!
Акыллы да Энҗе!
Күзләре дә нурлы,
тешләре дә энҗе!

Чия иреннәндә
тагын энҗе, көрче!
Анардан ул ансы —
кызыл якут энҗе.

## НЕФТЬ

Тылсымлы куәткә ия
нефть дигән җир мае.
Ансыз хәзер күз алдына
китереп булмый дөньяны!

Күкләрдә самолет оча,
диңгездә кораб йөзә.
Җирдә — бихисап юлларда
күпме машина гизә!

Моторларның йөрәгенә
ул көч бирә, җан өрә.
Хәтта илләрнең куәтен
хәзер нефть билгели!

Ә ул байлык кайда дисез?
Ерак түгел, якында!
Күпме нефть вышкалары
безнең бакча артында!

...Кемнәр нәрсә уйлый дисез
шушы байлык хакында?

## ЧИТ АВЫЛДА

Саташып әтәч кычкырды,
кич җиткәч, Кояш баткач.
Әллә нинди төшләр керде
ят караватка яткач.

Уянсам, тәрәздән күрәм:
Ай — антенна башында!
Безнең авылда Ай калка
зәңгәр таулар каршыннан!

## КЫШ АЛДЫ

Кырмыска «өйләре» биек —
кыш суык буласыга.
Димәк, ягарга утын да
күп кирәк булып чыга.

Абзар-кураны җылыттык,
маллар туңмасынар дип.
Кош-кортка җим әзерләдек,
һәлак булмасыннар дип.

## ЮЛДА

Бер таяк.
Ике аяк.
Өч авыл.
Ун чакрым.
Егерме төш.
Утыз ике теш.
Кырык уй.
Йөз исәп.
Мең адым...

Уф, ардым!

Артымда —
биш чакрым.
Өч күпер.
Ике авыл.
Бер күләгә.
Ярты юл.

Алдымда —
биш чакрым.
Өч үзән.
Ике үр.
Бер авыл.
Ярты юл...

Һәм тагын —
бер Кояш.
Бер әби.
Бер бабай.
Аларга
кунакка
баручы
мин — малай.

## КҮРДЕМ ТӨРЛЕ ҖАНВАРЛАРНЫ

Аланда ап-ак куян күрдем.
Әй чапты соң! Әй йөгерде!
Хөрлеген, аклыгын күреп,
күңелемә пакьлек иңде.

Таллыкта кызыл төлке күрдем.
Койрыклары ай-һай нинди!
Аның шома йөрешеннән
күңелемә шуклык иңде.

Урманда соры болан күрдем.
Шундый мәгърур! Шундый эре!
Аның көчле сынын күргәч,
күңелемә гайрәт керде.

Зоопаркта арыслан күрдем.
Әйләнәсе читлек иде...
Күзеннән сүнгән үч күргәч,
Күңелемә сагыш иңде.

## АЛМАПАЙ

Кичә алма бакчабызга
кергән иде Алмапай,
әйттем: «Пешкән алмаларны
үзең сайлап ал, апай!»

Бүген үзе чакырып алды:
«Мә сиңа бал, балакай!»
«Кем бирде?» —
дип сорады әни.
Әйттем: «Бирде Балапай!»

## ЭЗЛӘР

Зәңгәр эз салып, чаңгыда
ап-ак кардан мин барам.
Өстә реактив самолет,
зәңгәр күк йөзен аерып,
ак буразна — эз яра.

Күрше авыл мәктәбенә
мин белем эстәп барам.
Ә самолет, улап, кая,
нинди уй белән бара?

## «ТҮГӘРӘКЧЕ» МИРГАЛИМ

Бер елда ничә түгәрәк
үтте безнең Миргалим!
Белү җиңел аның кая,
ничек итеп йөргәнен.

Әнә
пианино кибеп ята.
Тимераяк тутыккан.
Кыйммәтле фотоаппарат
эшләми, сафтан чыккан.
Шахматы чәчелеп ята,
чын хуҗасы юклыктан...

Миргалим исәпләп тора
тагын әле йөрергә
йөзү түгәрәгенә,
    ату түгәрәгенә,
        бокс түгәрәгенә...

Әйтик аңа: болай йөрү —
вакыт әрәме генә!

## КӘГАЗЬ

Без укый торган китаплар,
без яза торган дәфтәрләр,
без карый торган альбомнар...
башта агач булганнар.
Яфрак ярып, җирдә шаулап,
Җирдә басып торганнар.

Аннан аларны екканнар,
чапканнар һәм кискәннәр...
Машиналардан үткәреп,
юка кәгазь иткәннәр.

Алдымда — чиста, ак кәгазь, —
нинди агачтан икән?
Каеннанмы, нараттанмы,
әллә усактан микән?
Аның урынына яңаны
кемдер утырткан микән?..

...Уйлап тордым да, ясадым
кәгазьгә бер имәнне.
Ясадым мин имәннең
шәбен — менә дигәнен!
Очы күккә тигәнне,
мәңге үсеп торырлыкны.
Кош оя корырлыкны.
Күргән кеше шатлансын.
Кәгазьдә генә булса да,
тагын бер агач артсын!

## ТАШУ ҮТКӘЧ

Ташу — үтте. Эзе — кипте.
Бер иске уймак калган төптә.
Ничә уймак сулар үткән
безнең нәни гөрләвектән!

Ялтыраганчы чистарттым да,
уймакны мин керттем өйгә.
Безнең тыкрык кар сулары
хәзер Каспий диңгезендә...

## АВЫЛДА

Бала әйтә: төтенне әнә
бәйләгәннәрморҗага!

...Тау читендә бәйсез-нисез
кинәнеп тайлар чаба...

## УЕНЧЫКЛАР

Уенчыгы күп Гөлнарның.
Җибәрә тибеп кенә!
Кызыктырмый инде аны
уенчык кибете дә...

Ә Вәлидә бик аз алар!
Ник азлыгын үзе белә...
Чөнки өйдә бер эшләүче —
ялгыз әнисе генә.

Бар нәрсәсе җитеш булгач,
кызык түгел Гөлнарга.
Никтер күрше кызы да
сирәк керә уйнарга...

Вәлинең теләкләр бик зур,
күңеле бай хыялларга!
Үскәч, үзем уенчыклар
ясыйм, ди, балаларга.

Шундый матур итәрмен, ди,
уйнап туймаслык булыр!
Ул кадәр күп ясамам, ди,
кадрен җуймаслык булыр!

## УТЫН ЯРГАНДА

Балта сабын, йә булмаса,
чөй тотып тора иде.
Тукмак суккан әтисенә
кызыгып тора иде.
Сап кына тотып торса да,
нинди җайга «каптырасын»
отып та тора иде.

...Хәзер менә үз кулында
ул эшләрнең бары да:
игеннәр дә, мал-туар да,
утын тумраны да...
Балтасын да үзе чаба,
тукмагын да үзе суга.

Карт әтисе бер кырыйда
улына карап тора.
Ансы да ярап тора.

## ЯЛАНДА

Килеп чыкты бер куян!
Кире чапты шул куян,
безне күргәч, куркудан...

Куян чаба. Алмаз елый.
Көчкә юатып торам.

Куянның үз өркүе.
Алмазның үз куркуы.
«Куян бездән китә, ди,
киткәч, кызык бетә!» — ди.

## АРБА БЕЛӘН ЧАНА

Арбаның да, чананың да торыр җире сарайда.
Ел әйләнә бергә рәттән торалмыйлар алай да.

Җәен чана кырын ята, ә арба һаман юлда.
Кышын исә арба тора чананың урынында.

## ТАМЫРЛАР

Агачлар тамырлылар.
Гөлләр дә тамырлылар.
Ташлар дә тамырлылар!..

Җиргә ныклап төпләнмәсә,
бина да салдырмыйлар!
Нигезгә каккан субайлар —
үзенчә тамыр алар!

## БЕЗНЕҢ НАИЛӘ

Юл читендә күгәрченнәр
җим чүпли «гөлдер-гөлдер».
Кошларны яратуыңны
син эшең белән белдер!

Күгәрченнәр туйдыручы
бәләкәй кыз ул кемме?
Күрше кызы Наилә ич —
яулыгы чиккән гөлле.

Күгәрченнәр канат кагып
куана «гөлдер-гөлдер».
Әйтәләр: мондый әйбәт кыз
шәһәребездә бердер!

## КАЙЧАН КАЙДА ГӨЛЛӘР?

Балконнарда гөлләр.
Түтәлләрдә гөлләр.
Болыннарда гөлләр...
Җылынайды көннәр!
Шифа яңгырларны
алып килә җилләр!

Тәрәзләрдә гөлләр.
Кәгазьләрдә гөлләр.
Күңелләрдә гөлләр...
Суыгайды көннәр!
Шакыраеп каткан
тышта элгән керләр!

## ЧҮЛМӘК

Читәндә — күлмәк.
Казыкта — чүлмәк.
Күлмәк алганда
ватылды чүлмәк!

Жәл инде чүлмәк...
Шәп иде чүлмәк!..
Эшсез эленеп
торган шул күбрәк.

Әнә базда исән
сөт тулы чүлмәк!

## НИЧЕК ЯХШЫ БУЛЫРГА?

Ничек яхшы булырга?
Аны сезгә әйтә алам:
уйла син, күреп тора дип,
һәр адымыңны анам;
йә булмаса, класстагы
матур күзле кыз бала...

Шуннан инде нишлисең?
Билгеле инде нишлисе —
гел яхшы эш эшлисең!

Ә эш эшләгән кеше —
була иң яхшы кеше!

## ИЛЛӘР, ҖИРЛӘР ГИЗҮЧЕГӘ

Йөр, күр, бел син күп җирләрне, күп илләрне.
Сау җаныңа һәрбер тараф якын булсын.
Күзең күргән һәр матурдан, һәр яңадан
күңелеңә хикмәт кунсын, акыл кунсын.

Дөнья зур ул: шәп балкышлар бик күп очрар.
(Егетлегең сыналыр да инде шунда!)
Һич күләгә төшермә син җаныңдагы
Туган илең, Туган җирең яктысына!

Файдалыны — күргән җирләр биргәнчә ал.
Тик үзең дә алган төшкә нур чәчә ал!

## СӘГЫЙТЬ БЕЛӘН СӘГАТЬ

Сәгать әйтә:
«Тек! Тек! — ди. —
Уян, торып
киттек!» — ди.
Сәгыйть әйтә:
«Ник? Ник? — ди. —
Йокы килә
бик! Бик!» — ди.

Сәгать әйтә:
«Тек! Тек! — ди. —
Синең эшең
бик күп!» — ди.
Сәгыйть әйтә:
«Көтәр лә!
Үз вакыты
җитәр лә!..»

Сәгать әйтә:
«Тек! Тек! — ди. —
Сәгыйть, яхшы
ишет! — ди. —
Вакытыңны
әрәм итмә
бөртек! — ди. —
Без — сәгатьләр —
бик күп! — ди. —
Сезнең гомер
бер тик! — ди. —
Йоклап ятма,
киттек! — ди. —

Максатларга
җитик! — ди. —
Илгә хезмәт
итик!» — ди.

...Сәгыйть торды
уянып.
Сәгать сукты
куанып!

## АВЫЛДА

Бакча артына чыккан да Марат,
кузгала алмый тора аптырап!
Арт чабуыннан кем эләктергән? —
Алга сузылсаң — әй әчеттерә!

Әнисенә кычкырган куркудан.
Коткарганнар аны «джунгли»дан.

...Ялгыш кычытканлыкка кергән булган.
Арттан тигәнәк эләктергән булган!

## АЛТЫН БАЛЫК ТҮГЕЛ, ГАДИ БАЛЫК СӨЙЛӘДЕ БИК ГАСАБИЛАНЫП...

«Без яшәгән илләрдә —
елгаларда, күлләрдә —
су асты катларында,
бормалы чатларында,
комлы уемнарында,
таллык куеннарында,
караңгы төпкелләрдә,
мүкләрдә һәм ләмнәрдә
каян килгән нәрсәләр бу:
　　галошлар, итекләр,
　　күгәргән үтүкләр,
　　кәчтерүл-чиләкләр,
　　иләкләр, көрәкләр,
　　буяулар, цементлар,
　　ташландык уенчыклар,
　　кирпечләр-ярчыклар,
　　целлофан капчыклар...

Болар безнең Су иленә
каян килгән?
Нигә килгән?

...Болар барсы өстән килгән —
Кеше дигән көчтән килгән!
Уйлап куям:
　　җир өстендә яшәүчеләр
　　эчкән чишмәләренә дә
　　тирес аудара микән?
　　Ашый торган ашларына
　　мунчала сала микән?
　　йоклый торган түшәкләрен
　　дегетләп ята микән?

Балалары бишегенә
тимер-таш ата микән?
Шулайдыр дим, юкса алар
Табигатьне аңламаслык
тунга әйләнмәс иде!
Җир-Су рәнҗер дәрәҗәдә
вәхшиләнмәсләр иде...»

...Шулай диде дә балыгым
суга чумды.
Мин ярда калдым да
уйга чумдым.

## ЙОМЫШ

Әни йомыш
кушты миңа.
Йомышы — сер:
әйтмим шуңа!

Үтим, дим,
онытканчы!
Аягым — ат,
кулым — камчы!

## КОМАНДИР

Без рядовой!
Без күбәү!
Кирәк, дидек, уйнаганда
бер командир билгеләү.

Әйтүен әйттек, ә сайлавы —
уен эш түгел бер дә!
Китте сүз көрәштерүләр!
Китте эш «Мин!» дә «Мин!»гә...
Бәхәскә киткәч, командир
булалмады беркем дә!

Ахыр чиктә әвәләдек
зур итеп бер кар сынын.
Шуңа килеп «честь» бирәбез,
үрә басып каршына!

Генерал иттек без аны.
Фанер погоннар куйдык.
Ян-яннан кызыл йөгерттек,
күмердән төймә уйдык.

Күзәтеп тора «генерал»
көнен-төнен урынында.
Һәрбер малай, «марш» атлап,
аңа карап борыла.
Ни әйтсәң дә, командир бит,
кар булса да — генерал!
Тик уңайсыз бер ягы бар:
әмерләр бирә алмый...
Батырырак малайларга
орден-медаль элә алмый...

...Язлар җиткәч, китәчәк, ди,
кышта гына яраган!
Бәлки, командир табылыр
үзебезнең арадан!

## РӘШӘТКӘЛӘР БУЯДЫМ!

Яңгыр килеп юып карады.
Кошлар килеп кунып карады.
Җилләр килеп өреп карады.
Кояш үзе төшеп карады!

Эшем матур булган микән? —
Син дә кереп кара әле!

## ҖИЛНЕҢ СУРӘТЕ НИНДИ?

– Җилнең мөгезләре бармы?

– Бардыр. Бардыр...
Юкса тамырлары белән
агачлар аумас иде...

– Тырнаклары?

– Бардыр. Бардыр...
Юкса түбә калайларын
куптара алмас иде!

– Томшыгы да бардыр әле!

– Бардыр. Бардыр...
Юкса камышлар эченә
кереп тулалмас иде.

– Канатлары?

– Бардыр. Бардыр...
Юкса күктә болытларны
җилпеп куалмас иде!

– ...Ә рәсемгә төшерә калсаң,
кыяфәте нинди соң?
Кошмы? Берәр җанвармы?
Әллә берәр җенме соң?

– Белмим. Белмим.
Үзе әнә форточкадан
миңа карап ыслап тора,
нидер әйтеп выжлап тора...
Тик телен төшеналмыйм!

Шуңа күрә әйткәннәрен
кәгазьгә төшералмыйм...

## ПАРОХОДЛАР ЯЛ ИТӘ

Пароходлар, теплоходлар
сыенышканнар ярга.
Тын култыкта тыныч кына
бергәләп кыш чыгарга.

Дулкыннар да ярдан ярга
бәргәләнеп арганнар.
Суык куып йөрмик, диеп,
боз юрган ябынганнар.

Кар сарган
пароходларның
алтынсу исемнәрен.
Белмим
кышын матросларның
нинди хис кичергәнен...

Фарватер өсләре калган
җәяүле бураннарга.
Ак штурвалга кунган да
кагынып тора карга.

## БОЛЫНДА. ЧИШМӘ БУЕНДА

Тугайлык. Таллык. Гөл-үлән.
Ямьле әйләнә-тирә.
Шунда мәш килә балалар,
эш табып үзенә күрә.

Әнәс әнә энесенә
сыбызгы ясап биргән.
Марат, ат кылларын кушып,
дүртләтеп камчы үргән.
Әлфия ал чәчәкләрдән
башына такыя кигән.
Рөстәм курай ясарлык
камыш тапкан бер дигән...
Ә Илһам атлы бер малай
җирдә чалкан яткан да,
тып-тын гына карап ята
болытларның акканын.

Янда чишмә. Күктә Кояш!
Күбәләк очып йөри.
Күбәләк әлеге малайның
янына килеп сорый:
«Уйчан малай! Нигә алай
бер читтә утырасың?
Иптәшләрең гөр килгәндә
бер шөгыльсез торасың?

Әллә, тәти малай булып,
кулыңнан эш килмиме?
Әллә булган сәләтеңне
бер мин генә белмимме?»

Малай җавап урынына
бер җыр сузып җибәрә.
Моңлы көйдән, бермәл туктап
калды, ахры, җилләр дә...

Торып басты да ул, җырлап,
килде чишмә янына,
фонтан булып су бөркелде
чишмәнең улагыннан.
Салават-күпер ясалды
тамчылар балкышында.
Күпер өсләп җыр яңгырый
чишмәнең алкышына!
Ватан турындагы җырдан
дөнья яңарды кебек!
Яңгырый җыр! Балкый төсләр!
Бер генә минут элек
берсе дә юк иде. Менә бит
нәрсә эшләде егет!

Әй, күбәләк! Бу дөньяда
сәләтсез кеше бармы?
Күрергә кирәк талантны,
ачарга кирәк аны!

...Болында, чишмә буенда
уйный-көлә балалар.
Җирнең Кояшка бүләге —
аңлы чәчәкләр алар!

## ХӘБИР АБЫЙ

### I. Ул

Егор түгел, егерь ул!
Урманнарда йөри ул,
яланнарда йөри ул,
болыннарда йөри ул...
Тиккә генә йөрми ул —
хикмәт белән йөри ул!

Яңа чишмәләр таба ул.
Гөлләргә сүз куша ул.
Сынганны бәйләп куя ул,
көчсезгә булыша ул.

Белә бар җәнлекләрне ул.
Белә бөтен кошны ул.
Ул аларга зыян салмый,
үзе алар дусты ул!

Егор түгел, егерь ул!
Һәммә җирдә өлгер ул!
Безнең якта һәркем белгән
«Егерь Хәбир» бердер ул!

### II. Күпне күргән кеше ул

Егет чакта, Армиядә ул
пограничник булган.
Әле дә аның фуражкасы
хәрбиләрнеке сыман.

Чик буенда төрле хәлләр
кичкән аның башыннан.
Күргән ул чын ерткычны да,
ике аяклысын да...

Солдаттан кайткач, районда
милиционер булган.
Ил ямен бозучыларны
ипкә китереп торган.

Олыгайгач, бу хезмәтне
тапшырган яшь кешегә.
Табигать сакчысы булып
күчкән егерь эшенә.

«Искечә әйтсәк, мин хәзер —
урман-суга кизү! — ди. —
Җир-суны яшь буыннарга
исән-сау җиткезү!» — ди.

## III. Төрле хәлләр булып тора...

Төрле хәлләр булып тора
тыныч-имин чакта да!
Тынычлыкны тынлыкта да
кирәк була сакларга...

Яман уйлы кешеләр дә
очрап куя кай ара.
Әзер алар, нәфес сузып,
Табигатьне таларга.

Кемдер, «урман сыеры» дип,
качып поши атмакчы,
кемдер төлкенең шәп тунын
яка итеп такмакчы...

Кемдер сакланырга тиеш
агачларны екмакчы,
кемдер тыюлы урыннан
күпләп балык тотмакчы...

Саный китсәң, байтак алар
әзергә кул сузучы.
Исемнәре — браконьер —
Җир-су ямен бозучы.

Кайберсенә аңлатасың,
кайберсен — оялтасың...
Туры килсә, узынганын
җавапка да тартасың —
мылтыгы бик еш шартласа,
йә озайса балтасы...

...Сөйли Хәбир абый, сөйли.
Сөйләр сүзләре күп шул!
Мөлдерәп карый Табигать,
аның күзләре күп шул...

### IV. Урманда ничә куян?

Икәү йөргәндә ул миннән
беркөнне сорап куя:
«Уйлаганың бармы, шушы
урманда ничә куян?»

Аптыраушта калдым бераз:
нинди сан дип әйтергә?
Тотлыгып калуны сизеп,
аркамнан кагып көлә!

— Белмәсәң, әйтеп бирәм! — ди. —
Булыр кырыклап данә!
Ялгышсам ялгышырмын, — ди, —
бергә яки икегә.

Әйтсәм әйтим, тагын монда
ике бүре, дүрт поши,
бер пар кабан, ике төлке,
бер данә бурсык кышлый.

Каян беләмме? Җәнлекләр
үзләре әйтеп бирә.
Кар өстендә ярылып яткан
эзләре әйтеп бирә!

Кар өстендәге китапны
укый алганнар сирәк!
Укыр аны күзе үткен,
күңеле чиста, зирәк!

Урманда ничә куян да,
күлләрдә ничә үрдәк?
Җирнең хуҗасы икәнсең,
барсын да белү кирәк!

Тормыш-яшәү көрәшендә
булмый исәпсез генә!
Бу дөньяга битарафтыр
туң җанлы гамьсез генә...

## V. Кызыл китап

Яшел китап... Бәрхет китап...
Чыкты Кызыл китап та!
Югала торган хайваннар
анда барсы хисапта.

Җәнлеге дә, киеге дә,
үләне, бөҗәге дә...
«Саклап калыйк!» дип куелган
игътибар үзәгенә.

Китаплар күп. Бусы — кызыл.
Кызыл төс юкка, димә!
Кызыл төс сискәндерә дә,
кызыл төс: «Тукта!» — ди дә!

Димәк, яшәр Җиребездә
хәлләр бар шомланырлык.
Табигатьтән ни алдык та,
аңарда ни калдырдык?

Бар соңгы кат очкан кошлар...
Соңгы чәчәкле гөлләр...
Килер буынга калырмы
алар рәсемдә генә?

Димәк, иртәгә бер аваз,
бер төс-ямь җитмәячәк...
Беркөн үзенең хөкемен
әйтер бит ул Киләчәк!

«SOS» мәгънәле китап ул,
башы да, азагы да.
Табигать — аның авторы,
кешеләр язган гына...

### VI. Күчтәнәчләр илтә ул

Кышкы иртәдә атын җигеп,
бара, дисез, кайларга?
«Күчтәнәчләр илтәм, — ди ул, —
урмандагы малларга!

Бураннар күмгәч җир өстен,
читен шул мескеннәргә.
Ач килеш син ятып кара
карда — суык төннәрдә...

Ярдәм итмәсәң, ачлыктан
үлеп калулары бар.
Йә кеше торган җирләргә
зыян салулары бар.

Һәрбер җан иясенә дә
аңлашыла игелек.
Без — кешеләр — иң аңлы зат,
кулны бирик иң элек!

Кошларга җим сибәсеңме
йә оя корасыңмы —
андый чакта син үзеңне
олы итеп тоясыңдыр».

...Чанасында печәне дә,
тозы да, көрпәсе дә...
Хәбир абый юлда була
кышның күп иртәсендә.

### VII. Кунаклар

Хәбир абыйларга килеп,
күрсәгез ишегалдын —
әйтерсез сез: түгелме бу
зоопарк филиалы?

Бүре кадәр бүре уйный
эт балалары белән.
Поши-бозау күшәп тора
сыер маллары белән.

Йорт казлары арасында
аккош ята сыенып.
Су тулы зур тагарактан
чыккан, ахры, коенып...

Шушы бер ишегалдына
каян җыелган алар?
Төрлесе төрле бәлагә
юлыккан булган алар...

Кайсы аның эләгә язган
браконьер кулына.
Кайсы адашып ук калган
оча торган юлыннан...

Ярый ла Хәбир абыйга
очраганнар ул җаннар!
Язмыш тапшырган аларны
шәфкатьле бер хуҗага.

Әйтә Хәбир абый көлеп:
«Алар — минем кунаклар!
Китәрләр, ди, юлларына,
җитүгә җылы чаклар!

Һәр җанварның үз сукмагы.
Һәрбер кошның үз күле.
Үз ирекләрендә яшәп,
күрерләр, ди, үз көнен».

...Хәзергә әле Хәбир абый
аларга азык сала.
Бүре баласының күзе
куанып уттай яна!

## VIII. Бер учта...

— Оланнар, кулымда нәрсә?
— Имән чикләвеге ич!
— Дөрес, әмма бу чикләвек
әкәмәт хикмәтле ич!

Күрер күзгә учта ята
чикләвек орлык кына —
ә уйлансаң, мин кулымда
бер урман тотып торам!

Бу орлыкны җиргә төртсәң,
бер имән үсеп җитәр.
Шул имәннән тирә-юньгә
мең орлык күчеп китәр!

Вакыт үткәч, алардан да
яңалары яралыр.
Шулай итеп, имән заты
байтак җиргә таралыр.

Шулай, дуслар, мин учымда
бер урман тотып торам!
Бер генә урман микән дип,
әле куркып та торам...

...Ә бу учта нәрсә дисез?
— Бер шырпы бөртеге ич!
— Әйе, шырпы. Ә үзендә
нинди яшерен дәһшәт көч!

Кызышса нәни шырпылар
бер яманның кулында —
урманнарны төтен итәр,
көлләр түшәп юлында!

Бер чикләвек тә бер шырпы...
Кайсын учка аласың!
Учка алу әле бер хәл —
ничек файдаланасың!

...Йә Җирдә бакча ясыйсың,
йә үкереп янасың!..

## IX. Кичке сөйләшүләр

Җыелып аның янына
җәйнең тын кичләрендә,
тезелешеп утырабыз
бүрәнә өсләрендә.

Сөйләп җибәрә безгә ул
баштан кичкән хәлләрен,
сөйли күбрәк, яуда түгел,
урманда күргәннәрен.

Сөйли киек-җәнлекләрнең
яшәеш рәвешләрен,
гөлләр дөньясындагы
төрле үзгәрешләрне.

Табигатьтә без белмәгән
тылсымнар шаккатырлык!
Хикмәтле сораулар бирә,
безне уйга батырып.

«Ник үлән үзе яшел дә,
ә чәчәге ал-гөлле?
Ник күбәләк аз гомерле?
Кырмыска ничә билле?

Кар бөртегенең сурәте
нидән шулай бизәкле?
Сандугач ник бездән качып
сайрый, өзеп үзәкне?..»

Уйлансаң, уйланырлык шул...
Табигать — могҗизалы!
Бөтен ямен кирәк кадәр
белмибез генә аның...

Хәбир абый өстәп куя:
«Табигатьне белмичә,
ни игелек кылмак кирәк,
шушы Туган җир өчен?

Җирне белми — аңлап булмый.
Аңласаң — якын була!
Шул чакта «Туган җирем!» дип
әйтерлек хакың була!»

Сөйли сәгатьләр буе ул.
Кызык булгач, тыңлыйбыз.
Беркөн без дә аның кебек
белербез дип уйлыйбыз.

«Сәгать ничә?.. Ә, соң икән!
Кереп ятасы булыр.
Иртүк торып урманнарны
карап кайтасы булыр.

Сезгә дә вакыт кайтырга,
оланнар, бала җаннар!»
...Таралабыз. Офыкларда
уйнаклый аҗаганнар.

## ЙОКЫ ӘКИЯТЕ

*(Рөстәм Кутуй буенча)*

Йокы кунсын күзеңә,
Әкият сөйлим үзеңә!

Булган, ди, Мияубикә.
Торган, ди, Мияубикә.
Беркөн ул чыгып киткән,
тырысын иңгә киеп,
гөмбә җыярга диеп.

Киткән туры сукмаклап,
киткән кыек сукмаклап,
каты басып лап та лап,
кош-кортны куркыткалап.
Хәл җыйгач, тырысындагы
сумсаларны капкалап,
тагын киткән лап та лап!

Әй киткән Мияубикә.
Әй барган Мияубикә.
Берзаман, юньләп караса —
сукмагы кая илткән?

Күзләр әлҗе-мөлҗе килә:
алда торган ни икән?
Тәрәзәсез, ишексез,
морҗасыз һәм торбасыз
искитмәле өй икән!

Мияубикә ары килә.
Мияубикә бире килә.
Өйгә керәсе килә,
эчен күрәсе килә!

Ә соң ничек керәсең —
табып булмый keләсен:
шакыр идең, ишеге юк,
чиртергә тәрәзәсе...

Йөри-йөри көн үткән,
кояш баткан, төн җиткән.
Мыекларны сындырырлык
җил искән әллә ниткән...

Мондый кара төннәрдә
башка Мияубикәләр,
Мырауҗаннар, песиләр
мич башыннан төшмиләр.
Мендәрләрдә яталар,
кәтүкләр уйнаталар...

Ә безнең Мияубикә
күшеккән, арган-талган,
тырысы бушап калган,
карыны ачкан яман...
Ә үзе өй тирәли
йөргән дә йөргән һаман:
«Тәрәзәсез, торбасыз,
ишексез һәм морҗасыз
бу соң нинди өй икән?
Эчләрендә ни икән?»
Йокла инде, кечкенәм!
Бәләкәчем, төшкенәм!
Әнә ай да башын салган
болытларның өстенә.
Чыпчыклар ояларында
елмаешып төш күрә.

Йокла инде, кечкенәм!
Бәләкәчем, төшкенәм!
Ә син күзең ачкансың,
иренемә баккансың.

Сорыйсың: Мияубикә
нишләгән, дип, шуннан соң?
Өйдә нәрсә булган соң?

Берни дә булмаган ла!
Сукмакта очраган ла
Мияубикәгә бары
кырмыскалар өй-тавы!

Хәзер йокла, кечкенәм!
Бәләкәчем, тәшкенәм!

## ӘЛЛИ-БӘЛЛИ

Әллә-бәлли бәү итә,
улым йокыга китә.
Аңа әле ябынырга
бер кулъяулык та җитә.

Имезлек авызында,
бар көче авазында.
Теләсә берәр нәрсә,
бер кычкырып җибәрсә, —
тәрәзәләр зың итә!
Әнисе килеп җитә,
    әтисе килеп җитә,
        әбисе килеп җитә!

Кечкенә лә димәгез,
куәте юк димәгез!
Әле хәзер ябынырга
кулъяулыгы җитсә дә... —
ул сәгатьләп үсә лә!

Күзләрен йомсын әле,
бераз көч җыйсын әле,
аннан уяныр әле,
бер аваз салыр әле!

Менә шунда күрерсез,
менә шунда белерсез,
ни гайрәтле икәнен —
әнисен йөгерткәнен,
    әтисен йөгерткәнен,
        әбисен йөгерткәнен,
            дөньяны селкеткәнен!

Тс-с! Улым йоклап китте!..

## ДҮРТ СҮЗЕ БАР УЛЫМНЫҢ

Улымның бар дүрт сүзе:
«әннә»се,
«әттә»се,
«тәттә»се,
«мәммә»се, —
менә шул һәммәсе!

Аның сүзе тансыкмы,
тыңлаучы бармы, юкмы, —
иртәдән кичкә кадәр
сөйләнәме, сөйләнә,
ничек теле әйләнә!
«Әннә-нә!»
«Мәммә-мә!..»
Үткәндә дә бәйләнә,
сүткәндә дә бәйләнә:
«әттә-тә»!
«Тәттә-тә»!

Яраткач «тел бистәсен»,
соң әтисе нишләсен!
Иценнән сыйпап үтә,
маңгаеннан пәп итә,
ә ул сөйли дә сөйли,
һаман көйли дә көйли!

«Әннә-нә»,
«мәммә-мә»!
«Әттә-тә»,
«тәттә-тә»!

Йөргәндә урам-чатта,
дөнья бик иркен чакта,
ялгышкалап та куя:
автобус «әннә» була,
агачлар «мәммә» була,
песиләр «әттә» була,
әбиләр «тәттә» була...

Ә өйдә ул ялгышмый!
(Урам чуар булгач та!
Чүт кенә буталгач та!..)
Үз бүлмәсенә кайткач,
ник ялгышып утырсын,
ник оятлы булып торсын!
Бер ягында әннәсе,
бер ягында әттәсе,
бер кулында тәттәсе,
бер кулында мәммәсе...

Улымның бар дүрт сүзе:
«әннә»се,
«әттә»се,
«тәттә»се,
«мәммә»се, —
менә шул һәммәсе!

Бүтән сүз нигә кирәк?
Дөньясы түгәрәк!
Үскәч, сүзе артыр әле,
тормышны татыр әле!

## АВЫЛ ЮБИЛЕЕ

Безнең авыл төзелгәнгә
өч йөз ел тулган икән!
Түгәрәк санлы еллар ул —
юбилей була икән.

Зурдан үтте бу юбилей.
Җыелышлар җыйдылар.
Урамнарга «ЮБИЛЕЙ!» дип,
плакатлар куйдылар.

Мәктәпнең бер бүлмәсендә
музей оештырылды.
Каһарман авылдашларның
рәсемнәре куелды.

Районнан килгән оркестр
дәртле көйләр уйнады.
Артистлар концерт биргәндә,
халык залга сыймады.

Алдынгы игенчеләргә
тапшырылды бүләкләр.
Матур киләчәк турында
әйтелде күп теләкләр.

Җыеннан соң да булды әле
бу бәйрәмнең дәвамы.
Җыр-биюдән яңгырап торды
сабан туе аланы.

...Без дә бабай белән икәү
тыңладык, күрдек барын...
Соңрак барып буяп чыктык
зиярат коймаларын.

## АЭРОБУСТА УЙЛАНУ

Самолетларның төрләрен
без хәзер аерабыз!
Кайсысы «кукурузник» та,
кайсысы аэробус...

Бүген беренче кат күрдем
аэробус дигәнен.
Сез белмисез, эченә кергәч,
башым күккә тигәнен!

Шаккаттым бу самолетка —
ул ике катлы икән!
Һәрбер салоны-бүлеме
бер клуб чаклы икән!

Утыртсаң, безнең авылның
халкы сыеп бетәрлек.
Бала арбаларына да
монда урын җитәрлек...

Хәер, бөтен авыл халкы
дәррәү кузгала алмас,
аэробус очып киткәч,
авылда бер ямь калмас...

Кемгәдер туган нигездә
утырып калу кирәк.
Кемгәдер ипи пешерергә,
сыер саварга кирәк...

Шулай да авылдашларны
бер утыртасы иде!
Чиратлап алып булса да,
ерак юл тотасы иде!

Йөземле җылы якларга,
без күрмәгән илләргә,
аэробус илтеп куя
ял итәрлек җирләргә.

Андый хөрмәткә лаек бит
безнең әти-әниләр дә,
безнең бабай-әбиләр дә,
сәяхәттән зыян булмас,
хәтта дим, бәбиләргә!

...Автобус йөртүче булу —
күңелдә хыял иде,
хәзер инде бүтәнчәрәк
уйлап та куям инде.

Аэробус очучысы
булсаң да яхшы икән!
Очучы формасы киеп,
авылга кайтсаң икән!

Мин белер идем иң башта
кемнәрне утыртырга!
Аэродром ясар идем
якындагы бер кырга.

Хәер,
очучыга укысаң да,
шофер булып була әле!
Чын ир-егетләрнең була
җитмеш төрле һөнәре!

Дус-ишләрне автобуска
төяп алып китәсең,
ә аннан соң трап буйлап
аэробуска үтәсең!

Булгач булырга кирәктер
экипаж командиры.
Командирга күбрәк күренә
Туган илкәйнең җире.

...Мин әлегә бу салонда
гади пассажир гына.
Гади пассажир булсаң да,
хыялланырга була!

Тырышсаң, дим, бу заманда
хыял әйләнә чынга.
Кирәк тик бик күп белергә,
үсәргә ашыгырга!
Күктәге хыялны Җирдә
тормышка ашырырга!

## ТАБАГАЧ

Бу табагач бик борынгы.
Мөгез кебек шомарган...
Заманында әбиемнең
кулларында уйнаган!

Мичтән күпме чыгарган ул
тәмле таба ашларын!
Ул ашларны җыйганнарның
күбесе җирдә башлары...

...Ул хәзер дә мич янында
сөялеп һаман тора.
Газ плитәсендә пешкән
ашларга карап тора.

Пешә газда төрле ашлар —
токмач та, пилмәннәр дә...
Шулай да табагач кирәк
кунаклар килгән мәлдә!

Кем мичтән чыгара алсын
өчпочмакны, бәлешне?
Фәкать табагач булдыра
андый зур мөһим эшне!

Кунаклар сыйланган чакта,
мактап хуҗабикәне,
табагач та белә булыр
үзенең кем икәнен!

Тикмәгә шомармаган ул —
күп утка кергән агач!
Тимер тешле табагач ул,
күп еллар күргән агач!

Буыннар килә дә китә...
Ялкынлап яна заман...
Ә табагач, элеккечә,
үз урынында һаман.

## БИЕКТӘН

Кайтып киләм урам буйлап,
караш ташлап түбәнгә.

Кулым сузсам — кул астында —
капка, койма, түбәләр...
Бакчалар, абзар куралар,
баскыч, ишегаллары...
Үрелеп карамасам да,
учымдагы күк бары!

Өстән торып күрәм очкан
кошларның канатларын.
Кызык икән биеклектән
дөньяны карап бару!
Этләр аста посып кала,
койрыкларын салып.
Малайларны сәламлисең
иякне генә кагып!

Күперләр кала түбәндә.
Инеш тә тарайган күк...
Үзем исә барган саен
һаман да зурайган күк!

Кайтып киләм урам буйлап...
Әйтерсең, мин — Гулливер!
Кемдер, бәлки, әле мине
мактана дип уйлыйдыр?

Яшермим: баһадир булу
теләге бар күңелдә!
Быел укырга керәсе
бер малай мин бүгенгә.

...Кайтып киләм урам буйлап
биек печән йөгендә.

## ТАУ

Газиз белән тотынышып
икәү тауга менәбез.
Менгән саен Туган якның
киңлекләрен күрәбез.

Адым саен без үсәбез,
ә тау — тәбәнәгәя...
Менә-менә башларыбыз
болытка тимәгәе!

Безнең күләгәләр төшә
кошларның канатына.
Утырганбыздыр шикелле
хыялның ак атына!

Уенчык күк өстән —
йортлар,
күлләр,
поезд юллары...
Ә без гүя әкияттәге
Алып батыр уллары!

...Газиз белән тотынышып
икәү таудан төшәбез.
Аяк асларына карап
таштан ташка күчәбез.

Арттан тау зураеп кала.
Кошлар очалар өстән.
Күләгәбез, кечерәеп,
аяк астына күчкән.

Тылсымлы кебек күренми
сукмак та, тирә-юнь дә.
Газиз арып кунаклады
әтисенең иңендә.

Ә шулай да күңелләр шат.
Өйдә — әни, алда — юл.
Тауларга менгән кешеләр
Кечерәя алмый ул!

# *Поэмалар*



## ГАДИЛӘРГӘ ГИМН

### 1

Тудыручылар!
Туендыручылар!
Киендерүчеләр!
Гыйлем иңдерүчеләр!
Төзүчеләр-коручылар!
Ил сагында торучылар!
Арагызда бөекләр бармы?
— Без беренче ишетәбез?!
Уйланган юк бу турыда.
Без табабыз, без багабыз, үстерәбез!
Без сөрәбез, без урабыз, пешерәбез!
Без төзибез!
Үзебездән яхшы булыр
алмаш буын әзерлибез,
без саклыйбыз иминлекне...
Без бөекме?
Без беренче кат ишетәбез!..
— Алайса,
бу — Сезгә, гадиләр!
Таңнан уянучылар,
гаризалар язучылар,
җәяүләп йөрүчеләр,
махра төрүчеләр,
бу — Сезгә!
Гомумләүкәләргә менеп,
пешеп чабынучылар!
Зарчылар һәм даучылар,
чиратта торучылар,
Бу — Сезгә!
Риясызлар, җор җаннар,
җырчы-шагыйрь туганнар,
көй-моң чыгаручылар,
җанны сугаручылар,
бу — Сезгә!

Җиңүчеләр, җиңелүчеләр,
ризык кадерен белүчеләр,
көне-төне чабучылар,
дөнья малы табучылар,
бу — Сезгә!
Хаклыкны хаклаучылар,
көчсезне яклаучылар,
Табигать таҗы — Кешенең
чын затын саклаучылар,
олы җанлы, киң күңелле,
тугры сүзле, садә җаннар,
бу — Сезгә!

**2**

Җир куеныннан мәрмәр чыгаручылар,
аны кояш итеп шомартучылар,
намус кебек ак кәгазь әзерләүчеләр,
күз бәбәкләренә үлчәп, хәреф коючылар,
юлда интегүчеләргә игелек кылучылар,
коргаксыган барханнарда канал-арык еручылар,
сырхауларның баш очында ак халаттан торучылар,
девоннарның төбенә төшеп, маен кысып сыгучылар,
себереп, юып, дөнья чүбен җыючылар,
иртә таңнан төнгә кадәр җәйләүләрдә йөрүчеләр,
кәрәз кебек катлы-катлы йорт-пулатлар төзүчеләр,
таулар аша, илләр аша нечкә чыбык сузучылар,
чәчү, урак өсләрендә басуларда кунучылар... —
Сезне
пьедесталдан гына эзләүчеләр ялгышалар.
Пьедесталга гына сыямы соң кешелеклелек!
Постаментка гына сыямы соң фидакярлек!
Мәйданнарга гына сыямы соң гавам-ташкын!

Чү!
Зәңгәр күктә нинди моң-чың?
Бу — тургай ич!
Һәйкәлләрнең өсләрендә сайрый ласа!

Сезнең һәйкәл —
тук башаклы иген-кырлар!
Сезнең һәйкәл —
җир челтәре — рельс юллар!
Сезнең һәйкәл — сулардагы крейсер-кораблар,
пиклардагы әләм-маяклар!
Сезнең һәйкәл —
корыч кошлар — самолетлар,
йөзек кашыдай елтыр утлар —
шәһәр-йортлар!
Җиһан үзе тулысы белән
Сезнең һәйкәл!

Горуррак, гади кешеләр!
Килешә Сезгә —
эшегез йөкли —
күкрәк киереп,
Җир шарында
нык торырга!
Мөмкинме соң мескенләнү,
бәяң белмәү бу гасырда!
Кул йолдызга җиткән чорда!
Горуррак!

**3**

Ике кулы тез башында. Башын игән.
Эш юк. Бу кем?
Корбаннарның катафалк артларыннан
тәүбә әйтеп баручылар. Алар кемнәр?
Бер кулында винтовкасы,
бер кулында яшь баласы.
Тревога!
Күкрәгеннән сөт тамчысы тамып бара. Бу кем?
Гомерендә бер хәреф-сүз укымаган.
Алар кемнәр?
Аркасында чаж-чож камчы.
Каратутлы гәүдәсендә тамчы хәл юк.

Иренендә — кан. Бу кем?
Авыз тутырып туйганчы бер ашамаган.
Алар кемнәр?
Бер саташкан әйтү белән
теләсә кайсы чиккә-илгә
саранчадай керергә әзер
әрсез өер.
Алар кемнәр?
Тагын күпме әллә кемнәр — алар кемнәр?
Кемнәр алар?!
Бәгърегезнең бер кисәге
түгелме алар,
Галиҗәнап гади җаннар?
Бар дөнья юксылларын
берләшергә чакырулары
асыл-асыл акылларның —
барыбызның
аңындамы?
Җанындамы?
Гуманлы рух
барыбызның
канындамы?

...Вакланмасын көрәш бөеклеге!
Тапланмасын данлы үткән юл!
Онытылмасын корбаннар!
Рәнҗемәсен коммунарларның
ал каннары!
Кыйшаймасын кадаган әләмнәр!
Хәтердә еракка ук
чигенмәсен Бастилия, Кышкы Сарайлар!..
Сез корыч коючымы, күмәч пешерүчеме,
фәллахмы сез, әллә докермы,
Кояшны баш очында күрәсезме яки яннанмы,
«әни» сүзен әйткәндә иреннәрегез
бер-беренә орынамы, юкмы,
тәннәрегез көнне хәтерләтәме, төннеме, —
барыбер Туганнар сез.

Җәрәхәт бар икән,
чир-афәт бар икән —
меңләгән чакрымнар аша да
барыбер әрнетер сезне дә!
Кузгалган, уянган дөнья бу!
Ычкынган тезгене...

### 4

Буратино һәм Аллаларга табынучылар!
Бер уч туфракка һәм икмәк валчыгына,
йөздәге елмаю сызыкларына,
сабый иреннәрендәге сөт яктылыгына,
нарцис чәчәкләренә һәм могҗизаларга,
кәмитләргә табынучылар!
Язмышларга, ырымнарга ышанучылар!
Иртәгесе көнгә һәм Кояшка,
бар сүзләргә, бар ымнарга,
бар төсләргә, авазларга
риясыз ышанучылар!
Сез балталар уйлап таптыгыз, —
башларыгыз бүкәннәрдән тәгәрәде;
үзегез ишкән бауларда ук
маятниктай чайкалдыгыз;
үзегез койган ядрәләрне
тәннәрегездән чүпләдегез;
үзегез җыйган танклар
кулларыгызны сытып узды;
үзегез очырткан корыч кошлар
өстегезгә бомба койды...
Кешелек әле сабый чакта ук
юри генә сез
(кызык бит!)
җәүһәрләр чыгарып сиптегез —
ә аңа
козгын кебек ябырылучылар табылды.

Юри генә акчалар койдыгыз
(сезгә нәрсә акча кою!) —
чыңын көлү белән тиңләүчеләр табылды.
Юри генә тәхетләр ясадыгыз
(сәнгать өченме?) —
берсен-берсе ашый-ашый, үрмәкүчтәй
үрмәләүче күпме җыелды!
Алар табындылар.
Ә сез исә кыланышларыннан
сабыйлар күк көлдегез генә!
Яңа чапкан печән өстенә ятып көлдегез, —
көлү чалгы йөзендә чагылды!
Домна миче каршында көйрәткәндә көлдегез, —
көлү тир тамчыларында чагылды!
Айлы төндә зәңгәр чуен юллар буйлап
чыңлап барды сезнең көлү!..
Ах, бу көлү!
Каһкаһәдән
чатнап алмазлар ярыла,
уала гәүһәрләр!
Ныграк көлегез!
Ныграк!!
Байлыклары тынычлыгын алган
кәрлә җаннар, каушый-каушый,
ашык-пошык план кордылар.
Бриллиантларын санап тордылар.
Тәхетләрне дер селкетте юхалыклар.
Ә акчалар сибелделәр, канга сусап,
Җир-ананың итәгендә...

**5**

Күпме алар! Күпме алар!
Фаҗигаләр! Фаҗигаләр!
Тарих үзе буйдан-буйга
торамыни фаҗигадән!

Кем соң әйтә ала алдан
килмәс диеп ул яңадан?
Дөнья йөзе мәңгелеккә
азат диеп фаҗигадән?..
Фаҗигаләр театрын
туймас күзләр ачкан чакта,
үзләре күк куркып, калтырап,
чаршау артына качкан чакта,
буын-ырулары белән
кырлар тулып кырылучы —
алар бит сез — гади җаннар!
Оялары туздырылган кошлар кебек
ялгыз, ятим, тол калганнар —
алар бит сез!
Өмет-курку арасында,
җигелеп тормыш арбасына,
кырмыскадай арлы-бирле
йөрүчеләр —
алар бит сез!
Җир өсте чак күтәрерлек
байлыклар тудырып та,
артык булып йөрүчеләр
ачлыкта һәм хурлыкта —
алар бит сез!
Алар бит сез,
гали җаннар!
Фаҗигаләр! Фаҗигаләр! —
җиңел, эзсез үтмәсеннәр!
Театрлар уйналалар
башларыгыз лепкәсендә.
Менә кайчан кирәк хәтер!
Хәтер!
Хәтер!!
Хәтер!!!
«Юк бит хәтәр!

Тынлык бозып кычкырма!» — дип,
бәлки, миңа кемдер әйтер?
Эш узгачтын,
хәтәрләнгәч —
үкчәләр дә хәтерләнә!
Хәтер кирәк үткәннәрне күрер өчен,
бүгенгене белер өчен!
Хәтер кирәк
чын-ялганны аерыр өчен;
үткәннәргә ныклап басып,
бүгенгене
хыялдагы киләчәккә
туры алып барыр өчен!
Хәтер кирәк гадиләрнең бөеклеген аңлар өчен,
хезмәтлене бар тавыштан данлар өчен!
Хәтер кирәк һава кебек,
хыял кебек...
Ваемсызлык сарган башка
Хәтер — бәлки, күбәләктер?
Тимер бизон булганда да
аңа
туры килә бик таманга
бу заманда!
Саплам җептәй кыска түгел,
Хәтер озын булсын!
Тарих буйлап ерак китсен, чыбыклар күк,
һәм тоташсын дөреслекнең чатларына!
Яхшысы торсын Хәтернең
алдук — йөрәгең янындук,
яманын да оныттырга
барыбер хакың юк!

Хәтер — газраил ул
фаҗигаләр, афәтләргә!

Кемнең исәп
Хәтерләрне чуалтырга
һәм очларын югалтырга?
Ул —
яшәвеңә каршы синең
сөенүеңә,
сөюеңә...

Гади кешеләр
күңелегез күкләрендә
Хыял белән Хәтер
бергә очсын!

**6**

Бу гасыр — ышаныч гасыры.
Куркулар, өркүләр искерде!
Дөньяга аң керде!
Төс керде!
Ис керде!
Замана — аңлашу заманы;
даулашу заманы
яңаны!
Бу чор — җыр чоры!
Сезнең җыр, Гадиләр,
җырларның иң хөре,
җырларның иң чыны!
Җырчылар — уртага!
Безнең чор — җыр чоры!
Җырмы соң санлаша
чик белән, бик белән!
Касталар, расалар ни аңа!
Мәхәббәт
һәм ирек җырлары
бар телдә аңлана!

Сезнең җыр, Гадиләр,
көрәш күк ирекле!
Ул һәрчак югары
корт-фиргавен яткан,
таш-яшьтән укмашкан
пирамидалардан!
Ул җырга үлмәс дан!
Соң ул җыр түгелме,
тургайдай меналган,
богаулар астыннан!
Итекләр астыннан!
Ул җырга үлмәс дан!
Ул җырдан түгелме
тәхетләр, сарайлар
бизгәктә калтыраган!
Ул гади һәм гали
җырларга дан!
Дан!
Дан!
...Тик шулай да
Җиргә җыр җитешми әле.
Тормыш әле җырга тиенмәгән.
Яулардан кайтмаган туганнар өчен,
полигоннарда үсәр бодай башаклары өчен,
үле туган балалар өчен җырлыйсы бар...
Бер җырланыр аның бары!
Гадиләрнең тормышлары гади дә бит,
әмма бөек
сагышлары, кайгылары!

**7**

Дөньяның бар читендә
бәхет теләп тирбәтелә
бар бишекләр.
Аналар!

Балаларыгыз, балигъ булгач,
кемнәр булып җитешәләр?

Игенчеләр!
Тир агызып сез үстергән изге икмәк
каныгызны агызырга шашкан җанны симертмиме?
Һәр кылган эш:
һәр ашкыну,
һәр җыерчык,
һәр хәрәкәт,
мускулларның хәләл көче
игелеклеме, кешелеклеме,
Галиҗәнап Эшче Дөнья!
Заман катлаулы,
акыл-аң яшендәй!
Тылсым-сер чишелә.
Ярылды матдә-төш.
Лазерлар... Катлаулы
ачышлар азмы соң!
Әмма дә алардан
мең тапкыр катлаулы
кешеләр язмышы,
халыклар язмышы!
Тәненә,
җиренә,
иленә,
диненә сыймаучы
ач күзләр азмы соң дөньяда!
...Әгәр кемнәргәдер
тәннәрнең кара төсе
яки сары төсе ошамый икән,
алар алайса
сөяр, назлар, яратыр чак — чем-кара төннәрне дә
күрмәсеннәр,
шатлык Алласы — Кояшны да!

Әгәр кемнәргәдер
күп телләрнең бик табигый яңгыравы
җирәнгеч икән,
алар, алайса,
бик табигый сулыш булган
саф һавадан да җирәнсен,
«яратам» сүзеннән дә!..

Киң дөньяда тар күңелле
бозык башлар каршысында, —
хаҗәт икән, —
иңбашларын иңгә терәп
басу кирәк!
Хаҗәт икән —
күчсен таулар,
аусын пирамидалар!
Хаҗәт икән —
сабыйларны башка куеп
коелсын тередән
нәфрәт коймасы!
Тик дөнья,
илереп,
күз яше коймасын!
Аек уй тынмасын!
Битарафлык сөремнәре
җаннарга кунмасын!
Теләк тә, таләп тә:
кешеләр иртәге турында
һәрдаим уйлансын!
Уйлансын!
Президент булырлык ат караучылар,
философ каравылчылар,
полководец күмәч пешерүчеләр,
мәгърифәтче кер юучылар!

Тарихны бер телдә — халык телендә укыгач,
әйберләрнең асылын ачкач,
төсләрне — чәчәкләрдән җыр укучыларга,
авазларны — Кояш нуры тавышын
ишетүчеләргә тапшыргач, —
күпер салучылар һәм шәраб әзерләүчеләр,
агач кисүчеләр һәм камыр изүчеләр,
күмер чабучылар һәм сал агызучылар,
чәчәк утыртучылар һәм машина йөртүчеләр,
чалгы көйләүчеләр һәм тире иләүчеләр,
пыяла өрүчеләр һәм тукучылар,
мөштек һәм ракеталар ясаучылар —
авазлардан үлмәс һәйкәл сезгә!
Таштан — җыр!

*1964 – 1969*
*Казан — Әлмәт*

## КӨРӘШЧЕЛӘР

### 1

Бөтен
планета буйлап
вакансия —
көрәшчеләр кирәк!
Көрәшчеләр кирәк!
Көрәшчеләр!

Бухгалтерлар, исәпләгез!
Хисаплагыз, электрон машиналар!
Күк астында
Кешелекле җаны булган кеше күпме?
«Кем мин?
Нишлим?
Нишләячәкмен?» —
Бу турыда
кешеләрнең
күпмесе уйлый?

Бу сәгатьтә җир йөзендә
бәхете ташкан җаннар күпме?
Дөньяны каргаучылар?
Бу сәгатьтә
җан башына —
күпме шатлык,
        кайгы,
                шартлау,
                        кургаш,
                                икмәк,
                                        тынлык,
                                                нәфрәт...

Җир-әнкәбез безнең хакта нинди уйда:
бик күпме без аның өчен, әллә азракмы?
Дөньяның иртәсеме, кичеме бу?
Чиксезлекме алда, финалмы?
Кая бара Кешелек?
Мең-мең сорау тагын...
Хисапчылар!
Алар дәшми...

**2**

Әгәр без дә эндәшмәсәк?
Күрә торып, күрмәс булсак,
ишетә торып, ишетмәсәк?
Уяу бул, Рух!
Һәр мизгелдә мәгънә.
Бер мизгелдә
гөл ава ала,
ил ава ала...

Әгәр җирдә
янартаулар сулкылдарлык афәт булса,
безгә
сукырлар күзләрен шар ачып карарлар:
«Алдандың төсләрдә!»
Телсезләр шыр ярып кычкырыр:
«Аералмадың авазларны!»
Аяксызлар йөзебезгә килеп басар:
«Ялгыштыгыз...»
Һайт!
Йокымсырамасын җаның!
Уят!
Йөрәгеңне аралап ал битарафлык җәтмәсеннән!
Чайкалсын күңелең,
курыкма!

### 3

Кеше җаны өчен көрәш бара.
Иң нечкә ау,
сәнгатьле ау — кеше аулау.
Алтын, имеш,
көмеш, имеш,
куәт, имеш,
хакимият… —
алар корал,
бары корал ау эшендә.
Иң кыйммәте —
Кеше җаны!
Кеше җаны!
Йә, кызык өчен язаммы мин бу юлларны,
ишетергә телимме мин җинаятен залимнәрнең, фашистларның?
Хәтерләргә телимме мин төрмәләрне,
лагерьларны,
яндыру мичләрен?
Җиңел дисезме язу боларны?
Миллионнарны
аткан,
буган,
ыслаганнар —
тән өченме?
Аскан,
чапкан,
тураганнар —
тән өченме?
Кирәк булганмы әллә
туфля баулары?

Юк!
Җан өчен!
Җан!

Кеше җаны кыю —
кемнәргәдер җан рәхәте.
Җан ул — хөрлек.
Хөрлек — яшәү.
Хөрлек — гади, изге мәгънәләр җыелмасы.
Хөрлек — икмәк,
иминлек,
ышаныч,
сөю һәм сөелү,
кешелеклелек.
Хөрлек — зәңгәр күккә тыныч карый алу,
сабыйларның сөенечен озынайту,
кешеләрне хөрмәт итү,
хыяллану...
Кем хөрлеккә каршы?
Дәшүче юк.
Каршы бер ым юк.
Ә хәвеф бар!
Ә хәвеф бар!!
Ә хәвеф бар!!!
Гуманизм,
әйдә саф алдына,
чакыру уйна!
Көрәшчеләр,
тезелегез!

### 4

Бу дөнья сезнең өчен, көрәшчеләр!
Сезнең өчен бу ал таңнар
Һәм мәйданнар —
офыклардан офыккача,
материктан материкка...
Һәр туфракта туа көрәшчеләр.
Туган җире һәркемнең изге.

Димәк, бөтен җир изге!
Изге җир һәм дөнья,
көрәшчеләр — сезнең өчен!
Сезнең кулда, көрәшчеләр,
халыкларның
ышанычы һәм өмете.
Сезнең кулда —
иртәге көн
һәм Кешелек.
Сезнең кулда —
бөек маяк —
Гуманизм!

**5**

Көрәшләрдә һәлак булалар.
Көрәш булган җирдә түбәнлек бар.
Мәкер дә уяу —
көрәшченең җан тибешен,
кәлтә кебек баш калкытып, тыңлап тора.
Тарих килә арттан.
Ул — күп чакта
хөкем узгач аклар өчен йөгереп килгән
шаһит кебек.

Көрәшчеләр
торсалар да һәйкәлләрдә
мәрмәр таштан, бронзадан,
алар да бит исән чакта —
Кеше.
Аларның да кан йөгерә тәне буйлап,
аларның да һич кипмәгән хис чишмәсе,
аларның да кешегә хас
бер-бер йомшак ягы була.
Ә дошманга шул кирәк тә.

Йомшаклыкны тишеп үтәр
эчкә-җанга,
кимерә-кимерә
җелек буйлап шуар башка таба,
суалчан күк...

Көрәшчеләр аугач,
аренада пәйда була мародерлар.
Кеше кебекләр, мәгърурлар, зурлар!
Ауган — ташланалмый.
Корал күчә залим кулына.
Әләмдә зина кылына.
Быргы — мисездә.
Нишләтергә белми,
уйнатмакчы була кендегенә терәп...

Җиңүме бу!
Түбәнлекнең җиңүе ул —
иллюзия!
Бер мизгелгә
дошман җиңсә
җиңә ала.
Вакыт исә
шушы мизгел хурлыгыннан
көрәшләрнең тудыра яңаларын!
Көрәшчеләр туа яңалар!
Ташкын булып
ташлана алар
мәйданнарга.
Заманны иңләп
яңа буын килә!
Һәлак булган каһарманнар рухы
балкый эшләрендә.
Сүнәме соң Рух!
Сын-һәйкәлләр әнә —
батырларның
бүгенге көн көрәшендәге бер халәте.

Мәңгелек утлар —
көрәшләрнең һичбер бетмәс дәрт билгесе.
Балалар көлүе —
яшьли киткәннәрнең гомер дәвамы.
Җир тулы чәчәкләр —
«дөньяны сөегез» дип елмаюы батырларның...

**6**

Кем көрәшче?
Дошман үзен «дошман» диме?
Көрәшчегә санамыймы ул да үзен?
Олы сүзләр,
матур сүзләр,
изге сүзләр
ят дисезме телләренә?
Эшкә карап — хөкем.
Төп-асылдан — бәя.
Кешелеклелек — критерий!
Көрәшче шул —
Кеше дигән бөек затны олылаучы,
шәхесенә дан җырлаучы.
Көрәшче шул —
бүгенгене кадерләүче,
Киләчәккә ышанычны ныгытучы.
Көрәшче шул —
матурлыкны арттыручы
Җир йөзендә һәм кешеләр күңелендә
илаһи хис — мәхәббәтне
Кояштан да биеккәрәк күтәрүче.
Көрәшче шул —
бүтәннәрнең бәхете өчен
үз гомерен яндыручы —
үлгәч тә яши алучы.

## 7

Кеше җаны өчен көрәш бара.
Иске дөнья һаман тартыша.
Кануннарын үзенең сакламакчы
һәм үсешкә каршы бармакчы...
Халыкларны әйдәп китәрлек,
күңелләрне җәлеп итәрлек
иман-идеясе булмагач,
таянмакчы көчкә, мәкергә,
ысламакчы күңелләрне,
кешелекне сыгып,
җанга тутырмакчы курку,
мәче баласыдай адаштырып,
чыгармакчы хәвеф юлына...

Иске дөнья шулай тартышканда,
казынганда чүплек-арсеналда, —
замананың, үзенең күкрәве
һәм Вакытның үзенең таләбе —
Тынычлык!
    Туганлык!
        Тигезлек!
            Хезмәт!
                Ирек!
                    Бәхет!
...Дога гына кылып бәхет иңми.
Бастилияләр — кычкырып кына аумый.
Көрәш бара икән,
димәк, тартышучы көч бар.
Димәк, әле ул көчнең дә
корымаган чишмәсе бар.
Димәк, әле җирдә бүген дә
Кояш югалса да аңа барыбер
битарафлар бар,
аш өстендә йөзгән май астына
керергә әзер куркаклар бар.

## 8

Бөтен
planeta буйлап
вакансия!
Көрәшчеләр кирәк!
Көрәшчеләр!
Беләклеләр җитә, —
йөрәклеләр кирәк!
Куәтлеләр җитә, —
теләклеләр кирәк!
Көрәшчеләр кирәк!
Көрәшчеләр!

Бу дөньяда сезнең өчен, көрәшчеләр,
Галәм мөлдерәп карый сезгә.
Сезнең кулда —
иртәге көн
һәм Кешелек.
Сезнең кулда
җир хыялы —
Гуманизм!

*1968*
*Казан*

# СӘЙДӘШ

*(Силуэт)*

## Пролог

Гомерләрне талкып, Вакыт ага,
су-дәрьялар сыман бер җайга.
Җилләр генә, ахры, бу җиһанда
ничек тели — исә шулайга...
Киләчәккә таба ага Вакыт.
Туу-Үлемнәрең ни аңа!
Яшәү-Мәгънә диеп уйлана тик
Кеше дигәннәре дөньяда.
Уйланырсың, гомер кыска булгач;
һәр сулышың төгәл санаулы.
Туган минуттан ук — үлемгәчә —
Кояш астында син сынаулы.
Сыный дөнья кылган гамәлеңне
Тарих үлчәүләре аркылы.
Ни китердең яшәп бу тормышта
ил-җиреңә, токым-халкыңа?

Ничек үтәсе соң Кеше булып
Гомер дигән шушы сиратны? —
Үткән белән килер буыннарны
тоташтырган шушы чиратны?
Гаепмени? — кила һәркемнең дә
матур итеп яшәп каласы,
максат биеклеген аласы,
җимерелмәс нигез саласы...
Килә бәхетлерәк итәсе
мәхәббәттән туган баласын,
шатлыкларның тели яңасын!..

Якты дөньяларда яши-яши —
көлеп, елап, хыялланып, ярсып, —
бәргәләнә адәм баласы,
өзгәләнә адәм баласы!
Ахыр чиген үзе белеп торгач,
гаҗәпмени булса ярасы…
Бөек бәхет — калсаң кешеләрнең
күңеленә кунган нур булып,
якты хәтер булып, ләйсән булып,
чәчәк булып, моңлы җыр булып.

## 1. Тукталыш

*Әкертен, җил, монда кабер,*
*монда анам күмелгән!..*

«Анам кабере янында» җырыннан

…«Сәйдәш» тукталышы. Ашыгып төшәм.
Беркем көтми. Мин болай гына…
Гашыйк сыман хисләнсәм дә ярый —
үз ягым ла, татар ягы ла!

Трамвайлар, машиналар, атлар…
Хәрәкәт зур монда як-якка.
Ашыкканнар, әйдә, ашыксыннар! —
мин йөрием әле бу якта,
бу борынгы чатлар сау чакта.
Бер көн килсәң, инде соң булыр —
биек йортлар килә бастырып.
Бу вак өйләр бетә. Китә. Җирдә
әллә бик озак, әллә аз торып?
Һәрберсе аның үзе бер тарих та,
ә сыннары түгел калырлык.

Яңалар ул — яхшы, уңайлы да,
тик яңаның кыска «тамыры»!..
«Сәйдәш» тукталышы — ул минем чат.
Шушыннан китә урамы башы.
Һәр тәрәзәдән Ул карыйдыр күк,
Аны белә күк һәр нигез ташы.
Иркенәеп йөрим, рухым белән
шушы якта торганга күрә.
Йомыш белән түгел, күңел белән
килгән төшем булганга күрә.

Кешегә кирәк кайчак тукталу —
тукталып торып, уйланып алу.
Тукталган төшең иманлы булса,
туктап тору да — ул алга бару!
Бар — күңелләрнең тукталышлары.
Бар — гомерләрнең тукталышлары.
Безнең тукталыш — Идел туфрагы.
Үзәге — Казан — яралы яры.
Үзенә җыя төрле тарафтан
үз кавеменә тугры җаннарны.
Безнең тукталыш — шул Казан инде.
Күп язмышларны кайнаткан кала.
Елаткан кала, юаткан кала,
утлардан алып, суга аткан кала!

Әй, син дә, кардәш, ашыкма әле!
Туктап торыйк шушы урында.
Кабаланмыйк: Казан — урынында,
Идел — янда, Кабан — кырында...
Минем сүзем бар — халыкның газиз,
талантлы бер улы турында,
шәхси тормышта, иҗатта кичкән
гыйбрәтле юлы турында.

Әйтерсең, бәлки, «Нигә гыйбрәтле? —
Ул — бәхетле язмыш кичкән ир!»
Кемдер, бәлки, сөйләвемнән кызык,
легендаи хәлләр көтәдер?
Бәлки…
Әмма мине борчый, уйландыра
талант юлы, талант язмышы!
Рухи байлыктан да кыйммәтлерәк
тагын берәр нәрсә бармы соң?

## 2. Гасыр башланганда

*Кара урман шаулый, ирек даулый,*
*ирек даулый качкын егетләргә!*

«Кара урман» җырыннан

Ул — Сәйдәшев, Җамалетдин улы
Салих булыр — егет солтаны.
Еллар үткәч, шушы гади исем
дөнья гизәр, булыр ил даны.
Әтисе аның — Җамалетдин ага,
Дөбъяз ягы Өбрә авылыннан.
Ә әнисе — чибәр Мәхүпҗамал —
Казан кызы, Идел ярыннан.
Чигүче ул. Күпме гөлбизәкләр
калфакларга чигелеп калгандыр!
Күпме җыры, хыяллары чигү
җепләренә ияреп баргандыр!
Җамалетдин — байда мал йөртүче;
шәһәрдә дә атын җуймаган.
Арба-чаналардан эз калдырып,
нужа чиккән озын юлларда.

…Әйдә, агай, тарттыр дилбегәңне! —
уйнасын җил ат ялларында!

Ни пычагым булсын кешеләрне
алдап җыйган бай малларына!
Маллар түгел, дөнья үзе дә әле
тезгененә эләгеп чак тора!
Эшче халкы күтәрелгән саен,
хаким сыйныф тора калтырап!

Яңа гасыр туды. Һиҗри белән
ундүртенче генә булса да,
миладича егерменче булыр —
Кешелеккә — яңа бусага.
Бу гасырда күп ачышлар булыр.
Күп түгелер илләр каны да.
Еллап түгел, көнләп рух өстәр ул
халыкларның үзаңнарына.
Хөрлек өчен баш салганнар әйтер:
кем монафикъ, кем дөреслеген.
Талау сугышлары әйтеп салыр
церизмның хәчтерүшлеген!

Менә шулай, Җамалетдин агай,
улың туа гасыр башында.
Һәрбер дәвер, үз сынавы белән,
һәр туганның баса каршына.
Туа шундыйлары — җаны белән
ия булып илаһи көчләргә —
үз халкының рухи рәсемен ясый
сүздән, авазлардан, төсләрдән.
Безнең халыкның да тиештер бит
рух куәтен җиһан күрергә!
Күпме талант ничә гасыр буе
бугазлары киселеп күмелгән...
Бу гасырда, бәлки, чыга алыр,
күренә алыр безнең егетләр?
Алда — революция, алда — хөрлек,
акланырга тиеш өметләр!

...Әйдә, агай, куала атыңны!
Җырлап җибәр халык көйләрен!
Җамалетдин белми әле
улы туганчы ук үзе үләрен...

## 3. Йә сәүдәгәр булсын, йә мулла!

*Идел буе яшел таш...*
*Ник елыйсың, яшь туташ?*
*Мин еламый кем еласын —*
*Үзем ятим, үзем яшь.*

Халык җырыннан

Ятимлекне кемнәр татымаган!
гаиләдәме, дәүләтендәме...
Ярдәмне бик күрмәсә дә ятим —
күп күрә ул өйрәтүләрне.
Салих инде шәкерт. Буй-сын үсә.
Сыйныфлар да үтелә берәмләп.
Тик әйт кенә, шытырдатып укыр
һәр сүрәне сиңа Коръәннән!
Сабак вакытлары тиз үтә шул!
Ә аннан соң нишләр бу бала?
Ярым ятим бала үстергәндә
нинди уйлар уйламас ана!
«Мәхүпҗамал, улың үсеп килә!
Эшкә кертик, яшьли өйрәнсен!
Приказчиклар янына урнаштырыйк,
күрә торсын кибет тирәсен...»
«Мәхүпҗамал, киңәш: улың Салих
дин сабагын ныграк өйрәнсен!
Безнең нәселдән дә берәр мулла
чыгып куюы бар, белмәссең!»
Төрле яктан төрле киңәш ява:
«Мәхүпҗамал килен, нык уйла!
Улыңны син кеше итим дисәң,
Йә сәүдәгәр булсын, йә мулла!»

Туган-кардәш әйтмәс начарлыкка,
киңәшләре дөрес тә төсле...
Ә җизнәсе тагын ни дияр бит,
җизнәсе бит укыган кеше!
Әйтте Шиһап*: «Син анасы аның,
ни теләвең, әлбәт, синең эш.
Мондый чакта хәтта ана да әүвәл
бала күңелен тыңларга тиеш!»

Ә Салихның күңеле бүтәндә шул,
башка уйда гаме, уйлары...

Кичә Ташаяктан** күреп кайткан
бер останың гармун уйнавын.

Күз алдында һаман: ярминкәнең
утырган да бер почмагында,
яше-карты сихерләнгән сыман,
җыелышып тора янында.
Әй, уйный соң! Бар бит кешеләр!
Кеше генә микән соң алар?
...Салих төштә күрде: күктә гармун
уйнап йөри фәрештә җаннар!

Ә уянса... нинди могҗиза бу? —
Өстәлендә тора чын гармун!
Үрелеп ал да, теге оста кебек,
уйнап җибәр көйләр, чыгар моң!
Бар икән ул бәхет, бар икән ул, әгәр
хыялдагы килеп, чын булса!
Әйдә, Салих, уйнап җибәр әле,
күңелеңдә ташыр моң булса!

---

* Ш и һ а п – Шиһап Әхмәров – педагог, мәгърифәтче, татар мәдәнияте тарихында якты эз калдырган шәхес. Ул шулай ук Салих Сәйдәшевнең шәхси тормышында һәм композитор булып китүендә зур роль уйнаган кеше.

** Т а ш а я к – революциягә кадәр Казан суы буенда, хәзерге цирк урнашкан тирәләрдә мәшһүр Ташаяк ярминкәсе уздырыла торган булган.

## 4. «Шәрык клубы»

Жанга якын йортлар калалмыйлар
макет-фотоларга төшеп тә...
Бульдозерлар көчле. Төртә-ишә.
Тигезли дә куя. Эш бетә...

Түрәләрдән бик озак рөхсәт даулап,
искә алып байлар көен дә,
рухи ихтыяҗдан туган бина
әверелгән халык өенә.
Патша сарае күк түгел инде,
Шамил йортына* да җиталмас...

Изге эш дип, фидаиләр куйса,
Гади таш та гүя чын алмаз!
Гали сүзләр белән дөньяга
сабый бала аваз салгандай,
монда янә тавыш бирә башлый
халык рухы, терелеп яңадан.
Евангелийский** урамында
(бер исеме генә ни тора!)
Мәшһүр Болгар белән күрше генә
өч катлы бер җыйнак йорт тора.
Бу тирәдән, белмим, кемнәр ничек,
нинди уйлар уйлап узадыр...
Ул — аванпост Олы Яңарышның,
ул — учагы милли үзаңның!
Монда — театрның башлангычы,
яңа чоры — әдәбиятның.
Монда көрәш, яшьнәү рухы сеңгән
кирпеченә кадәр һәр катның!

* Ш а м и л  й о р т ы – мәшһүр шәех Шамилнең оныгы, генерал-майор Заһид Шамил торган йорт. Хәзер анда Тукай музее.

** Е в а н г е л и й с к и й – хәзерге Татарстан урамы.

«Сәйяр»* тамашасы, Тукай сүзе.
Әмирханлы** милли кичәләр,
Мулланурлар*** чыгышы... Уйлансаң,
күп шәхесләр искә төшәләр.
Талантларны бергә җыйган клуб,
яшь көчләрне чакырып эндәшкән.
Монда иң беренче сынау бирә
безнең герой — япь-яшь Сәйдәш тә.
Ул вакытта әле үсмер Салих, —
Сәйдәшлеккә әле байтак ел, —

«Озын сәфәр»ләрдән**** бөеклеккә
хәерле юл сиңа, хәерле юл!

«Аккош маршы»н***** уйный Салихыбыз.
Бөтен бер зал аның хөкемендә.
Бик күпләрнең әле, сагынып-сагынып,
Хәтерләре кайтыр бу көнгә!
Алгы рәттә утыра Кариев.******
Күңеле аның нинди уй-гамьдә?
«Мондый көчле халык — бөек халык,
мондый халык үлмәс!» — ди мәллә?
Фатих Әмирханның үз уйлары:
«Бу малайда очкын-ут яна!
Болай булса Шәрык йоклап ятмый,
Шәрык тора, Шәрык уяна!»
Галиәсгар******* ага ни ди? Шөкер,
дустанә бер нур бар күзендә.
Канәгатьтер, ахры, бу сынаудан
Заһидулла******** абзый үзе дә.

---

* «Сәйяр» – беренче татар театры труппаларының берсе.
** Әмирхан – Фатих Әмирхан.
*** Мулланур – Мулланур Вахитов.
**** «Озын сәфәр» – Салих Сәйдәшев язган беренче әсәр.
***** «Аккош маршы» – атаклы скрипкачы Хәйбулла Әхмәдуллин әсәре. Революциягә кадәрге елларда бу марш бик популяр булган.
****** Кариев – Габдулла Кариев.
******* Галиәсгар – Галиәсгар Камал.
******** Заһидулла – Заһидулла Яруллин.

Тукай исән булса, бик ихтимал,
шатлык балкыр иде йөзендә.

...Баш игәндә, аның Тукай белән
карашлары очраша алмады.
Заманалар килгәч, чорлар аша
тоташтырыр бергә урамнары!

Зур сәхнәдән бүген аваз салды
горурлыгы килер көннәрнең.
Ораторлар әйтер бер көн: «Сәйдәш —
Тукае ул безнең көйләрнең!»

### 5. Көзге ачы җилләрдә

*Ком бураны, ком бураны.*
*Оренбурның урамы.*
*Илдә көрәш барган чакта*
*өйдә ятып буламы?*

«Ком бураны» җырыннан

Оренбур ул — татар-башкорт җире.
Оренбур ул — Кәрвансарайлы,
Европа белән Азия чиге-чаты
һәм капкасы чиксез даланың.
Бөтен илне ут ураган чакта
бер Оренбур гына каламы?
Быел гына аны төрле яктан
ничә тапкыр яулар камады!
Саклар өчен көрәш казанышын,
яшь көчләрне ала ил дәшеп.
Оренбурда хәзер кызылармеец —
Казан егете Салих Сәйдәшев.

Таңны ярып, «Вакыт торырга!» дип,
быргы кычкыртучы кем дисез?
Бөеклеге түгел, исеме дә
күпләр өчен әле билгесез
ул — бер солдат. Яше — унтугызда.
Үзе теләп килгән фронтка.
Сыный аны тормыш, сыный көрәш,
бер суларга кертеп, бер утка.
Алда — поход... Канлы, тузанлы юл...
Алда — чигенү дә, җиңү дә.
Ир-егеткә солдатлыкта йөрү
бер чыныгу була кимендә.
Тик исән кал! Җиң! Җиң! Тик егылма!
Егылсаң да, тор син яңадан!
Хәер, яуда Яшәү-Әҗәл эше —
картлар сүзен әйтсәк — Ходайдан...
Кайный дөнья. Алыша Яңа — Иске.
Бер хәлиткеч фронт — Төркестан.
Байтак монда безнең якташлар да,
бригадалар — татар-башкорттан.
Туплар тынып торган араларда,
киң Төркестан далаларында
нинди генә уйлар килми дисең
Җир-әнкәнең балаларына!
Дары төтеннәрен читкә куып,
килә моң да, килә сагыш та.
Сөйгән ярлар, Туган якның ае,
дулкынланып торган арышлар...
Безнең яктан, ахры, бу ак болыт?
Безнең Җирдән, ахры, бу кош та!
Бик ямансу булып китте әле,
сузып җибәр әле, әй, дускай!
«Йөгереп китәрдәй булам ла,
кайтып җитәрдәй булам,
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә!..»

Моңлы җырны ялгыз тыңлау яхшы.
Ә бу җырны — кирәк күмәкләп!
Солдат сагышы бу. Җырлаганда
үрсәләнеп тибә йөрәкләр!

...Туп ухылдап аваз салган чакта,
әйтәләр бит: Муза тын торыр.
Сугыш түгел, Яшәү мәңгелек бит,
бу кан коюю туктар бер, тыныр.
Хезмәт халкына соң ни кыйбат?
Азат тормыш, тыныч ил кыйбат!
Шуның өчен дә бит революция!
Шуның өчен дә бит инкыйлаб!

...Сугыш соңы безнең Салихны да
янә Оренбурга ташлады.
Ике-өч елда нинди генә мәхшәр
күрмәде икән солдат башлары!
Әй, Оренбур! Татар-башкорт җире!
Мәгърифәт нуры иңгән җир.
Урал-Идел рухи дөньясына
күп атаклы шәхес биргән җир!
Еваклардан килгән кардәшеңне
куеныңа сыендыр әле!
Күңеленә ятыш шөгыль табып,
илһам биреп сөендер әле!
Ил даны өчен яралган җанны
яңа казалардан сакла син!
Казаннарга барып ярышырлык
талантлар биргән як ла син!

Эшкә чумды Салих. Вакыты җитми —
белем дә ал, рәттән эшлә дә...

Оркестрны ничек көчәйтергә?
Бу ансамбль белән нишләргә?
Әле анда чыгыш, әле монда…
Сусаган ил җырга-көйләргә…
Яшьләр бурычы — яңа тормышны
яңа аһәң белән сөйләргә!
Чакыралар агитбригада белән
Азиягә — Ташкент ягына.
Салих күңелендә, очар коштай,
туар җырлар канат кагына.
«Озын сәфәр» туды, «Татар вальсы»…
Болай булса, эшләр барачак!
Күңел ташый. Агыла моң да, дәрт тә —
килде, ахры, күкрәр, янар чак!

## 6. Театр

*Театраль чаткылар.*
*Яңа Кояшның беренче нурлары.*

Мулланур Вахитов

Татар халкын кәмит-тамашасыз
күз алдына китерү кыен хәл.
Сәйдәш дөньясын белием дисәң,
театрны аңла иң әүвәл!
Театр ул — халык рухының
тантанасы, шатлык-кайгысы.
Егерменче еллар театрын
күз алдына китерә алмыйсың
Сәйдәшсез син. Сәйдәш — театрны,
ә театр аны үрләткән.
…Ә ул еллар — күпләр хәтерендә
сакланалар газиз бүләктәй.

Халкыбызның ихлас тартылуы
тамашага, җырга, уенга
килә ерак-ерак гасырлардан —
сабантуйларыннан, җыеннан.
Көне-төне гел-гел эш димәгән,
күңелгә дә бәйрәм яса бер!
Халык рухы, бер чигенә җиткәч,
үз буена торып баса бер!
Ташып чыга җыры, бәетләре,
чәчрәп чыга уйнакчанлыгы.
Нигә бер-береңә илең белән
бүлешмәскә күңел пакьлеген!
Әле бу хәл өстеңә таш бастырган
Царизмлы чакта, коллыкта...
Ирек кенә булсын, төтен түгел,
ялкын бәреп чыгар юллыктан!
Күрче, ул бишенче еллар нишләтте:
«Сәйяр» чыкты, «Нур»лар балкыды!
Заман набат какты: вакыт җитте!
Яула, расла рухи хакыңны!
Шифа җилләр күмелергә яткан
күпме талантларны калкытты!
Ыргылдылар алар яктылыкка,
үзләренә әйдәп халыкны.
Хөррият килде! Золым карачкысы —
сәмруг кош канда тончыкты!
Ирек килде! Кара мунчалардан
скрипка, гармуннар чыкты.
Җиң эченнән кубызлар чыкты,
итек кунычыннан — курайлар!..
Тиздән менә спектакльне дә
оркестрлар белән куярлар!

...Оренбурга — Салих Сәйдәшевкә
хәбәр килде беркөн Казаннан.

Дәүләт театры оешкан, ди,
шунда эшкә чакырып язганнар.
Дәүләт театры! Уенмыни!
Уйлата да, кызыктыра да.
Труппалар, димәк, сукбайлыктан
чыгып, хәзер яңа юл яра!
Туган яктан килгән чакыруга
сагынулар килеп кушылды.
Анда — әнкәй, дуслар... Анда — Идел.
Әй, Оренбур! Сау бул, хуш инде!

* * *

Ә театр чынлап яңа икән!
Артистларның уен, рух бүтән!
Тинчуринга* үрнәк театрны
оештыру йөкләнгән икән.
«Кәбәм, Салих, безнең уртак эшне
«Башмагым»нан башлап карыйбыз.
«Башмак» яхшы чыкса, белеп булмый,
бәлки, бергә ерак барырбыз!»

Тоя, сизә Салих: ышаналар:
өмет күзе белән карыйлар.
Ышанычны тою яхшы да бит,
аклый алсаң аны ярый ла!
Яшь чакта ук бер хакыйкать аның
нык урнашты кереп аңына:
улы булып, сөеклесе булып
керә аласың халык җанына
фәкать шул чак, үзең халкыңны
фидаичә яратсаң гына!
Тудырасы иде шундый көйләр —
халык йөрәгенә үтәрлек!

* Тинчурин — Кәрим Тинчурин.

Булсын иде шундый көч аларда —
ерак гасырларга китәрлек!
Моның өчен нәрсә? — Хезмәт кирәк!
Бирү кирәк бар көч-дәрманны!
Талант бер хәл, өстәп — ихтыяр,
сугышчан рух, холык бармы анда?
Җавап соңрак. Әлегә эш башы.
Олы максат җанда — игелек кылу.
Уйлар чиста. Күңел җилкенә.
Күпләр хәзер аңа эндәшәләр
«композитор Сәйдәш!» дип кенә!
«Казан сөлге»ләрен билгә урап,
кулга «Зәңгәр шәл»ләрне тотып,
йөри Муза «Кандыр буйлары»нда,
«Сүнгән йолдызлар»ны яктыртып!
Йөри Муза Шәрык дөньясының
пәрәнҗәсен ачып, уятып.

Идел, Урал, Кавказ күзен ачты,
Төркестанны кирәк кузгату!
Безнең якның байтак талантлары
ул якларга нурны күп чәчте.
Якты көне өчен Азиянең
канын, җырын биреп көрәште.
Еллар үткән саен ачыла бара —
кемнәр булган чишмә еручы...
Ерак Кәттәкурган театрын
Сәйдәш булган оештыручы!*
Җылы якта — җәйге театрда
күпме кадер-хөрмәт казанма,
өзелеп сагынып төп театрын,
көзен кайтыр иде Казанга.

* 1922 – 1928 елларда Салих Сәйдәшев, Казанда театр сезоны ябылгач, Кәттәкурган (Үзбәкстан) шәһәренә китеп, яз һәм җәй буе шунда эшләгән. Хәзерге А.Мәҗиди исемендәге Кәттәкурган дәүләт драма театрын оештырган һәм аның беренче баш режиссеры булган.

...Камал театры — Сәйдәш өчен
Туган йорт күк газиз бер урын.
Ул — аңа түккән күзенең нурын,
Ул — аңа түккән күңеле моңын,
утыздан артык гомере елын.
Театрда ул, яңадан туып,
әверелде халык улына.
Шунда аның бөеклеккә чыккан
баш юлы да, соңгы юлы да...

...Ул бүген дә әнә театрда.
Театрның алгы фойесында.
Китмәскә дип килеп утырган ул
мәрмәр креслога, таш сында.
Тамашачыларны каршылап, ул:
«Хуш киләсез, әйдүк!» — ди мәллә?
«Зәңгәр шәл»гә диеп килгәннәрдән
берәр танышын эзли дә мәллә?
Әйе, үз йортында — театрда ул.
Мәрмәр креслода, таш сында.
Инде ничә буын, юксынып үзен,
башын иеп үтә каршыннан.

## 7. Хатыннар

*Хур иткән дә хатын,*
*Зур иткән дә хатын.*

Әйтем

Кемнәр сылу? Хатын-кызлар сылу!
Нечкә күңел кемдә? Аларда!
Баш июләр, тезләнүләр бер дә
юкка гына түгел Хаувага!
Кадим риваятьләр әйтә килә:
электә дә алар баш булган.

Тәне — җиргә, җаны — утка якын...
Яннарында — бала, аш булган.
Прометей батыр кулыннан да
алар утны алдан алганмы?
Шулайдыр да, хатын-кызныкы күк,
тагын кемдә җанның кайнары?
Сине сөйсә алар, син бит — Алла!
Үз кадереңне үзең бел генә!
Нәфрәтләнсә — беттең! Өтеләсең!
Син бәндәдән калыр көл генә!..
Менә шундый безнең хәлләр, ирләр!
Шундый эшләр, иптәш ирҗаннар!
Алып-затны кайчак балавыздай
эретеп кенә сала марҗалар!
«Мин пәри зат кебек гүзәл булгач,
көчле булсын ирләр, чибәр дә!»
Каршы торып кара «дин!», «мин!» белән
хатыннарның шулай дигәненә!

...Булса була икән, килсә килә икән,
бирсә бирә икән Ходай да —
нинди җаннар дога кылды икән
Салих туар кышкы бу айда?
Зәңгәр күзле, сыны килешле,
сөеп туймас ап-ак маңгае...
Кемнәр бәхетенә үстердең син,
Мәхүпҗамал җиңги, малаең?
Урамнарга чыкса, аңа хәзер
Такташ Алсулары күз ата.
Асыл бу егетнең күз карашы
сылуларның бәгырен кузгата!
Ә Салихның инде үзенең дә
мәхәббәттән шашкан чаклары,
«Валя! Валя! Валентина!* Синнән
сөйкемлерәкләрне тапмамын!»

* Валентина – сүз Салих Сәйдәшевнең беренче хатыны В.М.Мухина турында бара. 1926 елда вафат була.

Кавыштылар алар. Җәй башында
Салих булды башлы-күзле дә.
Каршы төшмәделәр — әнисе дә,
әтиседәй Шиһап җизни дә.
Әй, ул яшьлек канатында күкрәп,
бәхет катларында очулар!
Икәвеңнең бер җан була алуы —
гаилә сәгадәте шушыдыр!
Гел шат көйләр җанда, гел дәрт канда,
гел яшисе килә, эшлисе!
Иҗат ургый! Тою рәхәт: син —
кешеләрнең кирәк кешесе!
Өйдә — шатлык. Эштә — алга барыш.
Сөенерлек мең-мең сәбәпләр.
Әнә театрда, техникумда
гөрләп үсеп килә сәләтләр!
Валя әйтә: тиздән (нинди шатлык!)
яңа тавыш аваз саласы!
Үз бәхете белән туа күрсен
мәхәббәт һәм сөю баласы!

Шатлык белән кайгы гел янәшә —
Тормышныңмы диалектикасы!
Исән калды — нәни баласы.
Ятып калды — бала анасы...
Үкси Салих. Үкси яшь әти.
«Ятим идем. Тагын бер ятим...»

Табигатьтә бөек гармония.
Ул шулаен анысы шулай да...
Күпме җаннар тәңгәл килалмыйча
тилмерәләр фани дөньяда!
Кан йөрешен тою әле бер хәл,
җан тибешен тою кыен ла!

Хатын исеме белән күзне буып,
асылынучы күп ул муенга.
Ә чын хатын — газиз, якын, җандаш…
Шундый хатын, әйтегез, кемнәрдә?
Рәсми җавап түгел: имеш, андый
туры килә меңнән берәүгә.
Аңлашалмый яшәү, ай-яй, кыен!
Иҗат кешесенә бигрәк тә!
Кысла булып йөри һәр авыр сүз
җанда, нервларда, йөрәктә…

Сәйдәш мисалында, бу җәһәттән,
байтак хәлләр бар ул барын да…
Фаҗигадә артык казынмыйча,
туктап торыйк шушы урында.

## 8. Сәяхәт

*Шаулый диңгез…*
*Җил өрәдер…*
*Җилкәнен киргән кораб!*

Дәрдмәнд

Бу дөньяда ике шәп табиб бар:
берсе Вакыт аның, берсе — Юл.
Вакыт безгә бәйсез. Ә менә юл —
сәфәр эше безнең кулда ул.
Җирләр гиз син, айка дөньяны!
Бер тынычлык тапмасмы җаның?
Сәйдәш бу елларда театр белән
гизде илнең байтак юлларын.
Юллар төрле алар. Ә монысы —
кабатланмый торган сәяхәт.
Зур әдипләр белән йөргәнеңне
искә төшерүе дә бер рәхәт.

Иҗат кешеләре бердәм булса,
уртак учак янар дәртлерәк.
Бер-береңә була алсаң терәк —
сәнгать үрен яулау җиңелрәк!
Чыккан юлдашларың кемнәр дисең, —
Кәрим абый, Такташ, Нигъмәти,
Шәриф Камал, Кутуй, Кави Нәҗми... —
һәрбер исем олы, хикмәтле...
Эш уң булыр: бөек якташ Горький
фатихасын алган сәфәр лә!
Алда — ил күрүләр, очрашулар,
яңа җирләр, яңа шәһәрләр...

Алда — ике диңгез, Каф таулары...
Яңа тәэсир, яңа кичерешләр.
Алда — Кырым. Галимҗан Ибраһимов.
Сөйләшүләр. Эшләр. Киңәшләр...

...Чит җирләргә китсәң, Туган якның
чүплеге дә ямьле тоела.
Татар өчен, кая китсә дә ул,
кайда Казан — шул як кыйбла!
Каспий буйлап йөзә ак теплоход,
дулкыннары ярга кагыла.
Җилләр кайсы яктан иссәләр дә,
уйлар һаман Казан ягында.
Бер хатирә: Мансур* белән икәү
төшкән идек, гармун уйнатып,
Көймә белән Балык базарына**,
Ташаяктан Болак буйлатып!
Болак — безгә олы елга иде.
Кабан инде — Казан диңгезе!
Ант итешкән идек без ул кичне
ташламаска бер-беребезне.

---

* Мансур – Мансур Мозаффаров.

** Балык базары – Иске Казанның хәзерге Тукай мәйданы («Кольцо») тирәсендә була торган базар.

Озак итеп шунда, тып-тын гына,
карап торган идек Кабанга.
Көймәләрдән яңгыраган көйләр
ишетелә кебек һаман да!..

...Ә диңгез шавы — бөтенләй башка!
Дулкынлавы бүтән, ярсуы!
Монда — чишмә, инеш, елга суы,
монда яңгыр, монда кар суы...
Челтерәү дә, ярсу, пышылдау да —
монда тавышларның һәммәсе!

Бу халәтне биреп бетерә алмас
биш тавышлы «кытай» гаммасы...
Киңәйтергә кирәк, көчәйтергә!
Нигә полифониядән качарга?
Музыка бит тиеш тавыш белән
күңелләрдә бәйрәм ясарга!
Чөнки Тормыш — бәйрәм. Яшәү — бәйрәм.
Көрәш — бәйрәм. Хәтта — Үлем дә!
...Уйлый Сәйдәш. Уй — күп. Диңгез үзе
сыеп беткән кебек күңеленә.
Гамьле җанны, эш күрсәткән саен,
яңа борчу, яңа уй баса.
Бер карасаң, борчылырлык түгел,
эше гөрләп бара лабаса!
Яраталар үзен. Казанда — үз.
Бу якта да ят түгел икән.
Бакуда ул алган алкышларны
бездә тагын кем күрер икән?
Яңгырады көньяк күкләрендә
«Шәрык биюе» дә, «Марш» та...
Әллә ничек тәэсир итте әле
тәбрикләүләр, дәррәү алкышлар.

Бу сәяхәт бик гыйбрәтле булды
күз өчен дә, күңел өчен дә.
Офыкларны ерагайту кирәк,
бикләнмәскә кабыгың эчендә.
Дөнья зур. Бөек музыка бар.
Бар тарихның Бетховеннары.
Шопеннары, Чайковскийлары,
Сибелиус, Чюрленислары... —
тагын күпме даһи җаннары!

...Кара, бездәгедәй күгәрченнәр!

Ап-ак күгәрченнәр бу якта!
Күгәрченнәр гөрләсенгә, Салих
күпме оя куйды яшь чакта!
Кошлар күп ул. Ераграк оча
көчлеләре, канатлылары.
Сәнгать күкләренә биек менә
гайрәтлесе талантлыларның.

## 9. Мәскәү калалары таш кала...

*Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,*
*Сагынам Туган илкәйне!*

Халык җырыннан

Тартыйм дисәң алга, олы юлга
Тарих тинтерәткән арбаңны —
кую кирәк, мирасыңнан чыгып,
өч-дүрт тапкыр артык дәрманны.
Уку кирәк, зыялылык кирәк,
һәм эшләргә кирәк ат кебек!
Сиңа мөлдерәп халкың караганда,
сынатсак без, булыр оят, егет!

Газет-журналларда, кулуарларда
кызу-кызу бәхәсләр бара.
«Татар музыкасы нинди юлдан
китәр икән, диеп, ал таба?»
Гареб яки Шәрык үрләренә,
мирасыңнан чыгып, атлап кит.
Милли көйләрнең аһәңен саклау —
ул халыкның хәтерен саклау бит!
Көйләребез моңлы. Ә «моң» нәрсә?
Тәрҗемәләп булмый «моң» сүзен.
Югалтмаска тиеш үз рухын ул
һәм җуймаска тиеш үз йөзен.

...Кайчак чиктән чиккә ташланулар, —
белмичә дә бугай, белеп тә, —
«габәшичелек» дип, «фәләннәр» дип,
көч таркату җанны әрнетә.
«Сания»ләр* хуплап алынса да,
язып чыксалар да чит илләр, —
тик әле алар бу зур сәнгатьнең
таләбенә килеп җитмиләр...

...Нигә укымаска? Сәләтеңне
үстерергә мөмкинлек барда?
Халык талантлары чарлансынга
яхшы шартлар туып торганда?
Яшь көчләрне, студия ачып,
башкала бит үзе эндәшкән!
Хыял тулы яшьлек поездында
китә яшьләр. Китә Сәйдәш тә.
Кәрим ага бик җибәрмәс иде,
театрга Сәйдәш бик кирәк.
Ил теләге, халык ихтыяры
шәхси теләкләрдән биегрәк.

* «С а н и я», «Э ш ч е» – беренче татар опералары. Авторлары – С. Габәши, Г. Әлмөхәммәдев, В. Виноградов.

Озаталар. Нинди шатлык төяп
кайтыр икән бер көн бу поезд?
Сез кайтуга, бәлки, өлгерер дә
опералар өчен йортыбыз.
Перроннары, өметләре белән
республика кала, ил кала.
Киткән чакта Казан бигрәк матур!
Сагынырбыз сине, и кала!
«Хәерле юл!» теләп, юл уңайга
Бакалтайда* җикән чайкала!..
Мәскәү калалары — ул баш кала.
Ныклык сорый торган таш кала.

Утыз биштә ирнең, уку түгел,
уе була икән башкада.
Һәр нәрсәнең бар шул үз вакыты.
Һәрбер кошның була үз күге.
Әллә юкка гына булды микән
килүләре аның Мәскәүгә?
Эшем шәһәре бу. Кешеләр — елгыр.
Терекөмеш кебек, ашыгалар.
Монда, туган шәһәрдәге кебек,
кырык өйдә көтми самавыр...
Үсәр өчен, балавыздай түгел,
корыч холык кирәк бу яшьтә.
Бармы соң ул яшьли дан татыган,
йомшак җанлы, хисчән Сәйдәштә?
Сагына Казанын ул, балаларын,
театрын, якын-ишләрен...
Тиккәмени Казан вокзалларын**
урап кайтулары кичләрен!
Ә егетләр эшли! Күбесенең
опера да балет телләрдә.

---

* Бакалтай – Казан суының Иделгә койган тирәләрендәге болынлыклар. Хәзер су астында калды.

** Казан вокзалы – Мәскәүдәге Казан вокзалы истә тотыла.

Ә Җиһанов* инде язган! Кемнәр
«башлыйм», «язам!» диеп йөргәндә,
Яруллин** да балет тәмамлаган.
Сәйдәшкә дә вакыт түгелме?
«Зәңгәр шәл»ле бер опера язу
уе күптән йөри күңелдә.
Ә кул бармый... Әллә «сыныйм» диеп,
сындырмакчы бу Язмыш туташ?
Нигә әле бик еш телгә килә
борынгы сүз: in vinas veritas***.

## 10. Озын төннәр

*Караңгы төн, ява яңгыр,*
*Өстемдә бер кулмәгем...*

Халык җырыннан

Әнисе үлде... Улын җирләде...
Ике кайгы рәттән, тоташтан.
Ә еллары нинди! Авырлыклар
ишелеп килә килсә бер башка!
Курку-шөбһәләрдән ишекләр дә,
күңелләр дә катлы бикләрдә.
Әйтерсең лә шомлы караңгыда
бүре кебек улый этләр дә!
Ичмасам, таң да сызылмый. Хәер,
көннәре соң төннән киммени?
Һәр таң саен хәтәр хәбәр туа,
дуслар кими, курку кимеми.
Кулдан төшә эшләр. Күпме кылган
хезмәтләрем китте вәйранга!
Күпме җырлар, күпме арияләр
куылдылар инде мәйданнан...

---

* Җиһанов – Нәҗип Җиһанов.
** Яруллин – Фәрит Яруллин.
*** Хакыйкать – шәрабта (латинча).

«Зәңгәр шәл»нең, «Кандыр буйлары»ның
ярамаска чыкты сүзләре.
Төшләремә керә Булатларның,
Мәйсәрәләремнең йөзләре...
Бетергечләр тузды сүзләр бозып,
ул алмаса — сыздык тушь белән.
Киңәшеп тә булмый. Кем — кем бүген?
Аралашкан дошман дус белән.
Уңга-сулга карап сәнгать тумый.
Җан хөрлеге кирәк иҗатта.
Метаморфозаларны белми чын җыр:
йә халыкка, яки — учакка!..

## 11. Җыр

*Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә*
*Һәм үләргә кыю ир булып!*

Муса Җәлил

Халыкларның җаны — ул җыр, диләр.
Җыр, диләр дә, бездә — моң, диләр.
Телгәләсә, киссә бәгырьләрне,
татар җыры инде — шул, диләр.
Моңда баскан, изгән, туглаган... Юк,
безнең җырлар — киңрәк, тирәнрәк!
Ничек тоташ хәсрәттән торсын
хезмәт дәрте тулы бу йөрәк!
Җиң сызганып эшли белгәннәрдә
күпме куәт, күпме ярсу бар!
Каннар кайный икән, димәк, бездә
Мәхәббәт бар, сөю, ачу бар!

Сәйдәш иҗатыннан, эзләсәң дә,
таба алмассың көйләр бер көнлек.

Халык рухы кебек сәламәт ул,
юк аларда шыңшу, мескенлек.
Яшәү тантанасын, хезмәт дәртен,
күңелләрнең җилкенүләрен
әйтә, раслый һәрбер аккордында
фани дөньяның бар ямен.
Чалгычылар чалгы янаганда,
шахтер егет күмер чапканда,
монтер егет утлар кабызганда,
кызлар өмәләрдә чакларда —
без һәммәбез алар белән бергә,
бер адымда, бер үк сулышта.
Кешеләр белән берлегеңне тою —
үзе бер бәхет бит тормышта!

Җыр язмышы — халык язмышы ул,
ил язмышы белән беррәттән.
Ил яулаган һәрбер үр-биеклек
көйләр, җырлар белән береккән.
Илне яңа сафка бастырганда,
ашкынулы бишьеллыкларда,
күмәк хуҗалыклар төзегәндә,
Днепрогэс, Магниткаларда
Сәйдәш тә бар, төзүчеләр,
коручылар белән бер иңдә.
Зур сәнгатьнең, масса сәнгатьнең
өлеше бар һәрбер җиңүдә!
Сәйдәш рухы йөрде фронтларда,
окопларда, алгы сызыкта.
Туплар булып яңгырады «Марш»
фашизмга каршы, коллыкка!
Шифа-өмет булып кунды Сәйдәш
әсирләрнең туңган җанына.
Җиңү булып, яшьнәп керде Сәйдәш
Бранденбург капкаларыннан!

Сәйдәш — җыя бергә, туплый, әйди,
йокымсыраганны да кузгата.
Якты рух өсти ул. Кешелекле
тавыш-аһәңнәрне уята.
Эчке тоем белән рухка үтү —
Сәйдәш талантының иркендә.
Җырлары аның — шәхси үзенеке дә,
шул вакытта — һәркемнеке дә!

## 12. Әй, дуслар, дуслар, дуслар...

*Яман дуска караганда,*
*Кәкре таяк яхшырак.*

Мәкаль

«Дус» сүзе бар. Бер иҗекле генә...
Ә мәгънәсе — чиксез һәм тирән.
Әй, кыен шул асылын бу сүзнең
дөрес итеп аңлап бетерү!
Бу сүз «ана», «икмәк», «туфрак» кебек
төшенчәләр белән беррәттән.
Шуны аңлауда ялгышсаң, Тормыш
борыныңа сугып өйрәтә!
Хәер, кемнең юктыр үз башыннан
кичкән, күргән төрле гыйбрәтләр!
Күпме алар данлы китапларда —
Әл-Коръәндә, Инҗил, Тәүратта!
«Дус» исеме белән кемнәр генә
ниләр генә башкармаганнар!
Нинди башлар ашалмаганнар!
Мифлар әйтә: ничек алданганнар
хәтта пәйгамбәрләр, Аллалар!
Әле дә бар ул оста уйнаган
«дус» роленең әллә кемнәре...
Бу заманның Яго-уллалары,
бүгенгенең Сальери-етдиннәре!

Сәйдәш тирәсендә күпме булган
чебен кебек сырышып йөрүче!
Дус битлеге белән җанга үтеп,
вакытын ашап, бәгърен кимерүче!
Амбицияләре зурдан булган
«сәнгать» яратучы «җан дуска»
талант нәрсә?.. Алар өчен Сәйдәш —
интеллектуальный закуска!

Товар-ишләр бик ишәйгән чакта,
мал буенча «дуслар» артканда,
кемдер — алтын, мебель, вилла,
лимузин, дип җанын сатканда...
Төкер! Табигатькә чык син! Ишет
бөре авазының кодрәтен!
Кошлар канатыннан көйләр укы
һәм җилләрнең яса сурәтен!
Девальвацияләр ала алмаслык
байлыклар бар җирдә бәхәссез!
Җан бәйрәме — сөю бәһасез,
Җыр — бәһасез, талант — бәһасез!
...Дуслар... Уендашлар... Шешәдәшләр...
Сердәш булып йөргән көндәшләр...
Һәрчак булган, һәм бар, булачаклар —
туып кына торсын Сәйдәшләр!

## 13. Затлылык

*Вөҗдан хөкемен белмәгән җанга*
*Хак-дөреслек белән Ялган — бер.*
*Дөньяга — кешелеклелек белән*
*интеллект җитми калган гел...*

Халык рухы саегуны белмәс.
Җан тартылыр учак гел кирәк.
Замананың җилләренә карап,
ялкынлавы була төрлерәк.

Әмма Кеше һәрчак омтылачак
Матурлыкка, Чынга, Хаклыкка;
кайгылардан сыгылып төшкән чакта,
җиңеләйгән чакта шатлыктан —
бушанырга кирәк була аңа —
күңелендә, әйдә, таң атсын,
сабый бала кебек садәләнсен,
кешелеге артсын, яңарсын!
Сәнгать — илаһи бер учак. Аның
бер балкышы Сәйдәш булды бит!
Көй тылсымы белән халкыбызның
күзәнәкләренә тулды бит.

Талант — сирәк. Тик алар бар. Кемнең
мәңгелеккә килмәс каласы.
Сирәк арасыннан бер гәүһәрен
халык үзе сайлап ала шул.
Элегрәк тә, Сәйдәш чорында да
талантлар туа килгәннәр.
Фәйзүк*, Мотыйгыйлар** — заманында
йөзек кашы кебек йөргәннәр.
Ә соңрак Сәйдәш калкып чыккан,
якты йолдыз булып янарга.
Әкияттәге сулмас чәчәк кебек,
күңелләрдә мәңге калырга.
Ә ник Сәйдәш? Нигә бүтән түгел?
Тау кадәрме әллә хезмәте?
Эше гел гүзәлме? Чиксез мәллә
үзен зурлата алу кодрәте?
Гел алай ук түгел... Хикмәт, ахры,
талантының табигатендә.
Шәхес булып яшәү рәвешендә,
сөйләшүендә, һәр гадәтендә,
кешеләргә ягымлылыгында,
дөньяга мөнәсәбәтендә...

* Ф ә й з ү к — Фәйзулла Туишев.
** М о т ы й г ы й — Камил Мотыйгый.

Беркем әйтмәс: Сәйдәш дорфа иде,
көнчел булды яки үчле, дип.
Чордашлары әйтә: ачыклыгы,
гаделлеге, интеллигентлыгы,
кешелеге белән көчле, дип.
Илаһи зур талант, өстәвенә
сирпеп торган аннан затлылык!
Күңелеңдә кояш булса гына,
чәчеп була илгә яктылык.
Якты башлыга да, затсыз икән,
халык тормас иде тартылып...

Интеллигентлык һәм затлылык! —
бик дефицит безнең заманда!
Уйлабрак баксаң, бу сыйфатлар
күбебездә бик тә чамалы!..

Ике-өч шигырь, берәр көй язып,
«бөекләнеп» йөргәннәр юкмы?
Бахус* бабайга бөтен саулыгын,
бар талантын биргәннәр юкмы?
Башны текә тотасы урында,
сәбәпсез иелгәннәр юкмы?
Теләсә нинди боерык алдында
тезләнеп биегәннәр юкмы?
Сәгать саен фикерен үзгәртеп,
мөлкәткә тиенгәннәр юкмы?
...Халкыбызның борынгыдан килгән
затлылыгын онытыйкмы?

Халык бердәм булып үз итүе —
Бөеклекнең анык билгесе.
Интеллигентлык, затлылык дисәк,
Сәйдәш аның күркәм өлгесе!

---

* Бахус — (Вакхъ Діонисъ) — борынгы грекларда табигатькә көч бирүче дымлылык, өлешчә — шәраб алласы. Беренче булып йөзем үстергән һәм аңардан шәраб әзерләгән.

## 14. Идел буйларында чирәмлек...

*Без кабызган утлар сүнмәс алар,*
*Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә!*

Кәрим Тинчурин

«Кызыл байрак» — җанга якын авыл.
Хыялланыр өчен җай авыл.
Идел кырыенда балкып торган
татар авылы тагын кайда ул!
Рәхмәт инде нарком заманына —
хөрриятнең аңлап мәгънәсен,
кайтарткан ул монда элек куылган
бер-ике дистә татар гаиләсен.

Ә җәйләрен Сәйдәш шунда хәзер.
Иҗат итә, шунда ял итә.
Үзеңне бер Җир баласы итеп
тою шатлыгына ни җитә!

Уйландыра Идел, уйландыра.
Дулкыннары бәрелә күңелгә.
Әрнетә дә: алтын, көчле чаклар
офыкларга кереп күмелгән...
Салмак аккан шул салларга карап,
елыйсылар килә кайчакта!
Язмыш миңа мәрхәмәтле булды,
рәхимсез дә булды бер яктан...
Идел өсләрендә, бу биектә,
сөртмәсәң дә, яшең тиз кибә.
Күпме булды, кәгазьләргә төшми,
җилләр алып киткән ул көйләр!
Кылган эшемә дә, кешеләр күк,
сак-бөртекчән була алмадым...
Мирас туплап барылынмады,
күпме кирәк нәрсә югалды!..

Җанны савыктырыр еллар килде.
Җылы якка борылды дөньялар.
Җирдә гаделлекләр арткан саен,
Матуррак җырлар туалар.
Арабызга кайтты Тинчуриннар,
Ибраһимовлар, Җәлилләр...
Татар шагыйренең шигырьләрен
таңга калып сөйли күп илләр.

Уйландыра Идел, уйландыра.
Бу дулкыннар кая ашыга?
Төрле-төрле уйлар килә икән
иллене узган ирнең башына!
Иллене узу — инде ил узу ул,
борылып карау — ярый үткәнгә.
Нинди игелекле хезмәтең бар
билге итәрлек яшәп киткәнгә?
Булган икән яктырак гомернең
яшьлек ягындагы өлеше.
Финал өчен яңгырарлык булган
иҗатымның башы, кереше.
Яулар истәлеге булды бугай
«Совет Армиясе маршы».
Әйтте күпләр: сугыш вакытында
ул калалар йөргән алышып.
Әле дә якын «Галиябану»,
«Наемщик»ка язган көйләр дә.
Бүләк сәгать, шинель белән йөргән
чаклар калды сагынып сөйләргә!

Уйландыра Идел. Уй — киңәя.
Тиздән Идел үзе киңәер...
Егетләрчә эшләп чыга алдыммы
музыкада үземә тигәнне?
Заманына күрә оркестрлар
оештырдык. Шунда уйнадык.

Халыкны без бераз симфониягә
күнектерәбез дип юандык.
Спектакльләргә көйләр язып,
җыр-биюне түргә менгездек.
Әкеренләп шулай төзелде бит
балет-опералар нигезе.
Без башладык кына... Алга таба
олы юлга бүтәннәр чыгар.
Бу мәңгелек хәят күчешендә
Сәнгать — диңгез, без — тик тамчылар...

...Сузып кычкыртты да ак пароход,
уе, ахры, калды бүленеп.
Ерак уйлар эреп таралуга,
яңалары килә өерелеп.
Исәп тә күп. Эш тә. Бу арада
«Җырларым»ны* язып бетерәсе.
Алабуга институт ачкан,
чакыралар, килә күрәсе.
Сабан туе көнне ял паркында
оркестрлап концерт бирәсе...

Беркем сизми әле, Әҗәл угын
төбәгәнен Аңа каратып.
Иреннәргә килә актыккы җыр...
Якынлаша соңгы пароход...

## 15. Сискәнү

*Бармыни бездә гомумән чын кеше*
*кадерен белү?*
*Без аны кайдан белик, мискин үлеп*
*аңлатмагач?!*

Габдулла Тукай

Әй, декабрь! Егерменче көнең.
Күңелдә боз. Күздә — кайнар яшь.

* «Җырларым» – С.Сәйдәшевнең М.Җәлил сүзләренә язган соңгы җыры.

Меңәүләрнең телләрендә бер сүз:
«Сәйдәш...
Сәйдәш...
Сәйдәш...»
Әй, декабрь! Син тудырып аны,
Бүләк иткән идең Иленә.
Кайчан гына... Инде мәңгелеккә
алып китәргә дип килдең дә...

Урам тулы халык. Балконнарда,
түбәләрдә, тәрәзәләрдә...
Мондый хәлне Казан моңарчы бер
күргән булган Тукай үлгәндә.
Холкыбызмы шундый: без, эш узгач,
әй үксибез, тәүбә иткәндәй.
Ә эчебез поша исән чакта
бирәребез гөрләп үскәнгә...
Язмыштырмы безнең, ялгыштырмы —
Үлемсезлеккә дә юл башка.
Тарихларга кереп калыйм дисәң,
үлеп күрсәт, корбан бул башта!

...Агайлар да килгән авыллардан
үрәчәле чаналар белән.
Озатырга чыккан чал әбиләр
оныклары — сабыйлар белән.
Бәгырьләрне кисә «Сакай маршы!»
Мәрсияләр — алар гомерле...
Сирәктер ул, ак чәчәкләр белән,
үз көйләрең белән күмелү.
Саубуллаша халык... Керсәң иде
һәрберсенең гаме-уена!
Нинди хисләр, сүзләр юктыр! Җыйсаң —
үзе булыр иде поэма!
Шагыйрь уйлый: «Күзем бәйле килеш,
дөнья читләрендә адашсам,
Туган илемне мин табар идем
Сәйдәш көйләренең моңы аша!»

Уйлый галим: «Сәйдәш иҗатының
сихри көче нидә дигәндә —
якты дәрте, хәтта моңы белән
ул яшәргә өнди, җиңәргә!»
Агайларның сүзләр — күзләрендә:
«Ул безнеке иде, үз иде!..»
Әнә шулай илне тетрәтә
бер зур рухи чылбыр өзелү!
...Туфрагына беркөн кайта адәм.
Әҗәл хәлләренә юк дәва.
Җирдә берни булмагандай, Күктән
күбәләктәй ап-ак кар ява...

**Эпилог**

Җан күбәләк булып кайта, диләр.
Үтермәгез күбәләкләрне!
Күңелләрдән шәфәкъларга кадәр
югалтулардан соң, җан әрни...
Күпме бездә эзсез югалганнар!
Карт хәтергә булмый ышанып.
Таш торгызу кирәк. Байтак тиеш
һәйкәлләрнең урыны буш әле.
Безнең әле байтак бөекләргә
күңелләрдә генә музейлар.
Битарафлык, яман чир шикелле,
чыгар ул бер, узгач күп еллар...
Табигатьтә бушлык булмас, диләр.
Берәү килә, берәү югала...
Халкы эше өчен янган гына
мәңге яшәр булып кала ала.
Һәлакәткә әзер талантлыда —
үз халкының рухи җегәре!
Аның җаны аша күреп була
үткәнне һәм килер көннәрне.
Талантлар китсә, әй ишәя
конъюнктура сандугачлары!

Аларның шәп эшли унисонга
ашказаны белән башлары!
Рухи дөньяга килеп торса
кайтышлар һәм сәләтсезрәкләр,
юклыкларын тоеп даһиларның
илләр буйлап әрнер йөрәкләр...

Һәрбер әрсез көчле булмаган күк,
һәр мескенлек түгел тыйнаклык.
Килер көннәр әйтер — кемнәрдә
фидакярлек, ныклык, йөз аклык!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Йомшаклык белән генә булмый.
Көчле һәм нык булыгыз, талантлар!
Тарихыбыз шундый, заманасы...
Иманыңны бүтән кем саклар?

...Ялгышларны — була, мәнсезлекне...
тууларны булмый кабатлап!
Җырчыларны булмый кабатлап!
Даһиларны булмый кабатлап!

Сәйдәш язмышы —
гыйбрәт тә,
горурлык та,
алыр сабак та!
Нечкә җаннар —
талантлар белән
сак булыгыз, дигән набат та!

*1978 – 1980*
*Пицунда – Казан*

## ҖИР ТУРЫНДА ЕРТЫК ҖЫР

*Җир кемнеке булса,*
*Җил — шуныкы...*

Кырылышып җир бүләләр,
сутыйлап та, илләп тә.
Сугышып та, димләп тә...

Җир бүләләр! Җир бүләләр!
Кемнәр көчле — шул ала.
Гомер бакый һаман Сине
Бүлгәлиләр, Җир-Ана.
Юккамыни әйләнгәнсең
иманнан иманага...
Сәясәт, Җир сөрмәсә дә,
сөргәндәй булып бара.
Вазгыятькә, декретларсыз,
бүгенге көннән кара.

Берсе әйтә: «Мин — фермер!» — ди,
Икенчесе: «Мин — варис!
Тарихта гел сәрмаяле
Җиргә хуҗа булган иң!»

Өченчесе: «Безгә кулай
Күмәк хуҗалык кына.
Эш майтара ала бездә
көтүдәй халык кына!»

Бәхәс бара: Җир кемнеке?
Минеке дә минеке!
Чынлап эшкәртергә булса —
Хуҗа Насретдиннеке,
Йә эшче көч җитеп бетми,
йә булмаса — техника...

Берәүләр шаулап йөргәндә,
берәүләр алып куя.
Алып куя да кишәрлек
(кесәгә салып куя),
зур сарай салып куя.
Коймасына чәнечкеле
чыбыклар сарып куя.

... Монсы бездә.
Ә, гомумән,
Һәр кыйтгада — Фәләстыйн!
Меридианнар, параллельләр...
Кем түбән дә, кем өстен?
Океан төпләренә төшеп,
Бүлмәкчеләр Җир өстен.

Һаман кыйммәтләнә бара
Кояш төшкән һәр карыш.
Ике аяклы адәм саны
дистә миллиардка барыш.

Уйласаң, басып йөрибез
кемнәрнеңдер күзенә!
Тере матдә меңәр гасыр
сибелгән Җир йөзенә.

Җирдән күтәрелгән җаннар
кая китсен?
— Җиренә!
Кавемнәре яткан туфрак
әверелә Иленә.

Болынлыкмы, ком-сахрамы,
тау-ташлыкмы, басумы? —
ни булса да, хакыйкать бер:
Җир — Ватанның асылы.

Халык тарих яза шунда,
яза җырын, дастанын...
Туган җирдән дә кадерле
бер нәрсәсе юк аның!

... И газиз Җир! И изге Җир!
Бездә ник чын хуҗа юк?!
Төп варисның — хокукы юк,
килмешәкнең — нужа юк.

Елап яткан җирләр күпме
Рәсәй киңлекләрендә!
Импер күз һаман төбәлгән
чит ил җимлекләренә.

Җиребезне сырып алган
баскын канлы дүңдәләк.
Аның ашказаны тулса,
бар дөньясы — түгәрәк!

Һаман җитми Планетаның
алтынчы өлеше дә...
Кайчан бу илне гөлбакча
ясарга керешерләр?

Ни уйлыйдыр безнең хакта
«тәлинкә»дә төшкәннәр?
Киләчәктә ни буласын
юк һичкемнең чишкәне...

Әй, Җир-Ана! Кемне генә
җанлы, тәнле итмәдең!
Юмарт бирдең Яманга да,
Изгегә дә икмәгең.

Галактика киңлегендә
кемнәрнеңдер Күге Син!
Барыбызныкы булсаң да,
беркемнеке түгел Син!

Әй, газиз Җир!
Гамәли әйләнешеңдә
ярылмый түзче инде!
... Бу ялваруны, ишетсә,
бер Аллаһ үзе инде...

*1995*
*Казан*

## КАРТ ҺӘМ ШАГЫЙРЬ

### Шагыйрь

Дөнья буйлап киләм.
Байлыгым, тәҗрибәм юк,
риям, мәкерем, хәйләм юк,
тик гаҗәпләнә беләм!
Гаҗәпләнеп нәфрәтләнәм,
гаҗәпләнеп сөенәм!
Миңа өр-яңа җиһан бу!
Төсләр, әйбер төрлелеге
күзләрне камаштыргач,
кеше күңеле хәлләренә
ис китеп карап торгач,
үземдә, кош баласыдай,
очар сүзләрне тоеп,
җаннары теләгән якка
аларга ирек куеп, —
очырам да, вөҗүдемдә
иң бөек ләззәт тоеп,
көләм йә елыйм сулыгып...

### Карт

Көлү — көлү, елау — елау,
елан да елый, диләр.
Мәгънәсез елаган — мескен,
мәгънәсез көлгән — юләр.
Максатсыз черки дә очмый,
син сүзләр очырасың.
Йә бәхетең ташый синең,
йә сызып ачынасың.
Хикмәте ни?

## Шагыйрь

Чолгамыйча туры әйтәм:
бәхетем ташкан түгел.
Хәтта тулы бәхет миңа
кирәк тә түгел бүген!
Иртәгегә калсын...
Ә бүген?
Бүген көрәшәбез әле!
Җирнең пакьлеге өчен,
илнең аклыгы өчен!
Киткән зиһен, киткән көчнең
кайткан чагылышы итеп
күрәсе килә матурны,
күрәсе килә акны,
чумрасы килә шатлыкны
күзләргә сыйган чаклы
Күрәсе килә кешене,
хыялдагы кебекне,
җирне күркәмлисе килә,
очырасы килә чүпне,
хәвефсез һәм чиста итеп
саклыйсы килә күкне.
Һаваны сулап туймаслык
гел саф итәсе килә,
шартлылыкларны бетереп,
чын иреклелек тоеп,
җирне үзеңнеке итеп,
бәйрәм итәсе килә!
Тормышны күбрәк ямьләп
яшәп китәсе килә!

## Карт

Кем теләми саф һаваны?
Кем теләми пакь җирне?
Шагыйрем, хисеңне тый да,
чак кына тыңла мине!
Җир үзе ничә катлыдыр,
әмма тормыш — катлырак.
Берзаман сабый акылың
калыр әле аптырап.
Шавың кимер, кыйблаң авар,
дөнья үзен төшендергәч.
Аллалар да котсыз кала,
аслынача чишендергәч.
Белеп тор, бу Җир бик иске,
мәхәббәтләре иске,
бар гадәтләре иске —
бик күп нәрсә бүлгәләнгән:
«безнеке һәм сезнеке».
Кем гайрәтле — шул югары,
кем өлгер — юл яра алдан.
Бар да омтыла. Берәү дә
чүбектән яралмаган!
Кояшны әле керфеккә,
әле тезләргә төшерү,
бәлки, кыендыр...
Тик авыррак
икмәкне Тәңре-җирдән
иренгәчә менгерү!
Син әйтәсең — көрәш, дисең,
ә соң нәрсә ул көрәш?
Тәнең өчен, җаның өчен
дөнья куу — шул көрәш!

## Шагыйрь

Бар дөньяны учлый алмый
салкын, хисапчан акыл.
Яши бит фанатиклар да,
Аллага шөкер, акын!

Миңа кирәкми сарайлар,
мәрҗән, энҗе, асыллар.
Рухым ирешкән хакыйкать
өстен, бөек барсыннан!
Булса ирек, булса җирлек,
ипи-тоз бераз гына,
язармын, бер дә басмамын
талантым бугазына!
Көрәшем менә шул минем!

## Карт

Рухың нык булу һәйбәт ул,
иҗтиһад итү яхшы.
Хәтереңә зыян килмәс,
шуны да онытмачы:
хезмәтлене олыласак та,
әле дә каберсезләр бар.
Ми кипкәнче хезмәт итеп,
исме кадерсезләр бар.
Шаулау нигә? Малайлык ул —
камыр кыңгырау кагу.
Кыңгырауламасаң да тормыш
ай-яй-яй гына ару!

Кирәк-кирәкмәскә көю,
ачыну һәм лаф ору
нигә кирәк? Үзе сәнгать —
эндәшмичә шым тору.
Мәҗнүн, бәлки, мәңгелектер,
кеше гомере бер саплам.
Кеше әүвәл — тән иясе,
яман күзләрдән саклан!

**Шагыйрь**

Саклан, дисең. Соң нәрсәдән?
Үземнең хаклыгымнанмы?
Күп күргән күзләремнәнме?
Намусым аклыгыннанмы?
Әллә халкым моң-хәсрәтен
тыңлап көенүдәнме?
Илнең якты йөзен күреп,
нарасый сөенүдәнме?
Саклан, дисең... Ә соң нидән?
Беләм кечкенәлегемне дә,
Җирнең зур икәнен дә,
тормыш-кунактан кайткач мин,
күзәнәк — Җир тәнендә...
Беләм, һәммә нәрсә үлә,
каберләр генә үлми.
Тираннар, патшалар үлә,
шагыйрьләр генә үлми!
Әгәр җирдә алдан ук мин
бәямне белеп торсам,
мәгънәсезлек дулкынында
буш гомер сөрер булсам, —
китәм...

Гадәтләрен ташлап китәм,
мәхәббәтен, икмәген...
Әгәр Кояш күпсенмәсә,
чын кешеләр чит итмәсә,
тормыштан тиз китмәмен!

## Карт

Егет! Бераз сабыйрак син:
күзләрең, сүзләрең дә.
Тарих — ерак, хаклык — тирән
яшәеш үзәнендә.
Еллар, чорлар катлаулы ул,
тарих үзе сиртмәле.
Бу дөньяда кемнәр булып,
кемнәр генә китмәде!
Әй, ул туры акыл белән
мәйданга килүчеләр!
Мин моны болай эшлим, дип
лаф орып йөрүчеләр!
Шул янып йөрүче йөздән
туксан тугызы кимендә
мәңгелеккә мәйдан тапты
Билгесезлек Илендә.
Кабер, кабер, кабер, кабер,
кабер — кая карама.
Кайсысында әрем үсә,
кайсысында — карама.
Юк анда һава, җил, яңгыр,
хәрәкәт, бушлык, төс, тәм.
Барыбер — яшен үтсә дә,
буран үтсә дә өстән.
Сулыйсың икән, тормышның
көй-серен өйрән Җирдә.
Табигать, бәхеттән җан биргәч,
озак яшәмәскә нигә?

## Шагыйрь

Яныйсың да үлем белән,
озын гомер димлисең.
Тик аны ник һәм кем өчен
яшисең соң, димисең?
Минем тормыш нәрсә соң ул?
Бар дөнья ал да гөл, дип,
мәнсез мыгырданумы?
Чак хаксызлык күрүгә дә
ачынып, гел янумы?
Әллә «җир-суны яндырып
һәм күкләрне ватумы»?*
Боекса, бөек халкымның
күңелен юатумы?..
Син әйтәсең — яшә, дисең,
озын гомер димлисең,
тик аны ник һәм кем өчен
яшисең соң, димисең.
Уйламыйсыңдыр үлемнең
бик үк начар түгелен:
китер, хәзер кабул итәм
Үлемсезлек үлемен!

## Карт

Гаҗәпләнәм: шагыйрьләргә
Иблистә дә булмый торган
көч килә әллә кайдан?
Үлемнән дә чирканмагач,
әйдә, йөр, шамакайлан!

---

* С.Рәмиевнең «Дөньяга» шигыреннән алынган юллар.

## Шагыйрь

Әйе, йөрим, гизәм, көләм...
Тир түмен тойган халыктан
хикмәтле сүзләр сөзәм,
күңелемдә кайнатам да
аларга тылсым өрәм,
мәхәббәттән йә нәфрәттән
күңелдә таулар өям,
кара савытымдагы айга
мәдхия язып бирәм,
сейфлар да ишетерлек
мәзәкләр сөйлим, көләм...

Дөнья буйлап киләм!

*1966*
*Казан*

## ИКЕ ЗИРАТ АРАСЫ...

*(Җилләр сагышында — интер уй)*

*Сугыш салган күкәй...*

Ги де Мопассан

### I

Арчалардан чыгып, бераз киткәч,
зират кала олы юл буйлап.
Нимес зираты ул... Төрле кеше
үтә булыр төрле уй уйлап.

Кайберәүләр нәфрәтләнеп уза:
сезгә монда бер уч җир әрәм!
Жәлләүчеләр була: нинди генә
язмышларга тармый Җирдә адәм!

Казансуга килеп баш салганнар
Алманнарда үскән ир-атлар.
Әсир төшкән алар — заманында
безгә каршы чыккан солдатлар.

Әтиләребезгә атучылар
булганнардыр араларында.
Китерүче бардыр ятимлекне
шушы якның балаларына.

...Арчаларда нимес әсирләрен
хәтерлиләр әле хәзер дә.
Йөргән алар монда сак астында
таш чыгарып, утын әзерләп...

Яшәгәннәр алар шул заманның
кырыс кануннары буенча.
Корбаннары булган... Хәер, ул вакытта
гадәти хәл һәр өй борынча...

Илләр тынычлангач, исәннәрен
җибәргәннәр туган иленә.
Ә байтагы мәңгелеккә калган
Казан арты — Арча җирендә.

Үскәннәрдер, бәлкем, аларның да
Алманнарда онык-торыны.
Адәм баласына мәгълүм түгел
соңгы туктар чикнең урыны...

Каберләре калган безнең җирдә
ят утрау булып яланда.
Тупыллары җилдә шомлы шаулый,
авыр хәтер булып заманга.

## II

Арчалардан Әтнәләргә таба —
юлың төшсә Олы Мәңгәргә,
зиратына кереп баш иеп чык,
гыйбрәт өчен, вакыт җәлләмә.

Бер кырыйда гына — ерак түгел
ярымайлы чардуганнардан —
каберләр бар. Яссы ташларына
ят исемнәр язып куйганнар.

Вакыйга шул: сугыш вакытында
вагон-вагон нарасыйларны —
латыш балаларын китергәннәр,
үткәнче дип афәт сынавы.

Авыл халкы ятим сабыйларга
күрсәтсә дә хәлчә бар дикъкать,
аларны да чапкан аямыйча
Әҗәл дигән ачы хакыйкать.

Ханнар дәфенләнгән бу якларда
ята Янис, Дайна, Гунарлар...
Зыкы суыкларда җилләргә дә
бәсле киртә уртак — кунарга...

...Кайсына — биш, ә кайсына — алты,
сирәкләре — мәктәп яшендә...
Шушы туфрак сабыйларның күпме
хыял-өметләрен яшергән!

Үлән белән каплап, тирән йоткан
мәңгелеккә, кайтмаслык итеп.
Фани дөнья яшәеше шундый:
кайгы — бөтен, шатлыклар — китек...

Ерак латыш җирләрендә кайчак
бәйгеләрдә көчләр ким булса,
гәрәбәләр бераз тоныграк,
чәчәкләрдә төсләр ким булса,
ятим хуторларның тәрәзеннән
хуҗа күләгәсе үтмәсә,
күмәк җыр бәйрәме сафларында
берәр кирәк аваз җитмәсә —
алар шушы кабер эчләрендә,
шушы туфракта һәммәсе.
Халыкның бар көче, кайтмас төсе,
югалтылган моңы, шәүләсе...

## III

Менә шулай: ике каберстан
Казан арты туфрагында.
Берсен латыш халкы белә булыр,
үзенекен — нимес ягы да...

Чит-ят җирдәге һәр ятим кабер —
һәр халыкка үзгә бер яра.
Миңа калса, кайчак ул каберләр
сөйләшәдер кебек үзара.

* * *

Нәни әрвахлармы оран сала:
— Ник без монда? Сезме гаепле?
Нимес каберләре дәшми сыман,
«юк» диеп тә, яки «җә» дип тә.

— Әйлән-бәйлән уены түгел икән
Газраилнең үлем уены...
Исән чакта «Җир! Җир!!» дидегез сез,
тар түгелме кабер куены?

Янә эндәшмиләр...
«Ни диясең,
ни әйтәсең нарасыйларга?
Үзебезнең монда калуларны
акылыбыз җитми аңларга...»

— Кемнәр җиңде, әй, сез хөкемдарлар,
без катнашкан бәйсез сугышта?

«Мәгънәсезлек җиңде!» Җилләр әйтә:
барсы өчен тоташ сулыштан.

— Киләләрме Сезне яд итәргә?
— Булгалады уллар, оныклар...
— Сезнекеләр?
— Каян булсын! Без бит
сабый килеш ятим сыныклар.

Ә ...хәтердә
килеп киттеләр шул бер елны
карт кешеләр. Ә без танымадык.
«Яшьтәш идек» диләр, елыйлар.

* * *

Әй, укучым! Болар шигъри фараз,
мин чарасыз гади бер бәндә.
Яшәү-Үлем кемне уйландырмас
фани дөнья кичеп килгәндә.
Дәвамчылар булып канат-уллар,
онykларың үсеп килгәндә.

Ә кем белә, бу кыйссада язган
әрвахлар, бәлки, күктәдер?
Галәм киңлегендә йолдыз булып
кайлардандыр җавап көтәдер?

* * *

Казан артындагы ике зират.
Ә андыйлар җирдә бихисап.
Саный китсәң, Әлмисактан бирле
кәгаземә булыр бик кысан.

Һаман арта бара... Үзе гыйбрәт
чичән халкындагы яралар!
«Бүленмәслек «бәхет» диеп анда
хәтта балаларны чалалар!..

Сабыйлары белән күзалла син,
фаҗигасен балкар, көрдләрнең,
Кырым туганнарның, калмыкларның...
тагын дистәләгән күпләрнең.

Хәер, әле империяләрнең дә
үзләрендә күпме үксезләр!
Ач балалар күз яшендә күперә
яңа байлар дигән сөнсезләр.

Сабый жаны кыелып Өмет үлә,
шомнар иңә туар таңнарга.
Өлкән дигәннәргә әллә вакыт,
әллә акыл җитми аңларга...

...Сабыйларның җаны юкка чыкмас —
тупланадыр алар көч булып.
Кешелекне мордар сурәтендә
үзен һәлак итәр Үч булып.

Бәлки, көтәләрдер яңа көчләр —
шәһит киткәннәрнең рух-җанын?

Күкләр белә: Җирдә кылынганның
берние дә югалмаганын...
Көтмәгәндә Илаһ нәгъръә орса —
сынау тотар Җирнең Үзаңы!
...Тик ул заман булмас сурәтләүче
Кыямәт дигән Ахыр Заманны.

P. S. Җанның җаннан аерылуы
туу булыр — Яшәү яшене!
Нинди язмыш кичерсә дә кеше,
Үз Җирендә булсын җәсәде.

Арча аша Кырлай юлларында
бөреләнгән уйлы хисләр бу.
Милләттәшем, Туган җиребездә
бердәм булып яшик! Исән бул!

*1996—2005*

## ИҖАТ

### I

Чибәрлек биреп сынады,
саулык биреп сынады...
Дөнья малын өеп биреп,
байлык белән сынады.
Дәрәҗәләргә менгезеп,
дуслар белән сынады...
Яраткан бәндәсе булып,
тәртипле яшәде Кеше,
сынауларда сынмады...

Разый булып әйтте Тәңре:
«Рәхмәтле җан! — чыдады.
Соң кат сынап, Иҗат утын
салып карыйм җанына?
Сынатмаса, изге булып,
иңәр, бәлки, янымa?
Әйдә, иҗат итеп кара! —
илһамлан иманыңда!»

### II

«Чү, ни булды? Йә, бу нәрсә?
Нишлисең син, әй, Кешем?
Мантыйкка сыймый кылганың,
һич аңлашылмый эшең?
«Кеше — бөек! Кеше — даһи!
Эше мәңгелек!» имеш.
Ничек телләрең әйләнә
ихтыярсыз кол килеш?
Нишләвең бу? Әллә инде
Асылыңны оныттың?
«Мин — Табигать таҗы!» дигән
вәсвәсәгә юлыктың?»

## III

...Ә ул шашып иҗат итә!
Илһам дигән очкын төшеп,
бар вөҗүден ут алган!
Хөр фикерләр ташкыныннан
чикләр-бикләр югалган!
Яза, сыза, шигырь көйли,
шигарь белән эндәшә,
мәйданнарга кешеләргә
сүздән ялкын өләшә!
Әйткәненнән — бүтәннәргә
нурлар иңә бөркелеп.
«Кеше җаны мәңгелек!
Иҗат рухы мәңгелек!»
Ә ул шашып иҗат итә
бер егълап, бер көлеп.

Әллә тиле? Әллә иблис?
Әллә шагыйрь? Әллә кем?..
Вә ләкин...

## IV

Әйтте Тәңре: «Ялгыштым шул,
хәзер менә бел инде!
Иҗат утына чорналган
бу бәндәне күр инде!
Бөек Канунга карышып,
үз хөкемен үзе язган
Аллага әверелде!
Тәүбәгә килә алырлык
акыл да җыя алмый.
Үз-үзенә мәдхия укып,
«Мин — мәңге!» дип тәкрарлый;
мин аны чын Адәм заты
итмәкче идем, бакчы! —

ижат итеп, Дөньялыкта
бакый булып калмакчы!
Әй, Адәм!
Ни чәчсәң — шуны урырсың,
өлешең калмас миннән.
«Сөю көчле иманнан!» —
дигәнең өчен, тигәнчә
әҗер сиңа, бүгеннән!
Әкеренләп чирләр биреп,
«картлык» дигән «шифа» биреп,
Вакытта элеп киптерәм! —
Кануннардан чыккан өчен...»

## V

...Утыра ул. Бөкере. Карт.
Тире, сөяк, күз генә...
Бу кайсы заман икәнен
әйтә алмас сүз генә...
«Заман кемнең заманы»мы?
Булган аның заманы!
Ничек заманы булмасын —
үзгәртә алгач ил аңын!
Хезмәте — данга уралган,
яшәве — алкышланган.
Сөйгән, сөелгән, янган...
Алыр тиешен алган.
Тик менә... саулык кына...
Күз яшен сөртеп торырга
кулында яулык кына...

## VI

Әйтте Тәңре:
«Тынычлануыңмы?
җиттеңме инде чигеңә?

Өмет тоткан идең бугай
Тәкъдиреңне җиңәргә...
Адәм затлар, белегез сез —
Вакыт дигән богауда.
Сезнең язмыш — сәҗдә кылып,
күнеп яшәү дөньяда!»

## VII

Таңга каршы яшь бер егет
җыр яза илһамланып!
Хисләре нечкә булса да,
сизә үзен, гүя — Алып.
«Бөек җыр тудырдым!» — ди ул.
Мондый җырсыз моңа кадәр
кешеләр ничек торган?
Әйтерсең җирдә тәүге кат
Мәхәббәт яратыла!

...Кем бу егет? Түгелме соң
әлеге картның яшь чагы?
Рухының шашынган чагы,
хисләренең яз чагы?

Илһамда янган һәр кеше
иҗатчы санала ала.
Юккамы патшалар, көнләп,
Шагыйрьгә канығалар!..

Сүзләрдән һәйкәл коямы,
көй чыгарамы — сайлап
авазларның яңасын,
салкын ташларны терелтеп,
әвәлиме яңа сын —
Иҗат итү — кешенең бөек халәте —
Рухының тантанасы!

Тарих таный — иҗатына
җаннарын салганнарны,
максат-идеалы өчен
фидаи янганнарны,
үзләренчә үзгә дөнья
тудыра алганнары!

Тән-кабыгыннан котылгач,
җан кая китә дисез?
Иҗатта кала. Шуңа да,
Кеше җаны белән бергә
бөек иҗат үлемсез!

## VIII

Тәңредән килгәнме бу өн?
Искәртә, әллә яный?
«Без яраткан Дөньядан тыш,
бүтән дөнья була алмый!
Була
        алмый!»

---

...Бер яшь егет шигырь яза!
Күңелендә — мәңге яшәү,
йөзләрендә — таң нуры!

*2000 — 2004*
*Казан*

## ЭЧТӘЛЕК


Елан тавыннан карадым... 7
Туган йортта 8
Бер чардуган янында 9
Учак янында 10
Туган өйдә күргән төш 11
Тугансың икән... 11
Ялган 12
«Җирдә байлык артмый, кимеми дә...» 13
Искә төшерде әтәч авазы... 14
Ялгызлык 15
Кызыгу 16
...Ул — син! 17
Туган халкым 18
Җырла син! 19
Җигә алсаң... 20
Исеңдәме? 21
Якты йолдыз белән чибәр күл 23
Кышкы авылдан бер сурәт 25
«Вакыт өчен нәрсә Адәм гаме!..» 26
Ышаныч 27
Тордым басып Кама ярында 28
«Хуш!» дип әйтмим, «Сау бул!» дим...» 31
Өмет 32
Кичер кайта алмавымны!.. 33
Сиңа 34
«Элегрәк әби-бабай сәҗдә киткән...» 35
Чиләбе. Төн. Вокзал. Күпердә 36
Авыл идиллиясе 38
Мунча яга аналар... 40
Сиздерми калмас!.. 42
Алма һәм корт 43
Офыктагы юл өстеннән агылалар болытлар... 44
Читкә китүчеләргә 46
Безнең Алсу 48
«Яшәү ул — һәр күзәнәкнең...» 49
Төнге күктә кыр казлары өне 50
Карама! 51
Таныйм да, танымыйм да... 52

«Җанын талкып, артык йөдәтмә син...» ........ 53
Япь-яшь килеш сәрхуш булган таныш түгел берәүгә ........ 54
Хатирә ........ 55
«Язуларга теркәлмәгән сүзләр күпме!..» ........ 56
Самолетта очканда ........ 57
Сиңа ........ 58
Кичке моңсу бер күренеш ........ 58
Каскадер ........ 59
Кошларымны көтәм ........ 60
Яра булып калган хатирә ........ 61
Туган тел турында бер шигырь ........ 62
Ялгыша дип уйла мине... ........ 63
Кеше-хуҗа ни уйлый? ........ 64
Яшьлегемнең көмеш бер киче ........ 66
Җәйге яңгырдан соң Иделдә ........ 68
Яшәү бит үзе бер бәйрәм лә! ........ 70
«Тау өстеннән — йолдызлар да якын...» ........ 71
Эльбруста исем турында уйлану ........ 72
Саумы, таулар! ........ 73
Тау — шул ук җир... ........ 74
Бер эресәң, тамарсың... ........ 74
Гел генә иман яңартып дөньяны каргаучыга ........ 76
Бернәрсә дә янә кабатланмый ........ 77
«Яманлыкны...» ........ 78
«Яфраклар лепердәшә...» ........ 78
«Аягүрә йоклап йөрсәң...» ........ 80
Чормада ........ 80
Үземне юатам... ........ 81
Төнге уй ........ 81
Кайсын пигы итәгендә ........ 82
Уйның ике сурәте ........ 84
Борчылуда туган ышаныч ........ 85
«Кулы — эштә. Җаны — утта...» ........ 88
Җан көеге ........ 88
Мин яшәдем! ........ 90
Төнге сәгать тавышы ........ 91
Сентенцияләрдән ........ 92
Укыдым да танышым китабын... ........ 93
«Кызыл әтәч» ........ 94
Кичке Эльбрус ........ 95
Язгы кар суларында ........ 95
Алтын капка! Алтын капка! ........ 96
Елан кабыгы ........ 97
Инде мин дә: «Яшәмәдем», — дисәм... ........ 99
«Шатлыктан да, хәсрәттән дә...» ........ 100
Булса икән ул!... ........ 101

Тансык төшләр ........................................................ 102
«Ятып үлгәнче, йөреп үл...» ........................................................ 103
Туган якта ........................................................ 103
Җәйге төннең бер бәләкәй вакыйгасы ........................................................ 104
Казансуда боз кату ........................................................ 105
Төнге учак янында ........................................................ 107
«Сине күрә алмаган һәр көн...» ........................................................ 107
Асрау ........................................................ 108
Катаклизм ........................................................ 109
Язлар килә... ........................................................ 110
Тау һәм үзән ........................................................ 111
Очраштык кеше туенда... ........................................................ 113
Көз — көз инде... ........................................................ 113
Халәт ........................................................ 114
Юкә чәчәге җыйганнар... ........................................................ 116
«Санамагыз киткән торналарны!..» ........................................................ 117
Ау сезоны ачылгач ........................................................ 117
Тәрәзәдән бер күренеш ........................................................ 118
«Шигырьне укымыйлар...» дип...» ........................................................ 118
«Татарстан — Төтенстан...» ........................................................ 119
«Туган якта күпме атамалар!..» ........................................................ 120
Читтән кайткан карт сораша авылдаш кордашыннан ........................................................ 121
Казан Кремле янында сүзсез тордык без бер Җәлилче ветеран белән 122
«Язмыш» дигән алмагачтан... ........................................................ 123
Син дә бер кояшы дөньяның! ........................................................ 124
Шундый чак... ........................................................ 124
Язмыш торса да өстән ........................................................ 125
Көньяктагы рәсемең ........................................................ 126
Әлмәттә җир тетрәү ........................................................ 126
Үткәннәр — бүгеннең башы ........................................................ 128
Туган якка кайткач ........................................................ 129
«Яшәдең, эшләп җан аттың...» ........................................................ 129
«Заманында манаралар кистереп йөргән...» ........................................................ 130
Сальвадор Дали үлеменә ........................................................ 130
Эз ........................................................ 133
Метаморфоза ........................................................ 134
«Тамчыда да...» ........................................................ 135
Топонимик мозаика ........................................................ 136
90° ........................................................ 138
«Дүрт кылым бар иде Сазымда...» ........................................................ 139
Биеклек ........................................................ 140
«Яшь вакытта — көчле чакта...» ........................................................ 141
«Кирәктер карау да...» ........................................................ 142
Рәсем ........................................................ 143
Борчылма! ........................................................ 145
Үкенеч ........................................................ 146
«Ил хәлен беләсең килсә...» ........................................................ 146
«Зәңгәр күктә бер ак болыт...» ........................................................ 147

Шагыйрь булсаң... 148
Гомер — очкын... 148
Арканланган ат янып үтә идем... 149
Язгы бер тойгы 150
Сорау 150
«Бер-беребезгә артык якынлашмыйк!..» 151
«Элеп киптер мине кер итеп...» 152
Казан алды 153
Күренеш 157
«Язмышымда упкынмы син?..» 157
«Күчә чирләр. Күчә илләр...» 158
Бер агай сүзләре 158
Җаны көйгән Акбай турында 159
Әни ишетми калган җыр 160
«Үзем эшафот та...» 161
Сау чакта яки «шул» хакта 161
«Озак эзләдемме мин сине?..» 163
«Соравыма бик еш, тапкыр итеп...» 165
Ул камышлар... 166
«Байлыгыңны кочаклап ят...» 167
Парадокс 168
«Тапканга артык сөенмим...» 169
«Качар җир — убежищелар...» 169
«Көтмәдекме безне баскан...» 170
«Авыл чите. Инеш буе...» 171
«Сабыйдай сөенәм кайчакта, югалткан...» 172
«Мин, бәлки, бер бөртек...» 172
«Нәрсә әйтим?...» 173
Безнең тай 174
«Мин хәтта...» 175
Көзге күкрәү 176
«Кыек атлама»га карап 177
«Серләреңне әйтеп...» 179
Килде чак... 179
Кар төшерәм түбәдән 180
«Мин карт булам яшәрмәгәндә...» 181
Гел «җиңү»дән торган гомерләр! 181
Җуймагыз мәхәббәтне! 182
«Һәр зат Җирдә тигез булса...» 184
Безнең көннәргә бер штрих 184
Яшьлек дәфтәрендә бер рәсем 185
Айну яки тарихи махмыр 186
«Мин бүген сөйләшмим әле...» 189
«Сезнең урам аша үттем бүген...» 190
«Кояш бата...» 191
Триумф яки күренеш 191
Җәй ахырында язылган шигырь яки юбилейдан соң 192
«Бетте ул...» 193

«Яшь чагында һәр нәрсәне...» ........................................ 194
«Париж түгел, Пар-Иш!..» ........................................ 195
«Иштем дә...» ........................................ 195
Белая горячка ........................................ 196
«Күрдек...» ........................................ 200
Син әлегә яшьрәк бит!.. ........................................ 200
«О, сәрдә үләне!..» ........................................ 201
Чын төс соңрак... ........................................ 202
Сискәнү ........................................ 203
«Төрле чагым булды...» ........................................ 204
«Алма апай. Туган апай...» ........................................ 205
Метаморфозалардан ........................................ 206
«Минем таралган салларым бар...» ........................................ 207
Чын Аккош күлен сагыну ........................................ 208
Төн ........................................ 209
Гел туйлардан торган дөнья... ........................................ 210
Эпитафия ........................................ 211
Урак белән чүкеч ........................................ 211
Картлык ........................................ 212
«Очуын очкандыр да...» ........................................ 212
«Ярминкәләр! Ярминкәләр!..» ........................................ 213
Бөек ләззәт ........................................ 214
«Төн һәм Суык. Бу икәүдә...» ........................................ 215
Ул чак... Бу чак... ........................................ 216
Телефон ........................................ 217
Әти яккан мунчада ........................................ 218
Мордар ........................................ 219
Син — бар! ........................................ 219
Мәдхия ........................................ 220
«Әй, бу Яшәү!..» ........................................ 221
«Борын юеш чактук...» ........................................ 222
Казансу буенда ........................................ 224
«Иясез шатлык түгел хәзер...» ........................................ 224
«Ялгызак иртәләр...» ........................................ 225
«Тәннән аерылып чыккач...» ........................................ 226
«Күз яшьләре бизе кипте...» ........................................ 227
«Булсынга дип, тирләп-пешеп...» ........................................ 228
«Дөрләп янган зиратларны...» ........................................ 228
«Ул да вафат...» ........................................ 229
Гасабилану — иҗади яну ........................................ 230
Куян ату ........................................ 231
«Иртәнге җил, кичке салкын...» ........................................ 233
Әзерлек ........................................ 234
«Син — яшь! Мин — яшь!» дигәннәргә...» ........................................ 235
«Урал шаһинәсе булып Син үткәндә...» ........................................ 236
«Канда — басып алу, талау...» ........................................ 237
«Ике дөнья — бер морҗа ла!..» ........................................ 238
Юаныч ........................................ 238

Монда бик тиз шәфәкъ бата... 239
Бәлки... 240
«Ара сакла! Бар бит әнә...» 240
«Халыклар берләшеп беркөнне...» 241
Сәхрәләргә чыккан идек бер... 242
Идея 243
«Читән кору түгел...» 244
Яна вакыт, безне яндырып... 245
Төрек мунчасында уйлану 245
«Теге бөекнең тамыры...» 247
«Һәм, ниһаять, бусы да булды!..» 248
«Ян, газаплан...» 248
Бала теләү 249
«Яшәлгән... Күрелгән...» 249
Шигъри попурри яки гомер фасылы 250
Оялма! 251
«Картлык — йогышлы чир...» 252
Кичеп чыкмады... 253
«Җир сөрмәде...» 254
«Бүләкләрме?...» 254
«Уч тулы үч...» 255
Ачылмаган хатлар ята... 256
«Шундый чак килә...» 257
Быел җәй... яки моңсу кабатлану 258
«Авырыйсыңмы — димәк, гөнаһың бар...» 259
«Әче хәсрәт... Төче хәсрәт...» 259
«Кафтау. Сугыш. Ташлар егълый...» 260
«Үткәнне сорама...» 260
«Козгын кунган киртәгә!..» 261
99 яшьлек карт 261
«Стресслар кирәк...» 262
«Затлы...» 263
Авырганда 264
«Урман авызындагы хәйран киң юл...» 265
Иртәнге махмыр 266
Бар да үтә... 267
Бар ул... 268
Зиратта 269
«Дөньясы кагып-сугып...» 270
«Тәхет — биек!..» 270
Басып тору 271
Уйланды ир иртән уянгач... 273
«Үз вакыты җиткәч — имән ава...» 274
Күләгәләр 275
«Әрәм үткән кичләр...» 277
Бизү 278
«Талантын да, буй-сынын да...» 278
Ак төш 279

«Беренче саф хисне...» ... 280
«Дус»лыгы аның чиксез...» ... 281
«Өем — түзек. Тәнем — чиста. Уйларым — пакь...» ... 281
«Күл өстендә черки аулый...» ... 282
Килде бу көн... ... 283
Татарник ... 284
Идиллия ... 284
Берәүгә ... 285
Бернәрсә юк... ... 285
«Бу юл(ы) юньләп яшәлмәде...» ... 286
Күпсенмә, Ходаем!.. ... 287
Фараз һәм чынлык ... 288
Абсурдизм ... 289
Юк белән бар ... 290
Аскет ... 292
«Ары лап-лап, бире лап-лап...» ... 293
Ишек ... 294
«Ирлек чыкты бәреп тирләрдә!..» ... 295
Чибәрләр ярышында ... 296
Хәлең ничек, авыл? ... 297
«Бу бит хикмәт бай эшмәкәр!..» ... 299
Чынлык ... 300
Бәйлелек ... 301
Кисәтү ... 301
Парадокс такмаклар ... 302
Булмый ул... ... 303
Яшәү ... 303
Ул ... 304
«Алай итте...» ... 305
«Очкычлар ватылгач, җирдән...» ... 306
«Бетсәң бет, әмма тәңгәлләш!..» ... 307
«Мәктәп-сарай!..» ... 308
Пенсионер ... 308
«Шагыйрьләр алар картаймый...» ... 309
Айкалый-айкалый... ... 310
«Яшьлек чыннан да яшелдер...» ... 311
«Мәхәббәттән — Нәфрәт туа ала...» ... 311
М. Юныска ... 312
Уенчы ... 313
Чарасыз юану ... 314
Тормыш кырында ... 315
Шундый хәлләр... ... 316
Бар иде... ... 317
«Ходай аңа күпне биргән...» ... 318
«Дулкын арты дулкын килә...» ... 318
««Картлык — шатлык түгел». Хак сүз...» ... 319
Әй ул шайтанны! ... 320
Саклыйк Республиканы! ... 321

## Балалар өчен шигырьләр

Синеке – илнеке ........ 324
Табигать кочагында ........ 324
Бердәнбер ........ 325
Атлы малай ........ 326
Сапер бабам – гөмбәче ........ 327
Яңа күлмәк ........ 328
Кайсысы? ........ 328
Миләш ........ 329
Табында баланлы бал ........ 330
Бабай белән малай ........ 331
Менә безнең Газиз нинди! ........ 331
Бәхет пилмәне ........ 332
Тау хәтле акыл белән... ........ 333
«Сизмәдем: ата каз өскә...» ........ 334
Авыл манзарасы ........ 335
Шалкан бәясе ........ 335
Теш ........ 336
Кышкы көндә җәйге аваз ........ 337
Сары чәчәк – тузганак ........ 338
Тырышлыкта ярышыйк! ........ 339
Без – балта осталары ........ 340
Суык! ........ 342
Әче күлдә ........ 343
Төнбоек ........ 345
Мавыгу ........ 345
Трамплинда ........ 346
Күмәкләр һәм көчлеләр ........ 347
Туп ........ 348
Бакчадагы комлыкта ........ 349
Аптырашлы хәл, яки утау урынына бутау ........ 350
Хыял ........ 351
Онытма син! ........ 352
Чикләвек ........ 353
Икмәк заводы яныннан узганда ........ 353
Тугайда ........ 354
Яңгырда ........ 355
Җиләк кайда күп? ........ 356
Туган көндә ........ 357
Ни яхшы? ........ 357
Кырмыскалар утыртты! ........ 358
Җәйге җылы яңгырдан соң ........ 358
Таң ........ 359
Тузганак ........ 359
Юлга чыккач, уй килә ........ 360
Ярышта ........ 361
Яңгырдан коры чыктык ........ 363

Очты, очты... 364
Бу песнәкнең сайрап ни дию? 365
Бияләй 366
Быелгы яз 366
Сабир нигә сөртенә? 367
Кар астында умарталар 368
Күке нәрсә дип әйтә? 369
Төсле буяулы туплар 370
Бабай таягы 370
Каймаклы чия 371
Паласны кем кагар? 372
Күзге пычрак бер көнне... 373
Сабыйлар елы 374
Балыкта 375
Күп ашап, аз йөрсәң, тиккә корсак үстерсәң... 377
Булмаганны!.. 377
«Бу агачлар миннән олы...» 378
Таң ату 378
Яхшы сүз 379
Маратка нәрсә җитми? 379
Бинокль 380
Ике чәчәк 380
Яңгыр 381
Кем күпме чәпчетә? 382
Нинди хәлләр булмый дисез? 383
Җәйге талгынлык 384
Үсү 384
Энҗе һәм анар 385
Нефть 386
Чит авылда 387
Кыш алды 387
Юлда 388
Күрдем төрле җанварларны 389
Алмапай 390
Эзләр 390
«Түгәрәкче» миргалим 391
Кәгазь 392
Ташу үткәч 393
Авылда 393
Уенчыклар 394
Утын ярганда 395
Яланда 396
Арба белән чана 396
Тамырлар 397
Безнең Наилә 397
Кайчан кайда гөлләр? 398
Чүлмәк 398
Ничек яхшы булырга? 399
Илләр, җирләр гизүчегә 399

Сәгыйть белән сәгать ........................ 400
Авылда ........................ 401
Алтын балык түгел, гади балык сөйләде бик гасабиланып... ........................ 402
Йомыш ........................ 403
Командир ........................ 404
Рәшәткәләр буядым! ........................ 405
Җилнең сурәте нинди? ........................ 406
Пароходлар ял итә ........................ 407
Болында. Чишмә буенда ........................ 408
Хәбир абый ........................ 410
Йокы әкияте ........................ 420
Әлли-бәлли ........................ 423
Дүрт сүзе бар улымның ........................ 424
Авыл юбилее ........................ 426
Аэробуста уйлану ........................ 427
Табагач ........................ 430
Биектән ........................ 431
Тау ........................ 432

## Поэмалар

Гадиләргә гимн ........................ 435
Көрәшчеләр ........................ 448
Сәйдәш ........................ 457
Җир турында ертык җыр ........................ 495
Карт һәм шагыйрь ........................ 499
Ике зират арасы... ........................ 507
Иҗат ........................ 513

Литературно-художественное издание

***Файзуллин*** *Равиль Абдрахманович*

Избранные произведения

В шести томах

Том 3

Казань. Татарское книжное издательство. 2005

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Фәйзуллин*** *Равил Габдрахманович*

Сайланма әсәрләр

Алты томда

3 том

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 2.12.2005. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 27,72 + вкл. 0,42 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 28,88. Нәшер-хисап табагы 16,85 + вкл.0,44 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ А-883.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.